Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

08
август 2022
ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫНА – 30 ЕЛ

Татарның беренче һөнәр мәктәбе

6 бит

Татар конгрессы: тәүге адымнар

30 бит

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС
12 +

08
(344)
август 2022

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Наис Гамбәр

ТАРИХИ МИРАС

4 Казан ханлыгы тарихында Сөембикә ханбикә. *Ә.Әхсәнов*
6 Татарның беренче һөнәр мәктәбе. *Л.Гобәйдуллин*
12 Касыйм ханлыгында акча әйләнеше. *О.Степанов, А.Бугарчев*
14 Малмыж татарлары һәм марилар. *И.Газизуллин*
20 100 ел элек татар дөньясы
22 Касыйм хан (1440 нчы еллар ахыры-1469)

ТАТАР ГАМЕ

24 Без татар халкына карашны үзгәрттек. *М.Шәймиев*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразыев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ильяс Җиһаншин
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рүзәл Мөхәммәтшин
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм битгә салучы
Алмаз Фәйзуллин
(843) 222-09-83 (17-92)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

SMM-белгеч
Ләйләгөл Сафина
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал
(на татарском и русском языках)

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

28 Васил Шәйхразыев: «һәр татар кешесе өчен Татарстан – туган як»
30 Татар конгрессы: тәүге адымнар. *И.Таһиров*
35 Данис Шакиров: «Татар халкының зур бәхете – һәр җирдә үз лидерларыбыз булу»
38 Олы юлның узганы. *Р.Закиров*
47 Фәрит Уразаев: «Ак бай»ларыбыз туып килә!»
50 Альберт Борһанов: «Тулы бер институт эшен башкара торган төбәкчеләребез бар»
54 Узган гасыр Милли Шурасыннан бүгенгесенә кадәр. *Р.Мөхәммәтшин*
61 «Безнең мирас» котлый!

ДИНИ МИРАС

62 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*
68 Ислам. Дини сүзлек
69 Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре. *Ә.Рәхими*
70 Дин дәресләре. *С.Бикбулат*
72 Морад Рәмзи хакында фикер-күзәтүләр. *Х.Миңнегулов*

СӘНГАТИ МИРАС

77 Бөек рәссам Урманче. *З.Мөхәммәтшин*
82 Татарның «наив» сәнгать юнәлешендәге беренче рәссамы. *Д.Гайнетдинова*
85 Илһам абый. *Ф.Сәфәргалиева*
90 Барабаннар кемнеке дә, балалайка кемнеке? *А.Чанышев*
96 «Яшә, республикам!» җыры

ӘДӘБИ МИРАС

98 Рәхим Саттар шигырьләре
100 Татар шигъриятендә мөһаҗирлек хәрәкәте һәм Исхакый. *Т.Галиуллин*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

106 Истә, һаман да истә!

ТАБИГЫЙ ЯДКЯРЛӘР

108 Имән

СИХӘТЛЕ МИРАС

109 Имән дәвалый

ТАТАР РИЗЫГЫ

110 Кияү коймагы – табын байлыгы

ШАЯН МИРАС

112 Көлке куа килә...

БАЛАЧАК МИРАСЫ

114 Без барыбыз да – балачактан

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Август*

Заказ №О-2248. Тираж – 3515 данә. Формат 70x100 $^{1}/_{16}$
Басарга кул куелды: 25.07.2022. Чыгу көне: 28.07.2022.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә:
Әлфрид Шәймәрдановның «Казан. Килеп җиттек» әсәреннән фрагмент. 2020 ел

Безнең мирас №8 август 2022

Гомер җәбе кыска — бер саплам.

Наис Гамбәр

Шагыйрь Наис Гамбәр (1947-2005) һәм артист Хәлим Җәләй (1940-2021). 1990 нчы еллар ахыры

НАИС ГАМБӘР
(25.08.1947-4.05.2005)

Язылмаган поэма – һәрбер төнем,
Укылмаган китап – һәр көнем.

***

Шыксыз, буп-буш бүлмә –
Күзгә алмагач кебек ялангач.

***

Вакыт – табиб, үтә тора көннәр,
Син калдырган җөйне дәвалап.

***

Ярлар буйларында арыпауган
Өянкеләр – динозаврлар.

***

Яшәү мең катлы була,
Сөю бер катлы була;
Сөюнең күңел келәте
Бер орлык белән тула.

***

Орлык эчендә орлык бар,
Орлык тулы күзәнәк;
Күзәнәктә яшәү йоклый, –
Бу да безнең күрәчәк.

*Текстны журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Казан ханлыгы тарихында Сөембикә ханбикә

Әнвәр Әхсәнов, тарих фәннәре кандидаты

Казан ханлыгы тарихында Сөембикә ханбикә ролен өйрәнә башлауга, парадоксаль вазгыятькә тарыйбыз. Бер яктан, ханлыкның сәяси тормышында Сөембикә тоткан мөһим урын турында бик күп тарихчылар яза, халык легендаларында һәм риваятьләрендә ул гаять җылы, яратып искә алына. Икенче яктан, чыганакларда аның хакында мәгълүмат бик аз. Урыс елъязмаларында һәм дипломатик документларда Сөембикә бары тик Җангали хан (1532-1535 нче еллар) идарәсенә (ханша буларак) һәм 1551-1552 нче елларга бәйле рәвештә генә (Явыз Иваннан солых өмет итеп, Казан хөкүмәтенең Сөембикәне, улы Үтәмеш Гәрәй белән бергә, Мәскәүгә озатуы) чагылыш таба. Елъязмалар раслаганча, Казаннан качар алдыннан Шаһгали ханның Мәскәүгә каршы булган бәкләрне һәм морзаларны юк итә, кирмәндәге тупларны һәм дарыларны сафтан чыгара, шуңа рәхмәт йөзеннән, урыс патшасы аңа Сөембикәне хатынлыкка бирә.

Фәрит Якупов. «Сөембикә – Казан ханбикәсе». XX гасырның икенче яртысы. ***Киндер, майлы буяу, 90х75 см***

«Казан елъязмасы» хезмәтендә ханбикәнең сәяси биографиясенә күбрәк игътибар бирелгән. Бу чыганакка ышансаң, Сафа Гәрәй ханның вафатыннан соң хакимият тулысынча Сөембикәгә һәм Кырым ханзадәсе Кузычак (Кошчак) угланга күчә. Казан хакимияте борын төбендә Зөя кирмәне төзелүен дә, чирмешләрнең хыянәтен дә белми кала, ә инде белгәч, соң була... Ханбикә сугышка әзерләнергә фәрман бирә. Аның бу омтылышын Кузычак, кырымлылар һәм нугайлар хуплый, калганнар исә каршы чыга. Нәтиҗәдә, үзара талаш-тарткалаш китә.

«Казан елъязмасы»чысы Кузычакны Сөембикәнең сөяркәсе итеп күрсәтә, аны тәхет варисы Үтәмеш Гәрәйне үтерергә теләүдә гаепли. Шуның аркасында, имеш, халык арасында ризасызлык туа. Фетнәдән куркып, Кузычак, гаиләсен һәм биш мең яранын алып, Кырымга кача. Шаһгали, бу хәбәрне ишетүгә, Кузычак артыннан воевода И.В.Шереметьев җитәкчелегендәге ун мең кешелек гаскәр җибәрә. Дон белән Идел арасында урыслар кырымлыларны куып җитә. Кузычак углан һәм тагын өч йөз кеше, әсир төшеп, Мәскәүгә озатыла. Озакка сузмыйча, хатын-кызлардан һәм балалардан кала, аларның барысын да җәзалап үтерәләр.

Әлеге елъязма раслаганча, Казан түрәләре, ханлыкның идарәсез калуын һәм сугыш алып баруның хаҗәтсезлеген сылтау итеп, тәхеткә яңадан Шаһгалине чакыра. Озак уйланганнан соң, Шаһгали Казан тәхетенә утырырга һәм Сөмбикәне хатынлыкка алырга ризалык бирә. Сөембикә булачак иренә бүләк итеп сыйнигъмәт һәм үзе теккән эчке күлмәк (сорочка) җибәрә. Әмма «күчтәнәчләр»нең агуланган булуы ачыклана. Сөембикә, улы Үтәмеш Гәрәй һәм хан казнасы белән бергә, Мәскәүгә җибәрелә. Ханлыкның тар-мар китерелүеннән куркып, халык Сөембикәнең куылуына каршы чыгарга базмый. Шаһгали, Казанга килгәч тә, сәетнең башын чаптыра һәм урыс әсирләрен иреккә чыгарырга боера. Әмма әсирләрнең күбесе, ислам диненә күчеп өлгергәнгә күрә, урыс иленә кайтудан баш тарта.

Алга таба «Казан елъязмасы» Сөембикәнең елый-елый Казан белән бәхилләшүен сурәтли. Ханбикә һичничек тынычлана алмый, көймә-кораб Казан ярларыннан купкач, ул соңгы кабат ханлыкның башкаласына караш ташлый һәм моң-зар түгә. Шунысын искәртергә кирәк: Сөембикәнең бу «еглавы» гаҗәп рәвештә «Слово о житие и преставлении великого князя Дмитрия Ивановича, царя русского» әсәрендәге Евдокия «плач»ына охшаган. Елъязмачы шушы «Слово...»дагы фрагментны үз әсәренә күчереп язган һәм изге китаплардагы кайбер фразаларны Сөембикә авызына салган: ханбикә Казанны гөнаһка чумган Иерусалимга һәм җеннәр, кара рухлар оялаган «җилбәзәк» Вавилонга тиңли.

«Казан елъязмасы»ндагы хәбәрләр Исаия һәм Иеремия китапларына охшаш. Шуңа күрә Сөембикәнең Кузычак углан белән «уйнашы», тәхет варисын үтерергә теләү, Шаһгалинең Сөембикәгә өйләнүе һәм башка шундый вакыйгалар Тәүратка ияреп язылган уйдырма дип расларга мөмкин. Чөнки, сюжет таләп иткәнчә, Казанның урыс патшасы тарафыннан яулап алынуы гына мондый «бозыклык»ка һәм «башбаштаклык»ка нокта куя алыр иде. Күренгәнчә, елъязма, тарихидан бигрәк, идеологик чыганак вазыйфасын башкара.

Йомгаклап әйткәндә, ханбикәнең тормышына кагылышлы документаль мәгълүматлар бик аз. Әмма татар халкының тарихи хәтерендә Сөембикә Казан ханлыгының иң куәтле сәяси фигураларыннан берсе булып саклана. Өстәвенә, ул үзе генә дә «исламда хатын-кыз хокуксыз» дигән сафсатага каршы торырлык мисал. Гомумән, мөселман илләрендә хатын-кызның тәхет биләве гайре табигый күренеш түгел. Урта гасырларда Хәрәземшаһлар дәүләтендә, Мәмлүкләр Мисырында, Госманлы мәмләкәтендә еш кына хатын-кыз идарәчеләр алга чыккан. Мондый мисаллар татар тарихында да бихисап: Алтын Урда ханбикәсе Тайдула, Казан һәм Кырым ханбикәсе Нурсолтан, Казан ханбикәсе Гәүһәршад һ.б. Һичшиксез, Сөембикә ханбикә дә – дөнья тарихында иң күренекле хатын-кызлардан, иң абруйлы дәүләт башлыкларыннан берсе. ■

Татарның беренче һөнәр мәктәбе

Ленар Гобәйдуллин



Пермь мөселман җәмгыятенең һөнәр мәктәбе

XX гасыр башында татар, шул исәптән башка мөселман балалары өчен ачылган махсус һөнәр мәктәпләре санаулы гына була. Шуларның беренчесе һәм иң нәтиҗәле эшләгәне Пермь шәһәре янындагы Куян авылында оештырылган. Әлеге мәктәп заманы өчен иң мөһим вазыйфаны башкарган: эшлекле һәм булдыклы татар егетләрен тәрбияләп чыгарган.

Аны 1908 елда «Пермьлеләрнең тәрәккъыюн икътисадиюн җәмгыятьләре» (төрле чыганакта төрлечә языла: «Пирмә мөселман тәрәккъыюн ислам җәмгыяте»), русча әйткәндә, «Мусульманское культурно-экономическое и благотворительное общество г. Перми» оештырып җибәрә. Бу «Һөнәр мәктәбе» әлеге хәйрия җәмгыяте иганәсеннән һәм өяз земствосыннан финансланган. Мәктәпне төрле исем белән атап йөрткәннәр: «Ыстолярлык мәктәбе», «Сәнәгатьханә», «Столярно-кузнечная мастерская», «Ремесленная учебно-показательная школа с. Кояново».

Ул кыска гына вакыт аралыгында зур уңыш казана. Әйтик, 1913 елда шәкертләр Омск шәһәрендә оештырылган күргәзмәдә үзләре ясаган комод өчен көмеш ме-

даль белән бүләкләнә. Шул ук елда Петербургта узган һөнәр күргәзмәсенә җибәрелгән бер буфет 300 сумга бәһаләнә. Ә Пермь шәһәрендәге мөселман кызлар мәктәбе белән берләштереп оештырылган өч көнлек күргәзмәдә татар егетләре ясаган буфетны губернатор үзе 200 сумга сатып ала! Яхшы савым сыеры әлеге елларда – 60, ә ат 70-110 сум торганын искә алсак, бу бик зур сумма.

Моннан тыш, һөнәр мәктәбендә шәкертләр буяу кайнату, колеровка, буяу технологиясе серләренә дә төшенгәннәр. Авыл читеннән ун дисәтинә казна җирен алып, шәкертләргә шунда печән чәчеп үстерү ысулын да өйрәтмәкче булганнар, әмма бу эшнең гамәлгә ашуы турында мәгълүмат таба алмадык.

Мастер Е.Г.Барашков, мастерскойны караучы (почетный чикмәндә) Бактиков һәм Куян авылының вәкилләре

1911 елның көзендә Пермь хәйрия җәмгыяте тарафыннан мәктәпнең «Кәрзинкә үрергә үгрәтә торган шөгъбә»се дә уңышлы гына эшләп киткән. Моның өчен хәйрия җәмгыяте, Петербургтагы авыл хуҗалыгы станциясе комитетына мөрәҗәгать итеп, 1000 сум акча алуга ирешкән. Куян авылында тал аз һәм каты булу сәбәпле, читтәге авылдан берничә дисәтинә җирне арендага алып, шунда яхшы сыйфатлы 4 мең төп тал алдырып утыртканнар, икенче елны янәдән 8 мең төп тал утыртканнар.

Пермь хәйрия җәмгыятенең рәисе һәм һөнәр мәктәбенең мөдире Гыйсмәтулла Мортаза улы Гайнуллин булган. Алда әйтелгән эшләрнең барысы да әлеге мөхтәрәм шәхеснең тырыш хезмәте икәнлеге аңлашылса кирәк. Гыйсмәтулла хаҗиның Уфада муллалар курсында укучы 42 имам һәм мөгаллим алдында «авылларда бик җиңел генә юл белән ничек итеп һөнәр мәктәпләре ачу хакында», «һөнәр мәктәбе ачу бик ансат эш» икәнлеге турында лекция укыганлыгы да тарихка кереп калган. Чыгышында ул өч җирдә һөнәрче мөселман мөгаллимнәр әзерләнүе турында хәбәр итә. Курстагы муллалар «Гыйсмәтулла әфәнденең яныннан бик мәмнүн булып, һәркаюсы үз төбәкләрендә бу эшне мәйданга чыгару юлында тырышырга вәгъдә биреп» таралса да, вакытлы матбугатта әлеге чорда татар һөнәр мәктәпләре ачу турында әллә ни мәгълүмат күренми.

Әгәр тарихи чыганакларга күзәтү ясыйбыз икән, беренче һөнәр мәктәбенә мөнәсәбәтле кызыклы гына фактларны барлый алабыз. Киләсе язмадагы сораулар – безнеке, ә җавапларны шул чорның вакытлы матбугатыннан эзләп таптык.

Эш өйрәнүче мөселман шәкертләре – 15 бала

***

– Һөнәр мәктәбе ни өчен ачылган?

«Киткән саен мәгыйшәт авырлаша бара. Җир азлык, налог күплек авыл халкын шәһәргә куа, кәсеп вә һөнәр белмәү боларны ач калдырып, теләнчелеккә мәҗбүр кыла.

Шуның өчендер ки, соң чакта мөселманнар арасында теләнчелек фәүкыльгадә *(гадәттән тыш)* күбәйде. Мөселманнар шәһәре Чистайның мәгълүм шөһрәтен дәгъва кыларлык дәрәҗәгә җитте*.

Мәзкүр *(әлеге)* бичара мөселманнарны бу хәлдән коткару өчен бердәнбер чара – аларга һөнәр өйрәтмәктер. Пермьдәге бер груһ *(төркем)* тәрәккыйпарвәр *(алдынгы карашлы)* адәмнәр шуны төшенеп, бер мөселман җәмгыяте ачканнар вә гыйлем тарату, һөнәр өйрәтү юлы илә мөселманнарны гаҗиз калу һәм теләнчелектән коткарырга тырышырга карар биргәннәр.

Әлбәттә, пермьле берничә һиммәт сахибе *(тырышучы кеше)* бөтен Русия мөселманын һөнәрле вә бәхтияр итә алмас. Моны алардан таләп итү дә хаксыз. Ләкин бу җәмгыятьнең отчетын күргәч: «Әгәр һәр мөселман шундый тәшәббеста *(тырышлыкта)* булса, милләтнең матди хәле бик тиз алышыныр иде», – диясе киләдер.

Җәмгыять ачылгач та Куян нам *(исемле)* мөселман авылында һөнәр мәктәбе ачып, Барашков нам оста русны яллап, 14 балага столярлык өйрәттергән».

– Мәктәпнең матди хәле ничек булган?

* Чистай өязе мөселманнарында теләнчелек киң тарала һәм бу татар вакытлы матбугатында көчле тәнкыйтькә дучар була. – *Ред.*

«Хәзер мастерской земство тарафыннан бирелгән бер йорттадыр. Ачылуына бер генә ел булганлыктан, эче бик бай түгел әле. 1910 ел башынача 400 сумлык корал алынган».

– Шәкертләр ниләр ясаганнар?

«Табуреткалар төрлечә (41 данә), җыелмалы (1), кухня өстәле (4), обед өстәле (1), ышпункаларда эшләнгән өстәл (2), комодлар (4), буфет (1), көзге алдына өстәл (1), зур ышкаф (1), китаплар ышкафы (1), кәнселәрия өстәле (1), хатыннар өстәле (1), этажерка (1), ширма (1), граммофон астына тумба (9), китаплар өчен киштәләр (4), кәрнизләр (13), тәрәзә рамнары (10), баскыч (1). Мәҗмугысы 12 төрле нәрсә».

Башка чыганакта: «Шәкертләр 87 данә һәртөрле утыргыч, һәртөрле 15 өстәл, бик күп комодлар, ширмалар, 22 тәрәзә кәрнизе, рамнар, буфет, этажерка, прилавка кеби нәрсәләр ясаганнар. Боларны эшләргә 92 сумлык материал тотылып, мәктәп 1000 сум саф файда итмештер. Киләсе көз шәкертләр остарып мастерскойда эшләр дәхи *(тагы да)* күбәячәгеннән анда ясалган мебель Пермьдә земство ышколада да сатыла башлаячактыр».

– Мәктәпкә кабул ителү һәм уку тәртибе ничек булган?

«Уку мөдәте *(вакыты)* өч ел. Уку елы беренче сентябрьдән башлап беренче майга кадәрле дәвам итә. Теләгән кешегә бөтен ел буе, ягъни сентябрьдән сентябрьгә кадәр эшләргә калырга мөмкин. Мастерскойга кабул итү уку вакыты башланганда булыр. Әгәр буш урын булса, ел уртасында шәкерт кабул итәргә мөмкин һәм яше олыгайганнарны да кабул итәргә мөмкин. Ыстолярный мастерскойга 12 яшьтән ким балалар алынмас. Ибтидаи мәктәпне бетергән таза-сәламәт балалар гына кабул ителер. Курс бетергән шәкертләр җәмгыятьнең рәисе вә әгъзалары, җирле



Мөселман шәкертләре мастерскойда эш вакытында

Җәмгыятьнең рәисе Гыйсмәтулла Мортаза улы Гайнуллин

Складта шәкертләр ясаган җиһазлар



Кәрзин үрү өчен махсус остаханә

һөнәрчеләр вә земство техниклары хозурында имтихан бирерләр. Имтихан тотканнарга һөнәр белгәнлегенә шәһадәтнамә бирелер, анда җәмгыять рәисенең һәм имтихан кылучының имзасы булыр. Мастерскойда шәкертләр практика хезмәтләре илә көнгә сигез сәгать шөгыльләнерләр».

– Мәктәпнең киләчәген тәэмин итү өчен нинди чаралар күрелгән?

«Пермь тәрәккъыюн ислам җәмгыятенең «Ыстолярный-кузнечный мастерское» файдасына Пермь любительләре – рус-мөселман яшьләре тарафыннан Общественный собрание залында «Шәрекъ кичәсе» ясалды. *(Бу 4 нче шәрекъ кичәсе инде.)* Зал шәрекъ ысулында киоскалар илә зиннәтләнгән, лотерея өчен җәмгыять файдасына тәрәккъыйпарвәр адәмнәр тарафыннан һәдия *(бүләк)* ителгән шәрекъ халкына хас кәләпүш, калпак, читек кеби нәрсәләр җыелган иде. Җыелган рус ханымнары вә руслар читек-кәләпүш чыкса иде дигән кеби билетларны туктаусыз ала тора иделәр. Лотерея билетлары бер дә калмый таралып бетте. Кичә бик тантаналы ясалды.

Програм бик яхшы иҗарә кылынды *(башкарылды)*. Рус вә мөселманнардан бик күп халык җыелган иде. Бар керем – 1346 сум, чыгым 446 сум булып, саф 900 сум файда калды. Пермь любительләре бу эштә зур хезмәтләре өчен Гыйсмәтулла әфәнде Гайнуллин вә ярдәмчесе Фатыйх әфәнде Тимкинга чын күңелдән рәхмәт укыдылар».

– Мәктәп нинди үзгәрешләр кичергән?

«Бу мәктәпнең эшләре бик уйланып, башындук бик яхшы куелган иде. Һәр ел әллә никадәр шәкерт укып, һөнәрмәндләр вә һөнәр мәктәпләре өчен мөгаллимнәр чыгарып торды. Бу ел столярный шөгъбәсендә *(бүлегендә)* 24 шәкерт үгрәнә. Мәктәптән шәһадәтнамә алган алты һөнәр мөгаллиме бар. Сораган җиргә хәзер җибәрергә мөмкиннәр. Язга тагын 8 кеше мөгаллимлек шәһадәтнамәсе алып чыгачак.

Кәрзинкә эшли торган шөгъбәсендә 10 шәкерт үгрәнмәктәдер. Монда тагын ун шәкертлек урын бар. Кәрзинкә эшләрен үгрәнергә теләгән кешеләр читтән кабул ителәләр. Монда иң гади вә иң простой кәрзинкәләрдән башлап 2-3 сум, 5 вә 20 сумлык кәрзинкәләр, кыйммәтле ширмаларга кадәр эшләнәдер. Тырыш шәкерт, ике елда имтихан биреп, оста булып чыга. Үгрәнү – буш, ашау-эчү өчен аена 7 сум расход җитәдер. Башка расход чыкмый. Бу мәктәптә юк кына бер расход белән ике-өч ел эчендә бик зур бер һөнәр үгрәнергә мөмкин».

Чыганаклар:

1. Отчет Пермского мусульманского культурно-экономического и благотворительного общества за 1910 год. – Пермь, 1912.

2. Мәһдиев Борһан. Пермь мөселман җәмгыятенең һөнәр мәктәбе // Вакыт. – 1910. – №627. – 9 июнь.

3. Ибраһимов Җәгъфәр. Пермь тәрәккъыюн ислам җәмгыятенең «Ыстолярный-кәрзиночный мастерское» // Вакыт. – 1912. – №939. – 13 март.

4. «Барып күрүче». Пермьдәге һөнәр мәктәбе хакында // Вакыт. – 1914. – №1406. – 2 февраль.

5. Авылларда ничек итеп һөнәр мәктәпләре ачарга? // Вакыт. – 1915. – №1788. – 4 июнь.

6. Куян авылының сәнәгать мәктәбе // Икътисад. – 1911. – №5-6. – Б.155-157.

7. Устав Пермского мусульманского культурно-экономического и благотворительного общества. – Пермь, 1910.

8. Хәерле сәгатьтә // Икътисад. – 1908. – №4. – Б.109. ■

Безнең мирас №8 август 2022

Касыйм ханлыгында акча әйләнеше

(XV-XVI гасырлар)

Олег Степанов, Алексей Бугарчев

XV гасыр урталарына Көнчыгыш Европада шактый четерекле сәяси вазгыять урнаша. Бу чорда гаять зур мәмләкәт – Җучи Олысы (Алтын Урда) таркала, аның урынына яңа сәяси берәмлекләр барлыкка килә: Кырым, Казан һәм Әстерхан ханлыклары, дәүләт рәвешен үк алмаган Нугай Урдасы, Себер ханлыгы. Олуг Урда элгәреге абруен сакларга тырыша. Көнбатышта татар ханлыкларыннан Мәскәү кенәзлеге ярала – Иван III алып барган сәясәт нәтиҗәсендә, төньяк-көнбатыш һәм үзәк урыс кенәзлекләре яңа мәркәз тирәсендә берләшә.

Бу хәлләргә нинди вакыйгалар этәргәнен искә төшерик. 1445 елда, Василий II гаскәре Суздаль янындагы орышта Олуг Мөхәммәд тарафыннан тар-мар ителгәч, дөнья картасында Касыйм ханлыгы дип аталган кечкенә дәүләт оеша. Ул әсир төшкән Василийны азат итү хакына Мәскәү һәм Рязань кенәзлекләре арасындагы җирләрдә (Мещера), «мордва» белән «мурома» арасында барлыкка килә. XV гасыр башында Мещераның административ үзәге хәзерге Кадом бистәсе янында була әле. Касыйм хан (Олуг Мөхәммәднең улы) тәхеткә менгәч (1452-1496 нчы елларда идарә итә), яңа үзәк – Ханкирмән (Мещерский городок) оеша. Әмма яшь дәүләт, ныгып китә алмыйча, акрынлап кына Мәскәү вассаллыгына күчә. Алга таба Касыйм ханнарына урыс дәүләте чикләрен һәм мәнфәгатьләрен саклау-яклау бурычы да йөкләнә. Ханлык җирләренең төп хуҗасы Мәскәү кенәзе була. Хан үзенә буйсынган аерым затлар аша крестьяннардан ясак җыя (салым дәүләт кеременең саллы өлешен тәшкил итә). Аннан тыш, Мәскәү кенәзе тарафыннан ханга «тугрылыклы хезмәте өчен» «вазыйфа хакы» да түләнә әле.

Касыйм дәүләтендә сәүдә эше киң җәелгән: әледән-әле ярминкәләр оештырылган, сату-алу үзәкләре корылган. Бу да, үз чиратында, казнаны тулыландырып торган.

Инде ул чорның акча берәмлекләрен барлап карыйк. Дәүләтнең сәүдә-икътисад мөнәсәбәтләре нигезен нәрсә тәшкил иткән соң?

Урыс иленә бәйле ханлыкта урыс акчалары йөрү табигый. Башлангыч чорда биредә Мәскәү, Түбән Новгород, Рязань, Бөек Новгород һәм Псков тәңкәләре әйләнештә була. Алардан тыш, өстәмә тамгалар төшерелгән (надчеканка) XIV гасыр Алтын Урда дирһәмнәре дә йөри. Сарык башы төшерелгән Рязань акчалары да очрый. Алтын Урда тәңкәләренә охшатып ясалганнары да бихисап. Табылдыклар арасында Хаҗитарханда, Сарайда, Кырымда сугылган XV гасыр татар акчалары да бар. Касыйм өязенең Паракино авылында 1925 елда Рязань тәңкәләреннән гыйбарәт хәзинә табыла. Археологлар Шемякино авылында Җучи дәүләте суккан акчаларга тарый. Шацк, Муром һәм Спас өязләрендә XIV-XV гасыр тәңкәләрен саклаган җиде хәзинә ачыла. Бу фактлар Касыйм ханлыгында Алтын Урда тәңкәләренең актив

Касыйм ханлыгы җирендә табылган Мәскәү тәңкәсе

Касыйм ханлыгы җирендә табылган Түбән Новгород тәңкәсе

Касыйм ханлыгы җирендә табылган Алтын Урда тәңкәсе (надчеканка)

Касыйм ханлыгы җирендә табылган Рязань тәңкәсе (надчеканка)

Касыйм ханлыгы җирендә табылган Бөек Новгород тәңкәсе



Касыйм ханлыгы җирендә табылган Иван III «копейкасы»

әйләнештә булуы турында сөйли. Җучи дирһәмнәре һәм Кырым акчалары сәүдә итүдә дә, салым җыюда да шактый еш файдаланыла.

Әмма Мәскәү хакимияте үзенең элгәреге «ирексезлегенә» ишарә иткән күренешләрдән тизрәк котылырга омтыла, шул сәбәпле, тора-бара Алтын Урда тәңкәләре кулланудан төшеп кала.

Касыйм ханлыгында Мәскәү акчаларыннан Василий II «билгеләре», соңрак Иван III һәм аның улы Василий III «копейкалары» әйләнештә йөргән. Яңа тәңкәләр урыс дәүләтендә генә түгел, чиктәш җирләрдә дә гамәлдә булган. Мәсәлән, Иске Казан җирлегендә XV-XVI гасырларга караган 80 данәдән артык урыс акчасы табыла.

Елена Глинскаяның 1532-1539 нчы елларда уздырган акча реформасыннан соң, Мәскәү дәүләтендә элгәреге һәммә тәңкәләр йөрештән чыгарыла һәм Мәскәү, Тверь, Псков һәм Новгород сарайларында Иван Васильевич (Иван IV) исеменнән сугылган яңа акчалар әйләнешкә кертелә.

XV гасыр уртасыннан башлап XVI гасыр ахырына кадәр акча йөреше әкренләп унификацияләнә, ары таба ике төрле тәңкәләр генә кала: сөңге тоткан җайдак («копейка») һәм кылыч тоткан җайдак («сабляница», «копейка»дан ике тапкыр җиңелрәк); ялган акча сугучыларга каршы катгый кануннар кабул ителә. Бу система Петр I реформаларына кадәр (XVIII гасыр башы) гамәлдә була.

Әдәбият:

Гулецкий Д.В., Петрунин К.М. Русские монеты 1353-1533 гг. – «Рифтур», 2018. – 511 с.
Рахимзянов Б.Р. Касимовское ханство (1445-1552 гг.). Очерки истории. – Казань: Татарское книжное издательство, 2009.
Худяков М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. – М.: «Инсан», 1991. ■

Иллюстрацияләр Д.В.Гулецкий һәм К.М.Петрунин китабыннан алынды.

Безнең мирас №8 август 2022

Малмыж татарлары һәм марилар

Илнур Газизуллин

Малмыж музее ядкярләре ни сөйли?

Казан дәүләт университетының тарих факультетында укыганда, Малмыж музеена барып, менә мондый мәгълүматларны ачыклаган идем.

Казан ханлыгы чорында Малмыж җирендә Казанга буйсынучы һәм аның чикләрен саклаучы мари кенәзлеге бик көчле була. Марилар, татарлар белән берлектә, хәрби көч тәшкил итәләр. Җирле рус һәм мари риваятьләрендә кенәз Балтуш турында сөйләнә. Ул Явыз Иванга каршы каты сугышта туп ядрәсе белән атып үтерелә. Риваятьләрдә Балтушны атка утыртып җирләүләре турында бик тә үзенчәлекле мәгълүмат сакланган һәм бу борынгы төрки йолаларга бик тә якын.

Мәкаләнең авторы (уңда) Адай авылындагы Изге чишмә янында

Шуны да әйтик, археологик Азелино культурасында ат культы бар – хатын-кыз бизәнү әйберләренә ат сыны кергән. Бу кабиләләр үз вакытында Урал артыннан килә. Әлеге факт аларның күчмә төрки кабиләләр белән тыгыз элемтәдә булганлыкларына бер дәлил булып тора.

Аяк киемнәре темасын тикшерә башласак, музей экспозициясендә зур урынны чабата алып тора. Аның бик күп төрләре бар: гади чабата, күтәртмәле чабата, юкәдән үрелгән итек. Татар этнографы Наил Халиков татарларга чабата үрү марилардан күчкән булуы мөмкин дип фаразлый. Бу аңлашыла да: урман халкы дип саналган мариларга урман чималыннан, ягъни юкәдән әйберләр ясау күбрәк хас. Ә менә даладан килгән татарларга тиредән ясалган аяк киеме – читекләр кулайрак булгандыр.

Шуны да онытмаска кирәк: Смәил – татар чабатачылары авылы. Яңа Смәилдә, шулай ук минем туган авылым Иске Смәилдә Бөек Ватан сугышына хәтле чорда ча-

бата үрү киң таралган һөнәрчелек була. Малмыж базарында чабата махсус урында сатылган. Смәил атамасын әйтү кайбер рус кешеләренә җайсыз булса, алар: «Теге, чабатачылар авылы...» – дип кенә аңлатканнар. «Престижный» булмаган әлеге һөнәрчелек Смәил татарларына революциягә кадәр салым түләргә, соңрак ачтан үлмәскә мөмкинлек биргән. Ул күпләр өчен өстәмә акча чыганагын, керем алырга мөмкин булган төп һөнәрне тәшкил иткән. Безнең якта җир алай ук уңдырышлы түгел һәм ул аз булган, һәркемгә җитмәгән. Шуңа күрә бу яктагы авыл кешеләре башка акча чыганагы эзләгән һәм аны төрле һөнәрләрдән тапкан.

Икенче материал – аучының төп коралы – җәя һәм ук. Мари этнографиясендә алар турындагы мәгълүмат бик кызыклы. Мәсәлән, агулы ук белән җирле мариларның милли каһарманы Акбатырны үтерәләр. Зур Китәк янындагы авылларның барлыкка килүе турындагы риваятьтә дә ук белән җәя зур урын алып тора. Анда болай диелә: әтиләре үзенең улларына җәя һәм уклар бирә. Уклар кая очып барып төшсә, егетләр шунда авыл нигезләргә тиеш була. Шулай итеп, Зур Китәк, Кече Китәк һәм Акбатыр авыллары барлыкка килә.

Уклар җирле археологиядә дә очрый. Мәсәлән, Азелино культурасына караган каберлекләрдә (б.э.к. I меңъеллык-б.э. башында) үзенчәлекле йола күзәтелә. Анда мәетләрне җирләгәндә кабергә ук очлары салып калдырганнар. Алар так санда – 7 яисә 9 данә булган. Археолог В.Ф.Геннинг бу культура белән эш иткәндә, үзенең эзләнүләрендә Зур Китәк базарындагы марилар этнографиясе материалларын куллана һәм, аның карашынча, Азелино кабиләләре мариларның бабалары була ала. Азелино авылы Иске Йөректән ерак түгел, тау аша гына урнашкан.

Соңрак, Казан дәүләт университетында тарих өйрәнә башлагач, татар-мари мөнәсәбәтләренә кагылган яңа кызыклы фактларга да тап булдым. Мәсәлән, безнең бөек якташыбыз, Малмыж музеена нигез салган һәм Казан ханлыгы тарихын язган галим М.Худяков үзенең әсәрләрендә безнең җирле материалларны, шулай ук мариларның риваятьләрен, каһарманнарын киң кулланган. Биредәге татар, мари, удмуртларның үзара татар телендә аралашуларын, Малмыж шәһәренең алынуы, Балтуш кенәз турында риваятьне тасвирлый ул. М.Худяков, моннан тыш, аерым мөселман суфиларының марилар арасындагы ролен дә яктырта, Адай авылының суфие Шәех бабай (марича – Шиквава, русча – Иш-Мухаммед сын Тук-Мухаммеда) хакында да яза.

Зур Китәк авылы марилары һәм татарлар

Зур Китәк авылы турында аерым әйтеп узарга кирәктер. Риваятьләр буенча, бу җирдә башта татарлар яшәгән, соңрак алар Кукмара районындагы Адай авылына күчеп киткән. Бу урынга марилар килеп утырган. Киткәндә татарлар: «Киттек», – дигәннәр, шуннан бу сүз Китәк авылына исем булып күчкән, диелә риваятьтә.

Бу ике авыл арасындагы мөнәсәбәтләр соңрак та саклангандыр, күрәсең. Риваятьтәге бер вакыйга моңа дәлил булып тора. Җирле мариларның милли каһарманы Акбатыр исемен йөрткән. Мариларда Шиквава исеме белән билгеле Адай авылы суфие Шәех баба хакында искәртеп үткән идек инде. Риваять буенча, бу кеше, Казан шәһәре 1552 елда яулап алынгач, әлеге якларга кача. Ул монда мәктәп ача һәм ислам динен таратуга, җирле халыкларны агартуга үзеннән зур өлеш кертә. Аның мари малаен уллыкка яки кучер итеп алуы турында да мәгълүматлар бар. Тарихчы М.Худяков үзенең «Очерки Казанского ханства» дип аталган китабында Шәех баба белән Акбатырны бик җентекләп тасвирлый.

Адай авылында Алыплар турында бер борынгы риваять сакланган. Алыплар үзләренең чабаталарын какканнар һәм алардан коелган туфрактан зур калкулыклар (курганнар) ясалган. Алып образы мариларда да бик популяр. Аларда «Онарлар турында риваять» бар. Галим Марсель Әхмәтҗанов алыплар турындагы риваять мариларга татарлардан керә ала, чөнки әлеге тема төрки халыклар арасында киң таралыш тапкан дип саный.

Этнонимнарга, мари-татар мөнәсәбәтләренә килик. Татарлар мариларның ир-атларын – «чирмеш», хатын-кызларын «әкәй» дип атый. Бу терминнарның килеп чыгышы турында берничә фикер бар. Марсель Әхмәтҗанов язуынча, «чирмеш» безгә «сармат» дигән борынгы этнонимнан калган. Ә «әкәй» төшенчәсенә килгәндә, безнең фаразыбызча, бу сүз татарча «апа»ны аңлата. Ә «чирмеш» термины марины гына түгел, ә мәҗүси, татар булмаган халыкны да белдерә. Шуңа игътибар итегез: татарлар мари һәм руслардан кала башка халыкларны җенес буенча ир-атка һәм хатын-кызга бүлеп, аерым термин белән атамыйлар. Русларга – «урыс» (ир-ат), «марҗа» («Марья» исеменнән үзгәртелгәнгә охшаган) дип әйтәләр. Бу татарларның ике халык белән бик озак еллар тыгыз элемтәдә торуына дәлил.

Этнотерминнар. Җирле марилар татарларны «сясь» дип атыйлар. Фәнни әдәбиятта бу термин «суас» дип бирелә. Әүвәл бу «чуwаш»тан үзгәртелгән термин түгелме икән дип уйлаган идек. Әмма марилар чуашларны «суасла мари» дип атыйлар икән, ягъни «татарлашкан мари» яисә «марилашкан татар» килеп чыга. Дөрестән дә чуашлар, телләре буенча төрки саналсалар да, матди мәдәниятләре белән мариларга, фин-угырларга бик тартым. Алар, гәрчә фин-угырлар (марилар) белән бик тыгыз кушылган булсалар да, бик борынгы төрки халык була ала. «Суас» яисә «сясь» этнонимы да «чуваш»тан борынгырак термин. Аның Болгар чорында яшәгән «суасы» яисә «ас» кабиләләренә барып тоташуы мөмкин. Бу кабиләләр борынгы Болгар чорына караган чыганакларда искә алыналар.

Исем-фамилияләр. Мариларның иң борынгы исемнәре язып алынган җир Яңа Смәилдән 5-7 чакрым төньякка таба, Нократ елгасына якын урнашкан Иске Бөртек дип аталган мари авылына бәйле. Тарихчылар С.К.Кузнецов һәм М.Г.Худяковның билгеләп үтүенчә, бу бик борынгы, әле марилар аудан һәм урман җыючылыгыннан (гөмбә, җиләк, үлән җыю) аерылып, урман егып, аны яндырып, җир сөрә, иген игү белән шөгыльләнә башлаган чор булырга тиеш.

Мари кенәзләре Алтыбай, Урса һәм Ямшан батырлар хакында бер риваятьтә борынгы чорда мариларның игенчелек белән шөгыльләнер өчен җирне агачлардан арындырганда ерак арадан (риваятьтә 5 чакрым диелә) бер-берсенә балта атып уйнаулары бәян ителгән. Бу иң борынгы исемнәр мариларда татарларга хәтле булган дип, «бай» термины исә татар теленә якын дип әйтә алабыз.

Хәзерге мариларның исемнәре урысныкы белән охшаш. Аларда төрки тамырларны күрә алмыйбыз. Ә менә фамилияләрендә кайчак төрки тамырны шәйләргә мөмкин. Мәсәлән, Тилибаев. Бу татарча «тиле бай»дан түгелме икән? Хайваннар атамасыннан ясалган фамилияләр дә еш очрый. Мәсәлән, Зайцевлар. Чын мари сүзеннән ясалган фамилия берәү генә – Поткин. Үрдәкне марилар «потка» (утка) дип атыйлар.

Безгә билгеле булган борынгырак мари исемнәре турында берничә сүз әйтеп китик. Малмыж мари кенәзлегенең башлыгы Балтуш (марича әйтелеше – «Полтыш») исеме мари теленнән «алтын билбау» дип тәрҗемә ителә. Күз алдына Азелино кабиләләре ир-аты (сугышчысы) килеп баса. Аларның бизәнү элементы – бакырдан (җиз?) эретеп ясалган бик зур һәм авыр эполет сыман билбау каптырма-

Малмыж музееннан бер күренеш

Мариларның милли герое Акбатыр

лары бар. Чагыштырыр өчен Татарстанның Малмыж янәшәсендә урнашкан район үзәге Балтачны алыйк. «Балтач» һәм «Балтуш» сүзләре әйтелеше белән дә, арасы белән дә (40 чакрым) бик якын. Борынгы заман өчен нәкъ бер көнлек юл. «Балтач» атамасы тарихи чыганакларда сирәк очрый. Ихтимал, үз заманында рус гаскәрләренә каршылык күрсәткән өчен, Балтуш исеме тыелган булгандыр. Икенчедән, кайбер риваятьләрдә Малмыж мариларының иң соңгы гаскәри талпынышны шушы якка – Казан каласы ягына ясаулары сөйләнә. Тагын бер фикер: хәзер Балтачның район эмблемасы булып балталы аю тора, аны халыкта, шаяртып, «медведь на лесоповале» (урман егучы аю) дип атыйлар. «Балтачы» термины татарларда һәм төрки дөньяда киң таралган. Мәгънәсе дә аңлашыла – «балта остасы». Бу сүзне «балта белән эш итүче» дип карасак, эш коралын сугыш балтасына алмаштырсак, бик кызыклы образ барлыкка килә. Балтуш кенәзне сугыш балтасы (ярымай балта) яисә борынгы кельт балтасы белән бастырсаң, барысы да үз урынына урнаша.

Мариларның милли каһарманы Акбатыр исеменә игътибар итсәк, бу сүз татар теленнән үзгәрешсез алынган дип санарга була. Марилар үзләре «Ахпатыр» (мариларга авазларны саңгыраулаштырып сөйләшү хас) диләр. Русчага тәрҗемәсе «Белый богатырь» булып чыга. XX гасырның 70 нче елларында татар Сабан туйларында мариларның да батыр калганы булды. Мәсәлән, безнең якларда абыйлы-энеле Зайцевлар. «Ак» сүзе (сыйфат) төсне дә белдерә ала. Бер фараз буенча, Акбатыр ак киндер киемнән йөргән, шулай ук «ак» сүзе аксыл чәчле кешене дә аңлата ала һәм, өченче вариант, ак төс ислам динендәге кешегә хас. Шуны истә тотарга кирәк: «ак» – татар сүзе, ә мариларда «ак» «ош» дип әйтелә.

Аш-су. Мариларның аш-сулары турында мәгълүматыбыз күп түгел. Шулай да тутырма турында әйтеп китмичә булмый: аңа эчлек өчен кан белән дөге ярмасы алынган. Ислам дине канлы ризыкны катгый рәвештә тыя, ә марилар аны куллана. Ләкин кухняга бәйләнешле бер очракны әйтми китә алмыйм. Берзаман, 7 класста укыганда классташым, милләте буенча мари Сергей Бажанов: «Без Алдарда

кумыс ясадык, авылдашлар исерешеп беттеләр», – диде. Кымыз төркиләрнең милли эчемлеге булганга, бу бик гаҗәпләндерде. «Кумыс» булдымы икән ул, әллә инде «кумышка»мы (көмешкә), билгесез, әмма сүз сөттән ясалган эчемлек турында барды.

Кенәз Балтуш һәйкәле янында

Антропологик типлар. Җирле мариларның антропологик типларына да бераз тукталып үтик. Күзәтүебезчә, аларда төрле типлар очрый. Татарларга бик якын тип бар. Ә менә лопоноидлык – кысык күзләр мариларда күзгә бәрелеп тора. Татарлардагы монголоидлык күп очракта этногенез процессында эрегән җирле фин-угыр тәэсире дә була ала. Мәсәлән, кысык күзлеләргә авылда «Ябалак» дигән кушамат тагылган. Бу тип татарларга җирле фин-угырлардан да керә ала. Шулай ук монголлар яисә дала төркиләреннән килүе дә мөмкин.

Алдарак әйтүебезчә, лапоноид тип та бар. Алар эпикантус – кысык күзләр, тәннәренең пигментациясе кара-кучкыл яки бик кара. Кайвакыт татарлар арасында да шундыйлар очрый. Шулай ук европеоид, прибалт сары яисә җирән чәчле, сипкелле һәм очлы борынлы татарлар да бар.

Җирле халыклардан мариларда гына очрый торган бер үзенчәлекле типка игътибар итик. Алар – вак бөдрә чәчлеләр. Чәч төсе кара да, сары да яисә төссез дә була ала. Ә баш формалары озынча (фәнни термины – долгоцефаллар), иреннәре калын, тән пигментациясе дә каратут, негроид тип диясе килә. Археолог П.Н.Старостин бик борынгы чорда бу җирләргә Африкадан чыккан негроид расага караган кабиләләр үтеп кергән, ди, әмма чорны да, археологик культураны да атамый. Шундый гадәттән тыш теория бар, дип кенә билгеләп үтә. Икенче фикер дә бар: мондый тип якын туганнарның каны кушылудан килеп чыгарга мөмкин.

Җирле мариларның милли темпераменты турында сөйләгәндә аларның сугышка осталыклары хакында әйтми мөмкин түгел. Шул нисбәттән, рус кулъязмаларында сурәтләнгән һәм XVI гасырда үзенең төз атучы укчылары белән Мәскәү гаскәрләренә күп югалтулар китергән болын чирмешләре искә төшә. Мәсәлән, күрше удмуртларны алсак, алар марилар белән чагыштырганда бөтенләй тыныч. Сугышчан мариларны Балтуш кенәзнең Малмыжны яклап көрәшкән гаскәр калдыклары дип фаразларга була. Шулай ук җирле татарлар тәэсире булырга да мөмкин. 2015, 2016 нчы елларда Йошкар-Олада һәм Козьмодемьянскида узган фәнни конференцияләрдә катнашырга туры килде. Безнең җирле марилар белән чагыштырганда, анда яшәүче марилар тыныч холыклы, безнекеләр исә «усалрак».

Марилар урманны бик яраталар, анда үзләрен әйбәт хис итәләр. Ә безгә, татарларга – дала балаларына ачык җир кирәк. Марилар әйбәт аучылар һәм төз аталар. Кышын туңмыйлар, чаңгыда әйбәт йөриләр. Мәсәлән, безнең мәктәптә иң җитез чаңгычылар Китәк марилары иде. Аларның фольклорында шундый риваять бар: үз заманында мари илчеләре урыс патшасы янына (Мәскәүгә хәтле бит әле!) кышын чаңгы белән барып кайтканнар.

Татар-мари халкының милләтара никахлары, бик күптән якын яшәсәләр дә, күзәтелми диярлек. Монда милли үзенчәлекләр үзенең ролен уйнаган булса да, алгы планга дин чыккандыр дип уйлыйбыз: татарлар – мөселман, ә марилар, кагыйдә буларак, формаль яктан православлар, ә төптән алсаң – мәҗүсиләр.

Мәҗүсилек темасын карасак, Китәк тирәсе авылларында тарихи һәм этнографик материал бик бай һәм күп сакланган. Мәсәлән, танылган этнограф С.К.Кузнецов үзенең 1878 елда Санкт-Петербургта чыккан «Четыре дня у китякских марийцев» китабында җирле мариларның сыер чалу йоласын җентекләп сурәтләгән.

Азелино культурасы ядкяре – эполет сыман каптырма

Яңа Смәил мәктәп музее материалларыннан күренгәнчә, әле XX гасыр уртасына хәтле күрше мари авылы Айболатта (русча – Каменный Ключ) мәҗүси марилар яшәгән, аларны «чи мари» дип атап йөрткәннәр. Татарларда да «чи татар» дип әйтү бар, ләкин мәҗүси татарны күз алдына да китерүе кыен, бездә бу сүзтезмә «чын татар» дигәнне аңлата.

Җирле марилар рәсми рәвештә христиан динендә, ләкин әле дә мәҗүсилекнең калдыклары күп сакланган. Хәзерге заманда мариларның бер өлеше үзләренең мәҗүси диннәрен торгызу юнәлешен алды. Алар фикеренчә, бу юл милләтне эреп юкка чыгудан саклап калырга тиеш. Мәсәлән, югарыда әйтелгән Зур Китәк авылындагы Акбатыр кабере янында ел саен август башында мари җыеннары уза, биредә алар үзләренең мәҗүси келәүләрен үткәрәләр.

Гомумән, безнең якларда төрле ырымнарга ышану бик киң таралган. Мәсәлән, белүемчә, Татарстанның көньягындагы районнарда алай көчле түгел. Этнограф Н.А.Халиков фаразынча, бездә татарлар борынгыдан марилар белән янәшә яшәгәнгә шулайдыр. Җирле мариларда төрле сихерләү, бозым, күз тидерүләргә ышанулар көчле һәм без бу мәсьәләдә марилардан бераз шүрли дә идек. Татарларда исә дин көчлерәк. Белгәнебезчә, мөселманга ырым-шырымга ышанырга, багучыларга барырга, сихерчеләргә мөрәҗәгать итәргә һәм төрле «шайтаннар» белән аралашырга катгый рәвештә тыела. Шулай да мондый гөнаһлы гамәлгә керешеп киткән татарлар да шактый.

***

Бу мәкаләне әзерләгәндә, үземнең бер үк вакытта этнограф та, информатор да (этнографик чыганаклар бирүче) булуым кызык иде. Ләкин ролем ике кырлы: бер яктан мин мөһим, үземә кирәкле мәгълүматны аерып, сайлап ала алам. Икенче яктан, кайчак үзем дә искәрмичә, бу мәгълүматка йогынты да ясыйм.

Мәкаләнең ахырында бер фикеребезне язып үтик. Үз халкын өйрәнгәндә, этнографлар, тирә-юньгә карамыйча, шул даирәгә генә «чумалар», ягъни татар татарны өйрәнә. Ә кайвакыт чит кеше күзлегеннән карау файдалырактыр дип уйлыйбыз. Шул очракта берәр нинди мәсьәләнең, сорауның көтелмәгән чишелеше табылырга мөмкин. Бер халык телендә аңлашылмаган мәсьәлә – әйбер-термин икенче халык телендә, ягъни «читтә» бик җиңел чишелә. Мәсәлән, мариларның милли каһарманының исеме «Ахпатыр» – татар «Ак батыры»ннан, «сәник»ләре татар «сәнәг»еннән алынган булырга мөмкин. Татарларның «Балтач»ы мариларның «Балтушы» белән бер тамырдан була ала. Киләчәктә милләтара мөнәсәбәтләр темасы киңрәк яктыртылыр һәм күп нәрсәләргә ачыклык керер дип уйлыйм. ■

100 ел элек татар дөньясы

Оренбургтагы Татар институты бинасы (1922 ел), элеккеге «Хөсәения» мәдрәсәсе

Татар телен гамәлгә кую

Бик күп төрле чараларны гамәлгә кертер өчен халыкның күпчелеген тәшкил иткән милләт телендә эшли алырлык күп кенә мәдәни көчләр хәзерләргә кирәк. Шуңа күрә Татар телен гамәлгә кую комиссиясе аң-белем тарату мәсьәләсенә зур әһәмият бирә. Комиссия Татарстан Өлкә партия мәктәбе һәм коммунистлар университеты белән нык галяка *(берлек)* ясап эшли. Алар Татарстан Җөмһүрияте өчен партия һәм совет эшчеләре хәзерлиләр. Комиссия татар укучыларына ярдәм эшләре оештырды. Моның өчен төзелгән ярдәмче комиссия татар укучыларына ярдәм итәргә сумма табарга, алар өчен көтепханә тәшкил итәргә һәм штат кыскартылган мөәссәсәләрдә *(оешмаларда)* татар укучыларын урыннарында калдырырга тиешле чаралар күрә. Аннан соң комиссия татар телен өйрәнү курсы ачарга Мәгариф халык комиссариатына тәклиф кылды *(йөкләде)*.

Татарстан Җөмһүриятенең бер еллык гомерендә татар телен тәмамән гамәлгә куярга мөмкин булмады. Икенче елда моны эшләргә мөмкин иде, ләкин ашлык булмау сәбәпле, каты ачлык башланганлыктан, ул мәсьәлә икенче планга күчте.

Без узган елда Татарстан Җөмһүриятендә аң-белем тарату һәм башка эшләр белән шөгыльләнгән күп көчләрнең читкә таралганын күрдек. Шуңа күрә Татарстан Җөмһүриятендә калып эшләргә теләгән урыс эшчеләрен татар телен өйрәтә торган курсларга тиешенчә җәлеп итәргә мөмкин булмады. Татар телен өйрәнергә теләүчеләр өчен беркадәр генә курслар ачылды.

Ләкин анда да уку мәҗбүри ясалмады. Шулай булса да, ул вазыйфа икенче уңайлы вакыт килгәнгә кадәр кичектерелде һәм без ул уңайлы вакыт бу көз килер дип өмид итәбез.

«Татарстан». – 1922. – 1 август.

Көтепханәгә *(китапханәгә)* эшчеләр хәзерләү курслары

1921 елдан бирле Татар җөмһүриятенең бәгъзе бер кантоннарында татар көтепханә эшчеләре хәзерләү курслары ачылган булса да, бердән, аларның бик кыска мөддәтле – 2-3 атналык кына булулары, курста үтәргә тиешле фәннәрнең иң кыска, иң тар рамкада үтелүе, көтепханә эшләре белән өстән генә, назари гына таныштырылуы аркасында ул курсларның практический файдалары бик аз булды.

Икенчедән, ул курсларда укыр өчен кешеләр җибәрү эшләренә әһәмият бирелмәү, кем туры килсә шул кешене, аның аң-белеме дә ни дәрәҗәдә булуына карамастан, курска җибәрүләр һәм шуның аркасында курска җибәрелгән курсантларның аң-белеме дә бик төрле дәрәҗәдә булулары, күбесенең көтепханә эшчесеннән таләп ителгән белемнең аз гына өлешен дә тота алмаулары – менә болар һәммәсе татарлардан көтепханә эшчеләре хәзерләргә бик зур киртә булып килделәр.

Татарлардан курска 15 кешедән дә артык укучы алынмаганга, кантоннар үзләренә билгеләнгән разверстка буенча, иң ышанычлы, иң хәзерлекле авыл яшьләрен җибәрергә тиешләр.

Татар Җөмһүрияте көтепханәләре мөдире Г. Акбулат.

«Татарстан». – 1922. – 1 август.

Татарлар институты

Бу ел кыш үткән елдагы кебек Шәрык институты (элекке «Хөсәения» мәдрәсәсе) ачылып укулар дәвам итте. Бу татар институтында июнь башларына кадәр укулар барды, йөзгә якын шәкерт укып чыкты. Соңгы вакытта аны рус институтына катнаштырып параллель ясау фикере кузгалып тора. Мәркәздән хөкүмәт челтәренә кертелү сорала. Бу ел бу институтны 9 кеше бетереп чыкты. Бер татар техникумы бар иде, ул русларныкы белән бергә кушылды. Шәһәрдә алты балалар йорты дәвам итә.

«Эшче». – 1922. – 12 август.

Шәрык музыка мәктәбе

Башта Оренбург татар яшьләре һәм приказчиклары тарафыннан ачылган бу мәктәп электә бик яхшы гына дәвам итеп килә иде. Татар-башкорт галәмендә бердәнбер башлангыч булган бу мәктәп, яңа икътисади сәясәт чыгу аркасында, хөкүмәттән тыш эшли башлаган иде.

Казакъстан мәгариф комиссариаты, бу мәктәпнең шәрык халкы арасында бердәнбер рассадник булганлыгы өчен, аның икътисади якларын яхшырту нияте белән, аны үз карамагына алды һәм юлга салып җибәрде. Хәзердә яхшы гына рәвештә дәвам итә. 80гә якын музыка өйрәнүчесе бар.

«Эшче». – 1922. – 12 август.

*Сәхифәне **Рәйсә Шәрәфиева** һәм **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Безнең мирас №8 август 2022

ТАТАР ХАННАРЫ

Касыйм хан

(1440 нчы еллар ахыры-1469)

Касыйм ибне Олуг Мөхәммәд – Касыйм ханлыгының беренче хөкемдары, Казан ханы Олуг Мөхәммәднең улы. Ил белән ул 1452-1469 нчы елларда идарә итә.

Җитез чиркәс егетләреннән гаскәр туплавы

Хан булганчы, Касыйм, әтисе Олуг Мөхәммәд җитәкчелегендә, 1437 елда – Биләү (Белев) һәм 1445 елда Суздаль сугышларында катнаша. Ике сугышта да мәскәүлеләр җиңелә, кенәз Василий II (Сукыр Бәчили) әсир төшә, соңрак азат ителә. Суздаль сугышыннан соң төзелгән шартнамәнең үтәлешен күзәтү өчен, Касыйм туганы Якуб белән Мәскәү кенәзлегенә – Василий II сараена күчеп китә. Шулай итеп, аңа сарайда җайлап кына мәскәүлеләрнең «эченә үтеп керергә», аларның ышанычын яуларга мөмкинлек туа. 1446-1452 нче елларда кенәз аңа Мәскәү янындагы Звенигород шәһәрен бүләк итә. Кавказ тауларыннан, Цемес бухтасыннан анда китерелгән чиркәс казакларының станицасы турыдан-туры Касыймга буйсына башлый, аның кул астына җитез, гаярь егетләрдән генә торган хәрби көч туплана.

Касыйм ибне Олуг Мөхәммәд (1440 нчы еллар ахыры-1469). ***П.А.Панкин коллекциясеннән. Рәсем «Касимовские ханы и султаны» исемле календарьдан (редакторы – Д.В.Мөхетдинов) алынды.***

1449 елда Касыйм, Василий IIгә итагатен белдереп, Мәскәү тәхетенә дәгъва кылган Дмитрий Шемякка каршы сугыша. Соңрак ул Пахра елгасы буена килгән Олы Урда ханы Сәед Әхмәдне тар-мар итә һәм аның мал-мөлкәтен тартып ала. 1450 елда Галич янындагы сугышларда катнашып, Битюг елгасы буенда Руська һөҗүм белән килүче Мәүлим бирде углан гаскәрен кырып сала.

Касыймның хан булуы һәм Казан тәхетенә дәгъвасы

1452 елда Василий II аңа Рязань кенәзлеге янындагы Мишәр йортын (Мишәр шәһәрен) – хәзерге Касыйм шәһәре янындагы Городец Мещерскийны бирә. Шулай итеп, татар тарихында мәгълүм булган Касыйм ханлыгына нигез салына. Яңа сәяси берлек Мәскәү кенәзлегенең вассал дәүләте буларак яши башлый.

1467 елда Мәскәү тарафдары булган Казан кенәзләре аны яшерен генә Ибраһим хан урынына чакыралар. Чөнки Касыйм 1465 елдан соң, шул чордагы гадәт буенча, абыйсы Мәхмүднең тол калган хатынына – Казан ханы Ибраһимның әнисенә өйләнә. Кайбер казанлылар фикеренчә, аның Казан тәхетенә утырырга хакы күбрәк була.

1467 елның 14 сентябрендә Мәскәү кенәзе Иван III ярдәмендә тупланган һәм Касыйм хан җитәкләгән гаскәр Зөя елгасы тамагына килеп җитә, әмма Ибраһим ханның каршылыгына очрап, Иделне кичә алмый. Әлеге вакыйга татар халкы тарихына Беренче Казан-рус сугышының (1467-1469) башлангыч вакыйгасы буларак кереп калган. Озак та үтми, Касыйм хан вафат була. Хатыны исә Казанга – улы Ибраһим хан янына кайтып китә.

Мәшһүр тарихчыниләр яза?

Тарихчы В.В.Вельяминов-Зерновның «Исследование о касимовских царях и царевичах» исемле китабында Касыйм ханга кагылышлы менә нинди юллар язылган: «Осенью 1445 г. сложилось царство Казанское… Об эту пору в земле Черкасской появились два брата, сыновья Улу-Мухаммеда — Касим и Якуб…

Факты за период времени от 1446 до 1452 г. ясно свидетельствуют о том, что Касим и Якуб первые шесть лет по приезде в Россию прожили с выведенными ими татарами у нас. Состояли же они, как видно, на службе у великого князя, который употреблял их в случае надобности: то брал с собою в походы, то посылал против врагов внутренних и внешних. После 1452 г. сведения о Касиме становятся весьма скудны… Между тем об эту пору совершилась в жизни Касима перемена, не только имевшая влияние на судьбу его, но даже, в некоторой степени, важная для России. Касим получил от великого князя Московского Городец (Городок Мещерский) на берегу реки Оки в Рязанской области. В действительности этого пожалования, хотя и нет на него прямых доказательств, сомневаться нельзя. В пользу его говорят: и нынешнее название Городца, переименованного (если не при самом Касиме, то, вероятно, вскоре после него) в честь царевича в Касимов; и народное предание, живо сохранившееся доселе в памяти жителей города из татар; и …некоторые имеющиеся на то косвенные письменные указания. Пожалование же Касиму Городца положило начало образованию внутри самой земли Русской удельного Татарского ханства, которое, состоя в прямой зависимости от наших государей, поддерживалось более 200 лет…

Вся местность крутом его [города Касимова] в Рязанской области была с давних пор заселена мордвою и Мещерою (отчего и самый Городок, в отличие от других, звался Мещерским), исповедовавшими частью язычество, частью, вследствие близких сношений с мусульманами, — мухаммеданство; инородцев этих, скорее, нежели русских, можно было отдать в управление татарину и мусульманину».

*Текстны басмага **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Без татар халкына карашны үзгәрттек

Минтимер Шәймиев, Татарстан Республикасының Беренче Президенты

ТР Президенты Минтимер Шәймиев Бөтендөнья татар конгрессының икенче корылтаенда чыгыш ясый. 1997 ел

Моннан 30 ел элек без Бөтендөнья татар конгрессын төзүнең максатын Дәүләт суверенитеты турындагы декларация кабул итүгә, республиканың статусы турында референдум үткәрү нәтиҗәләренә бәйле рәвештә, Татарстанның илкүләм һәм дөньякүләм позициясен, татарларның БДБ һәм Россия халыклары арасында тоткан урынын аңлату дип билгеләгән идек.

Ул вакытта Татарстанда һәм аның тирәсендә ниләр барганын күз алдына китерик: чикләр ачылды, кешеләр бер-берсе белән аралаша башлады. Татарлар бөтен дөньядан республикага омтылды. Төрле илләрдәге татар диаспоралары Татарстанга үз теләкләрен һәм таләпләрен җиткерде: татар телендә китапларны, журналлар һәм газеталарны күбрәк бастырырга, дәреслекләр һәм башка кирәкле әсбаплар белән тәэмин итәргә кирәк. Читтән «милли басым» көннән-көн ныграк сизелә барды. Җыелып сөйләшү-аңлашу гаять зарур иде.

Бер караганда, барысы да аңлашыла кебек: Конгресс – дустанә очрашулар, бәхәсләр, республикада һәм аннан читтә яшәүче татарларның проблемалары турында фикер алышу урыны. Әмма Бөтендөнья татар конгрессы корылтаен уздыру барысының да күңеленә хуш килмәде. Шунысын әйтергә кирәк, Мәскәүдәге кайбер рәсми затлар форумны үткәрүгә комачаулап маташтылар: мәсәлән, чит илдән килүчеләргә виза бирәселәре килмәде яки федераль Үзәк кинәт кенә, Конгресс утырышларын татар телендә үткәрмәскә, дип, үз «теләген» белдерде.

Беренче корылтай бөек Тукай шигыренә халык көй чыгарган «Туган тел»не җырлаудан башланды. Бу җыр, кайда тууларына, кайда яшәүләренә карамастан, гомер-гомергә барлык татарларны берләштерә. Аны бөтен татар белә һәм иң тантаналы, иң дулкынландыргыч мизгелләрдә башкара. Мин бу мизгелне мәңге онытмам: җырны бөтен зал, сөенечле күз яшьләрен яшермичә, бер зур хор шикелле, бер сулышта җырлады. Бу безнең барыбыз да озак көткән мизгел – берләшү, горурлану һәм очрашу шатлыгы мизгеле иде! Дөресен генә әйткәндә, бу җырны башкару нияте бөтенләй юк иде. Күңелебез кушканга шулай килеп чыкты – күрештек тә, җырлый башладык...

Мин барыбер татарча чыгыш ясадым, чөнки чит илләрдән килгән татарлар рус телен белми, әмма күбесе ана телебезне саф килеш саклаган. Дөньяның бөтен почмакларыннан безгә җыелган татарлар үзләрен тарихи ватаннарында чын хуҗа итеп сизәргә тиеш иде. «Бу Конгресс бөтен дөнья татарларын берләштерүче һәм бөтен татарлар исеменнән рәсми белдерүләр ясарга сәләтле зур мәҗлес булырга тиеш», – дип белдердем. Йөзләгән делегат минем сүзләрне алкышлап хуплады. Шуннан соң бер шигем дә калмады: без барысын да дөрес эшлибез. Без тулаем татар милләте турында уйларга, Татарстан бөтен татар диаспораларын берләштерү вазыйфасын үтәргә һәм Россиянең милли сәясәтенә уңай йогынты ясарга тиеш, дигән фикергә килдек. Конгресс, утыз ел дәвамында, чынлап та, эзлекле рәвештә, шушы сыйфатта эшләп килә.

Беренче корылтай барыбызга да көчле этәргеч бирде. Аны уздырганнан соң, без, кайда яшәвенә карамастан, барлык татарлар мәнфәгатен кайгырткан мөһим чаралар күрүгә керештек. Татарстан Республикасының шул ук елның ноябрь аенда кабул ителгән яңа Конституциясендә махсус 14 нче маддә барлыкка килде. Анда: «Татарстан Республикасы Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче татарларга милли мәдәниятне, телне үстерүдә, аларның үзенчәлекләрен саклап калуда ярдәм күрсәтә», – дип язылды.

Ул елларда Татарстан тотрыклы үсеш чорына аяк басты. Федераль үзәк белән Шартнамә төзелде. Дөньяның кайбер илләрендә республиканың вәкиллекләре

Җитди мизгел. ТР Президенты Минтимер Шәймиев, РТ вице-президенты Василий Лихачев, ТР Югары Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Бөтендөнья татар конгрессы рәисе, академик Индус Таһиров. 1997 ел

барлыкка килде. Алар, икътисади хезмәттәшлек урнаштыру белән беррәттән, татар иҗтимагый оешмаларына ярдәм итә башлады. Татарстан, БДБнең һәм Россиянең төрле республикалары һәм өлкәләре белән килешүләр төзегәндә, форсаттан файдаланып, шул өлкәләрдә яши торган татар халкы мәнфәгатьләрен күздә тотты. Безнең әлеге юнәлештә фикеребез билгеле һәм ул хәзер дә үзгәрми: татар кешесе үзе яшәгән, эшләгән һәм салымнар түләп барган җирдә үзен иркле хис итәргә, телен, гореф-гадәтләрен, динен саклау өчен кирәкле мөмкинлекләргә ия булырга тиеш. Бу исә татарларга БДБ илләрендәге, Россиядәге тупланып яшәү урыннарында тормышларын үзләренчә җайларга мөмкинлекләр ачты. Без моның белән үзебезне бердәм халык итеп күрсәттек. Татар телен, мәдәниятен, ислам динен торгызу башланды. Нәкъ менә шул чорда, республикада төпле милли сәясәт һәм икътисад реформаларын гамәлгә ашыруның халыкка кулай юлларын сайлау нәтиҗәсендә, Татарстанның абруе күтәрелде. Ә иң мөһиме – хакимият структураларында һәм башка халыкларда безнең милләткә карата ихтирам артты.

Дөресен әйтик, совет заманында да, аннан элегрәк тә идеология, тарих дәреслекләре татар-монгол золымына бәйле рәвештә татарларга карата үтә тискәре мөнәсәбәт белән сугарылган иде. Без татарларның тынычлык сөючән, иҗтиһад итә торган милләт, аеруча үзгәртеп кору елларында Россия Федерациясенең бөтенлеген саклап калуда зур роль уйнаган халык икәнен күрсәттек. Үзгәртеп кору елларыннан башлап үткәргән төпле сәясәтебез нигезендә, без татар халкына тискәре карашны, тарихи вазгыятьне үзгәртә алдык.

Һәм без шул чакта ук үз тарихыбызны яңадан барлап, хак тарихыбызны язу эшенә керештек. Әлбәттә, һәр халык үз язмышына, үз тарихына бик сизгер, сак карый, әмма бу эштә төп алым – гадел караш булырга тиеш иде. Ун елдан соң «Татарларның борынгы заманнардан башлап язылган тарихы» дигән күләмле – җиде томлы хезмәтнең беренче томы дөнья күрде. 2013 елда аның ахыргы – җиденче томы чык-

Биюле мизгел. 1992 ел

Бөтендөнья татар конгрессының беренче корылтае делегатлары Изге Болгар җирендә. 1992 ел

ты. Бу Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты, аның җитәкчесе Рафаэль Хәкимов һәм аның шәкертләре тарафыннан, республика җитәкчелеге ярдәмендә эшләнде. Ул республика өчен генә түгел, гомумән, фән дөньясы өчен дә зур вакыйга булды. Әлеге эшкә Россия Фәннәр академиясе, чит ил галимнәре һәм, әлбәттә, үзебезнең Тарих институты алынуы дөрес гамәл булды.

Шунысын да әйтергә кирәк: соңгы елларда Россия Федерациясе тарихи дөреслекне кайтару мәсьәләләрендә бик зур әһәмияткә ия сәясәт алып бара. Без моны бүген көндәлек хезмәтебездә бик ачык күрәбез.

Әмма хак тарихыбызны язу белән генә чикләнеп калмыйча, алга таба аны дөньяга тарату, иң мөһиме – таныту зарур иде. Бу юнәлештәге эшне без, барыбыз бергә тотынып, махсус «Яңарыш» фонды булдырып дәвам иттек. Борынгы Болгар шәһәрен торгыздык, аннары аны ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертүгә ирештек. Шуның белән без тарихи-мәдәни мирасыбызны тергезеп, аны фәнни-тарихи яктан дәлилләп, үз тарихыбызның халыкара танылуына ирештек.

Шул ук вакытта бу вакыйга, нигездә, мөселманнар булган татар халкы өчен бик кадерле, истәлекле датаны дәүләти югарылыкка күтәрүдә төп роль уйнады. Ата-бабаларыбызның 922 елда Болгар җирендә, хәзерге Россия биләмәсендә беренче булып ислам динен кабул итүе факты, дөньякүләм расланып, кешелек тарихына теркәп куелды. Мәгълүм ки, быел без Идел буе Болгар дәүләтенең Ислам динен ирекле һәм рәсми төстә кабул итүенә 1100 ел тулуны ил күләмендә бәйрәм итәбез.

Сүз дә юк, татар милләтенең гасырлар буе җыелган проблемаларын утыз ел дәвамында гына хәл итү мөмкин түгел, өстәвенә, һәр заман алдыбызга үз таләпләрен куя. Шуңа да карамастан, утыз ел элек билгеләнгән кыйблабыз, нигездә, үз көчендә: милләтебезне исән-имин килеш саклап калу, үстерү һәм киләчәген кайгырту – безнең изге бурычыбыз!

Бөтендөнья татар конгрессына, гомумән, барлык милләттәшләребезгә шушы игелекле юлда уңышлар һәм көч-дәрман телим! ■

Безнең мирас №8 август 2022

Васил Шәйхразыев: «Һәр татар кешесе өчен Татарстан – туган як»

(Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисе Васил Габделгаяз улы Шәйхразыевның «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат конференциясендә (22 июль, 2022 ел) әйткән кайбер фикерләре)

Васил Шәйхразыевның Тукай районының Яңа Бүләк авылында Илһам Шакировка багышланган бюст ачу тантанасында чыгыш ясаган мизгеле. 9 сентябрь, 2020 ел.
Салават Камалетдинов фотосы

«Үткән биш ел эчендә безнең өчен иң мөһим вакыйга «Татарлар: гамәл стратегиясе»ен кабул итү булды. Шуны гамәлгә ашыру юнәлешендә эш башланды. Икенче зур вакыйга – ТАССР оешуның 100 еллыгы. Без аны Татарстанда гына түгел, башка төбәкләрдә дә зурлап бәйрәм иттек. Дөньяда яшәүче һәр татар кешесе өчен Татарстан – туган як, туган җир дигән төшенчәне булдыра алдык. Дөрестән дә, Татарстан – татар телен һәм мәдәниятен үстерүнең, татар халкы бердәмлеген саклауның тарихи үзәгенә, ә меңьеллык башкалабыз Казан татарларны үзенә тартып торучы милли мәдәни үсеш мәркәзенә әверелде».

«Кая гына барсам да: «Татар-мөселман цивилизациясе!» – дип горурланып сөйлим. Үзебезнең оешма җитәкчеләре, мәктәп-мәдрәсәләрдә укучылар белән очрашканда да халкыма татарлык һәм мөселманлык рухында берләшергә кирәклеген искәртәм».

«Безнең алда күп бурычлар бар. Әмма милләтебез алга таба барсын өчен, тәрбия һәм милли рух иң беренчел бурычларның берсе булырга тиеш. Хәзерге вазгыять шартларында башкарылмаган нинди милли эшләребез бар? Шуларны бар-

Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының VIII Бөтенроссия съездында татар теле дәреслекләрен тәкъдим итү. 29 июнь, 2022 ел.
Салават Камалетдинов фотосы

лар өчен, күптән түгел генә Татар теле укытучылары съезды уздырдык. Татарстандагы һәм республикабыздан читтәге татар мәктәпләрен һәм классларын дәреслекләр белән тәэмин итәбез. Дөрес, ФГОС кабул ителгән. Шуның нигезендә татар халкы гына түгел, барлык милләтләр дә үз эшләрен алып баралар. Анда бирелгән вакыт безгә җитәме, әллә җитмиме? Җитми икән, нәрсә эшләргә була? Факультатив дәресләр, якшәмбе мәктәпләре, «Ана теле» онлайн мәктәпләре – барысы да Россия күләмендә эшләп килә. Ә күпме әти-әни балаларын татар классларына бирде?! Татар теленнән БДИ тапшыручы бармы? Хәзерге көндә ТР Мәгариф министрлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы белән берлектә, халыкның теләкләрен истә тотып, канун нигезен эшләргә тиеш. Дөрестән дә, халыкка нидер җитми икән, алга бурычлар куеп, киләчәккә бару юлларын эзләргә кирәк. Законнарның үзгәргәнен көтеп тормыйча, мәктәпне бетергәнче үк, балаларыбыз өчен туган телне саклау юнәлешендә уңай шартлар булдырырга мөмкин. Теләк кенә булсын! Ә теләк тусын өчен, без яңа һәм кызыклы проектлар тәкъдим итәргә тиеш».

«Узган ел җанисәп алу уңаеннан, Башкортстандагы югары уку йортларының татар бүлекләрендә, татар мәктәпләрендә булдым. Башкортстанда татарга уңай мөнәсәбәт, туган телне укыту, ресурс үзәкләре ачу кебек эшләр урынынннан кузгалды. Андагы җирле җитәкчеләребезгә дә җитди бурычлар куелды. Артистларыбыз да концертлар куя, укытучылар белән дә аралашабыз. Ике бертуган халык арасына чөй кыстырмыйча, тагын да алга барып, татар теленең дә, башкорт теленең дә үсешенә юл салырга тиешбез».

«Күп өлкә һәм шәһәрләргә барсам: «Татар мәчете», «Казан мәчете», «Бу мәчетне 100 ел элек татарлар салдырган», – дип сөйләгәннәрен еш ишетәм. Мәчетнең имамнары да элек татар булган, әмма соңгы елларда башка милләт кешесе имам итеп сайланган. Шундагы татарлар: «Имам безнең кеше түгел шул. Ничек татар имамы куярга?» – диләр. Имам сайланып яки җирле җитәкчеләр ярдәмендә куела. Әгәр дә безнең мәчетләрдә татар имамнары булса, без, Бөтендөнья татар конгрессы тарафыннан, ул имамыбызны һәрвакыт яклый, аңа ярдәм күрсәтә, хәтта үзебезнең кешеләрне дә имам итеп тәкъдим итә алабыз. Мәдрәсә бетергән белемле имамнарыбыз җитәрлек.

Дөрес, башка милләт кешеләре дә татар файдасына эшләргә мөмкин. Мәсәлән, Әстерханда татар җанлы казакъ кешесе мөфти итеп сайланды. Ул татарларга зур ихтирам-хөрмәт белән карый. Күп эшләрдә татар халкын алга чыгарып, безнең милләткә хезмәт кыла. Бүтән милләт кешесенең шундый дәрәҗәгә ирешеп, татар халкын хөрмәт итүе – безнең өчен дә мәртәбә. Әстерхан шәһәрендә тарихи татар мәчетләре күп, аларда Казаннан, Татарстаннан күчеп киткән имамнар да эшли». ■

Безнең мирас №8 август 2022

Татар конгрессы: тәүге адымнар

(«Татар конгрессы туа» дигән истәлек-язмадан өзек)

Индус Таһиров, академик, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының 1992-2002 нче еллардагы рәисе

ТР Президенты Минтимер Шәймиев һәм Бөтендөнья татар конгрессы рәисе, академик Индус Таһиров. 1992-2002 нче еллар

Мин инде күпмедер рәвештә Бөтендөнья татар конгрессы, аның эшчәнлеге турында әйтә килдем. Хәзер исә аның барлыкка килүен һәм кайбер гамәлләрен искә алып китәр вакыт җитте.

Билгеле булганча, сиксәненче елларның ахырында ук, үзгәртеп кору дулкынында, СССРның төрле төбәкләрендә милли оешмалар барлыкка килде. Аларның төп максатлары телебезне, гореф-гадәтләребезне, гомумән, милли яшәешне тулысы белән аякка бастыру иде. Шушы нигездә Марат Мөлеков җитәкчелегендә Бөтендөнья татар иҗтимагый үзәге (БТИҮ) оешты. Ул үзенең төп максатларының берсе итеп Татарстаныбызны союздаш республика итеп үзгәртүне билгели. Ни кызганыч, шушы саф зат арабыздан вакытсыз китеп барды. Аның болай да яралы йөрәге үзенә төрле яктан ябырылуларга түзә алмады.

Конгресс шушы уңай җирлектә барлыкка килде. Аның идеясен күтәреп чыгучыларның берсе депутат, күренекле шагыйрь, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Ренат Харис булды. Без аның белән һәрвакыт дустанә мөнәсәбәттә һәм фикердәшләр идек. Һәм шулай булып калабыз да. Аның шушы Конгрессны оештыру кирәклеге турындагы хаты Президентыбыз өстәленә ятты. Минтимер Шәриповичка бу идея бик ошады һәм эш башланып та китте.

Бөтендөнья татар конгрессының тууы чын мәгънәсендә тарихи вакыйга булды. Ул татар милләтенең халәтен, яшәешенең төп проблемаларын күрә алды.

Ун ел буе – 1992 елның июненнән 2002 елның августына кадәр Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының рәисе булып тордым. Үземә йөкләнгән вазыйфаны башкарганда бик күп кешеләр белән аралашып яшәргә туры килде. Аларның үзем өчен иң якыннары һәрвакыт янымда булдылар. Болар – рәис урынбасарлары: «Сөембикә» журналының баш редакторы, «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасын бар итүче Роза ханым Туфетулова, «Азатлык» радиосының Казан бюросы җитәкчесе Римзил Вәлиев, Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комиссиясе җитәкчесе, депутат һәм әдип Разил Вәлиев. Конгресс бюросының составында Татарстан Фәннәр Академиясенең президенты Мансур Хәсәнов, республиканың мәгәриф министры Фарис Харисов, мәдәният министры Марсель Таишев, матбугат министры Ислам Әхмәтҗанов, Тарих, тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, профессор Мирфатыйх Зәкиев, ГТРК «Татарстан» рәисе Илшат Әминев бар иде.

Башкарма комитет үзенең эшен татар халкының санын, милли холык-фигылен һәм сыйфатларын, шөгылен, төбәк үзенчәлекләрен эченә алган концептуаль нигездә алып барды. Ул, татарларның, кайда яшәүләренә карамастан, сулышын тоеп, бер тән, бер җан булып яши башлауларына нигез салды, Татарстанның мөстәкыйльлеген ныгытуга үз өлешен кертте.

Аппаратыбыз бик аз санлы иде. Аның җитәкчесе моңа кадәр мәдәният министрының урынбасары булып эшләгән Лилия ханым Нарбекова иде. Милли эшләребезгә җаны-тәне белән бирелгән җиң сызганып эшләгән Тәэминә ханым Биктимирова. Барлык көндәлек эшләребезне, бигрәк тә төбәкләрдәге татар оешмалары белән мөнәсәбәтләрне алар җайга салды. Монда Роза ханымның эшчәнлегенә махсус бәя бирү кирәктер. Ул, «Ак калфак»ның җирле оешмаларын төзеп, Конгресс эшчәнлегенә бик күп татар хатын-кызларын җәлеп итә алды.

Роза ханым татар гаиләсенә, татар анасына, бала тәрбияләү һәм үстерүгә багышланган дистәләрчә күркәм бәйгеләр үткәрде. Гомумән, Конгресс эшен җайга салуда гүзәл затларыбызның роле бик зур булды. Без рәсми рәвештә дә, гадәти көннәрдә дә очрашып сөйләшеп тордык, барлык проблемаларны бергә хәл итә килдек.

Шагыйрь Разил Вәлиев (сулда), журналист Римзил Вәлиев һәм академик Индус Таһиров

Республикабызның халыкара мәйданга чыгуында, аның эчке һәм тышкы эшләрендәге казанышларында Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең өлеше гаять зур. Бу шәхесне бөтен дөнья белә һәм таный. Аның исеме дөньядагы иң мәшһүр татарлар исемлегендә. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты һәрдаим аның ярдәмен тоеп торды. Дәүләт Советы, Министрлар Кабинеты, аның каршындагы Баш Архив идарәсе, министрлыклар, Фәннәр Академиясе дә безгә игътибарлы булды.

Эшчәнлегебезнең иң нәтиҗәле ысулы – Башкарма комитет тарафыннан уйлап табылган һәм дөреслеген тормыш үзе раслаган күчмә утырышлар турында сөйләү урынлы булыр. Без аны Татарстан җирлегендә – Түбән Камада башлап җибәрдек. Ул мәдәният, мәгариф, гомумән, татарның яшәеше турындагы утырыштан зур җәмәгатьчелек җыелышына, хәтта фәнни киңәшмәгә әверелде. Аның үтемле чара булуы расланды. Шуннан соң, Татар конгрессы – җирле хакимиятне татар җәмәгатьчелеге белән килештерә алучы көч, дигән фикергә килдек. Икенче күчмә утырыш Екатеринбург шәһәрендә үтте. Ул хакта инде мин элегрәк тәфсилләп язган идем.

Сарытау, Самара, Оренбург шәһәрләрендә һәм күп кенә район авылларындагы татар мәктәпләре Конгрессның, аның вәкилләренең ярдәмен тоеп яшәде. Самара өлкәсендә бу эшләрне Башкарма комитет әгъзасы, инде мәрхүм Равил абый Яһудин башкара иде. Ул, авылларны әйләнеп, татар мәктәпләренең хәлләрен аныклап, мәсьәләне өлкә җитәкчеләре алдында кабыргасы белән куя белде.

Шушы елларны Татарстан Мәгариф министрлыгының 18 өлкә белән килешүләр барлыкка килде. Бу зур эшләрне башкаруга ул вакыттагы мәгариф министры Фарис Фахраз улы Харисов зур өлеш кертте. Әгәр дә без Россия төбәкләрендә бары тик 232 446 укучысы булган 1638 татар мәктәбе генә эшләп килгәнлеген һәм биредә милләтебезнең күпчелеге яшәгәнлеген искә алсак, моның ни дәрәҗәдә мөһимлеген аңларбыз.

Без татар мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруда төбәк башлыклары белән аңлашып яшәүне максат итеп куя идек. Шунлыктан, мин аларның кайберләре белән эшләвебез турында мәгълүмат бирүне урынлы булыр дип саныйм.

Аларның берсе – Сарытау өлкәсенең губернаторы Дмитрий Федорович Аяцков. Аның кайсыдыр бабасы мәчетләрдә Коръән аятьләрен укучы татар булган, дип сөйлиләр. Анысы дөрестерме-юктырмы, әмма ул татарларга бик җылы карашта торган кеше. Милләттәшләребез аны шулай ук яратып һәм ярдәменә өметләнеп, Дамир Фатыйхович дип кенә йөрттеләр. Аңа бу бик тә ошый, шулай дип дәшкәндә йөзе балкып китә иде. Татар бәйрәмнәрендә аның башында кәләпүш булыр иде. Гомумән, ул татар мәнфәгатьләренә игътибарлы булды, татар гимназиясен аякка бастыруга да үз өлешен кертте. Дмитрий Аяцков 1998 елны татар җәмәгатьчелеге белән очрашуы вакытында, быелгы уңыштан гимназиягезгә өлеш чыгачак, дип ышандырган һәм, нигездә, вәгъдәсен үтәгән. Нәтиҗәдә, гимназиягә үзе урнашкан бинаның тагын бер каты бирелде.

Аның белән миңа бик еш очрашып, озаклап сөйләшеп утырырга туры килде. Шул очрашуларның берсе кайчандыр Сарытау урынында урнашкан Үкәк исемле татар каласының 600 еллыгына багышланган, профессор Фрид Рәшитов җитәкчелегендәге конференция вакытында булды. Анда миннән башка тагын профессор Әзһәр Мөхәммәдиев тә чыгыш ясады. Шуннан соң әлеге кала урынына һәйкәл өчен таш кую тантанасы булып үтте. Шул көнне хәтердә яңартып үтәм.

Идел буе тулы халык. Митинг башланды. Чыгыш ясаучылар арасында профессор Фрид әфәнде Рәшитов җитәкчелегендәге берничә галим, күренекле эшмәкәрләр. Музыка яңгырый. Янымда басып торган Айдар Фәйзрахманов микрофон янына килеп баса да «Идегәй» дастаныннан «Идел-йорт»ны җырлап җибәрә. Аяцковка карыйм. Йөзе җитди, күзләрендә хәтта яшь тә җемелди сыман.

Бу кеше Татарстанны ярата, Казанга сокланып карый. Шәймиевкә мөнәсәбәте аеруча җылы. Бервакыт Казанга килгәч, хөкүмәт залындагы очрашу вакытында ул, тирә-якка күз ташлап: «А где же мой друг?» – дип сорады. Ә мине күргәч: «А вот он!» – дип килеп кочаклап та алды.

Миңа, Аяцков губернаторлык постыннан киткәч тә, аның белән берничә мәртәбә очрашырга туры килде. Ул – һаман да шул Аяцков.

Санк-Петербургның туксанынчы еллардагы губернаторы В.А.Яковлевны әле дә җылы хисләр белән искә алам. Бу кеше һәрвакыт Татарстан һәм татарлар белән махсус мөнәсәбәттә торды. Россиянең икенче башкаласын җитәкләү аңа җиңел булмагандыр, бигрәк тә Собчактан соң. Ә Собчак – мәгълүм ки, В.В.Путинның укытучысы. Путин аны һәрвакыт зур хөрмәт белән искә ала. Яковлевның көндәшләре, шуннан файдаланып, Путин исеменә аның өстеннән шикаятьләр яудырып торды. Һәм Яковлевның башына да җиттеләр. Аны башта, урыныннан алып, Мәскәүгә төбәкләр үсеше министры итеп алдылар һәм, ахыр чиктә, эшеннән төрле гаепләр табып, ул урыннан да азат иттеләр.

Ләкин мин Владимир Анатольевичның татарларга мәрхәмәтле булуын махсус рәвештә ассызыклыйм. Ул милләттәшләребезгә карата игътибарлы булды, аларга һәрвакыт ярдәм итеп килде. 1998 елның 9-10 март көннәрендә без Петербургта Конгресс Башкарма комитетының күчмә утырышын үткәрдек. Татарстанның андагы вәкиле Шамил Камил улы Әхмәтов аны ныклап әзерләгән. Гомумән, бу кеше татарларны оештыруга, аларның җирле хакимият җитәкчеләренә якынайтуга күп көчен сарыф итә иде. Аның тырышлыгы нәтиҗәсендә, «Таврический» сараенда үткән БДБ илләренең парламенты утырышында Татар конгрессын бу оешмага күзәтүче рәвешендә кабул иттеләр. Монда Яковлевның да роле зур булды.

Эрмитажда: алгы рәттә уртада – Владимир Яковлев

Безнең утырыш Эрмитажда үтте. Яковлев һәм аның хөкүмәтенең җаваплы кешеләре монда актив катнашты. Владимир Анатольевич үзенең чыгышында татарларның шәһәр тормышында бик зур роль уйнауларына махсус басым ясады. Ул конкрет фактларга таянып, дистәләрчә милләттәшләребезнең исемнәрен атады, аларга зур бәя бирде. Утырыштан соң, Яковлев татарлар хөрмәтенә кабул итү мәҗлесе оештырды. Икенче көнне ул безнең белән мәчеткә барды һәм аның Ватан сугышы вакытында зарар күргән манарасын торгызуга ярдәм итәчәген әйтте.

Владимир Анатольевичның ярдәме белән, Казанның иске йортлардан торган Свердлов урамы төзекләндерелде һәм аның исеме Петербург урамы итеп үзгәртелде.

Конгресста эшләгән чорда миңа еш кына Пермь, Ульяновск, Самара, Оренбург, Төмән, Новосибирск, Омск, Иваново һәм Әстерхан губернаторлары, Удмуртия һәм Якутия Президентлары белән очрашырга туры килә иде. Шушы очрашу-аңлашулар нәтиҗәсендә, милли эшләребезне алып бару күпкә җиңеләйде.

Гомумән, күпвакыт урындагы җитәкчеләр татар тормышына кагылышлы вәгъдәләрен үти торганнар иде. Һәм бу эш һәрвакыт безнең күз уңында булды.

Бервакыт, М.Шәймиев белән Б.Ельцин сөйләшкәннән соң, Россия Президенты урыннардагы хакимиятләр алдына татар тормышына кагылышлы 17 йөкләмә-бурыч куйды. Без аларның үтәлешләрен дә кулдан килгәнчә барлый килдек. Күп урыннарда була идек. Шушы максат белән Владивостокка кадәр бардык, андагы җитәкче органнар белән әнә шул йөкләмәләрнең үтәлешен берәм-берәм барлап чыктык.

Дөрес, үтәлми калган вагъдәләр дә булгандыр. Аларның берсе Әстерхан губернаторының татар театрына элеккеге бинасын кайтарып бирү хакында иде. Ул, аны үтәргә өлгермичә, бакый дөньяга күчте.

Марат Мөлеков.
Фотосурәт samtatnews.ru сайтыннан алынды.

Әгәр дә без җирле хакимиятләрне татар ягына бормасак, татар мәдәниятенә, татар мәгарифенә, татар телен үстерүгә өлеш кертүгә күндермәсәк, анда милли мәктәп тә, милли телебез дә, мәдәният тә булмаячак иде. Без һәрвакыт шуны аңлап эш иттек.

СССР таркалгач, Россиядән читтә яшәүче татарлар бездән аерылып калды, алар тарихи ватаннарыннан ераклашты. Аларга Казанда чыккан газета-журналлар килми. Шуның өчен татарлар яшәгән илләр, андагы милләттәшләребез белән аралашу чараларын арттыру, бәйләнешләребезне ныгыту мәсьәләсе килеп басты.

Монда безгә үзебездәге мәгълүмат чараларының җитәкчеләре белән дә, җирле хакимиятләрдәге шушы эшләр өчен җаваплы кешеләр белән дә эш итү кирәк иде. Беларусь Президенты Александр Лукашенко, Кыргызстан Президенты Әскәр Акаев белән очрашкан вакытта да без шушы проблемаларны күтәрдек.

Украинада, Беларусьта, Казакъстанда һәм Үзбәкстанда эшлекле очрашулар, файдалы сөйләшүләр узды. Казакъстанның Семипалатинск, Шымкент (Чемкент) шәһәрләрендә нәтиҗәле чаралар үткәрдек. Башкарма комитетыбызның Шымкент шәһәрендәге күчмә утырышында Казакъстанның бөтен өлкәләренең, хәтта Кыргызстан һәм Үзбәкстан вәкилләре дә катнашты. Өлкә хакиме Заудбәк Кылышбәк улы Тулусбәков килүебезнең беренче минутыннан алып соңгы минутына кадәр безнең белән булды, утырышыбызда катнашты. Утырыш зур конференция төсен алды. Без анда уртак проблемаларны бергәләп хәл итү юлларын эзләдек. Эшне татар проблемаларын беренче урынга куеп хәл итүдән башлап җибәрдек һәм аңлашуга ирештек.

Шушы эшләрдән соң, әлеге республика-илләрдән килгән милләттәшләребез: «Безгә эшләве дә, яшәве дә шактый җиңеләйде һәм телебез, мәдәниятебез үсешенә дә яңа сулыш бирелде», – дип әйтә башладылар... ■

Данис Шакиров: «Татар халкының зур бәхете – һәр җирдә үз лидерларыбыз булу»

Данис Шакиров, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисенең беренче урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе

Данис Шакиров «Татар кызы» бәйгесендә. 2019 ел. ***Рамил Гали фотосы***

Ике съезд арасында гына да дөньяга сибелгән татар оешмаларында көчле шәхесләр, чын лидерлар үсеп чыкты. Бернигә дә карамастан, планлаштырылган чараларның күбесен уздыра алдык.

Авыл эшмәкәрләре җыеннарын туктатмадык. Татар авылларын саклауга юнәлтелгән бу проект югары бәяләнде. Шуның нәтиҗәсендә, илебезнең кайбер төбәкләрендә татар авыллары эшмәкәрләренең бизнес-клублары оешты. Иң уңышлылары арасында Мордовиядәге татар бизнес-клубын атарга мөмкин.

Татар дин әһелләре форумнары халкыбызны берләштерүдә мөһим урын алып тора. Ике дистәгә якын ел эчендә Конгресс дин әһелләре өчен аралашу һәм аңлашу мәйданчыгына әверелде. Без моның белән хаклы рәвештә горурланабыз. Быел Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми кабул итүнең 1100 еллык юбилеен бәйрәм иткәндә үткәрелгән чираттагы Дин әһелләре форумы халыкара яңгыраш тапты. Конгресс башлап җибәргән дин әһелләре белән хезмәттәшлек бүген милләтебез өчен иң кискен торган мәсьәләләрнең берсен күпмедер дәрәҗәдә хәл итү юлына алып чыкты. Сүз Татарстан Диния нәзарәте карары нигезендә рес-

«Ислам нуры – мәчетләрдә» бәйгесенең бүләкләү тантанасында

публика мәчетләрендә җомга вәгазьләрен татар телендә сөйләү турында бара. Бу – бөтен төбәкләр өчен матур үрнәк. Күрәбез, динебез, мәчетләр милләтебезне саклауда мөһим урын алып тора, шуңа да илебезнең башка төбәкләрендә дә мондый матур, бик мөһим эшләр булуын телләр идек.

Татар дөньясында бик күптәннән авыл тарихларын язу, нәсел шәҗәрәләрен төзү киң таралган иде. Милли күтәрелеш башлангач, мондый милләттәшләребезнең саны бермә-бер артты. Тора-бара бу эшләр киң колач алды һәм Конгресста махсус бүлек төзеп, аңа тиешле юнәлеш бирергә булдык. Бөтенрусия төбәк тарихчылары оешмасы теркәлде, аның җитәкчесе итеп эшмәкәр, танылган тарихчы Камил Әбләзов сайланды. Илнең төбәкләрендә дә җирле тарихчыларның җәмгыятьләре барлыкка килде. Бүген Конгресс канаты астында әлеге оешманың «Туган җир» дип аталган махсус журналы чыгарыла. Ике съезд арасында без 3 тапкыр, Уфа, Томск һәм Омск шәһәрләрендә илдәге төбәк тарихчыларының җыеннарын уздырдык. Конгресста төбәк тарихчылары тарафыннан язылган меңнән артык китап тупланды.

Узган биш ел эчендә татарлар яшәгән мөһим төбәкләрдә Татар мәдәнияте үзәкләре һәм Татар йортлары ачылды. Элегрәк Мәскәү, Тубыл, Төмән, Ульяновск, Йошкар-Ола һәм Волжск шәһәрләрендә эшләп килгән Татар мәдәнияте

«Татар кызы» бәйгесендә катнашучылар

үзәкләренә кушылып, Курган, Санкт-Петербург, Магнитогорск һәм Новосибирск калаларында да яңа үзәкләр ачылды.

«Татар кызы» бәйгесен милләтебезнең киләчәге белән бәйләп карарга кирәк. Бу бәйгеләрнең зур сәхнәләрендә, кызларыбызның гүзәллеге-нәфислеге аша, халкыбызның асыл сыйфатлары – туган телебезнең матурлыгы, милли рухыбыз, гореф-гадәтләребез, тарихыбыз, бөек шәхесләр мирасы ачыла. Һәр елны илнең һәм дөньяның кырыклап төбәгендә шундый бәйгеләр уздырыла, аның тамашачылары бүген меңләгән кешене сыйдыра торган зур спорт сарайларын тутыра.

Бөтендөнья татар конгрессының иң зур казанышы – аның Русия төбәкләрендәге һәм чит илләрдәге йөзләгән оешмалары. Бу – зур көч. Һичшиксез, татар дөньясы – Татарстанның ышанычлы таянычы.

Татар халкының зур бәхете – аның һәр җирдә, һәр төбәктә, һәр илдә үз лидерлары булу. Татар оешмаларының җитәкчеләре – алар милләтебезнең алтын баганалары. Татарстанның төбәкара багланышларында ул лидерлар мөһим урын алып тора. Мин ышанам: масштаблы зур эшләр генә милләтне берләштерә, биек үрләргә күтәрә. Барыгызга да шушы юлда уңышлар телим! ■

Безнең мирас №8 август 2022

Олы юлның узганы

Ринат Закиров, 2002-2018 нче елларда Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе



Ринат Закиров

Мәгълүм булганча, Татарстан Республикасы үзенең яңа дәүләтчелеген 1990 елның 30 августында Дәүләт Суверенитет турындагы Декларациясе игълан итүдән башлап җибәрде. Бу хәлләргә дә инде 30 елдан артык вакыт узды. Әйтергә кирәк, татар халкы шушы арада нык үзгәрде, аның милли горурлыгы үсте, рухы күтәрелде. Безнеңчә, Татарстан Республикасының алга китеше, алдынгы сафларга чыгуы нәкъ шушы үзгәрешләр белән бәйле. Бу елларда татар халкының гасырлар буенча басылып килгән дәрте уянды, башкарылган һәр эштән канәгатьлек хисе туды. Мондый яшәү рәвеше кешенең тормышына мәгънә бирә, халыкны берләштерә, яңа үрләргә өнди.

Татарстан Республикасында татар халкының дүрттән бер өлеше генә яши. Совет автономиясе чорында чит төбәкләрдәге, бигрәк тә чит илләрдәге татарлар белән элемтәләр бик чикләнгән иде. Шуны истә тотып, 1992 елда Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Бөтендөнья татар конгрессын оештыру турында фәрман чыгарды. Шул ук елның җәендә Казан шәһәрендә Бөтендөнья татар конгрессының I корылтае җыелды. Ул, һичшиксез, тарихта калырлык зур вакыйга булды. Башкарма комитет оештырылды, аның рәисе итеп танылган галим, академик Индус Таһиров сайланды.

Татарның 1000гә якын милли һәм дини оешмалары эшли

Аннан соңгы 30 ел эчендә Бөтендөнья татар конгрессы зур юл үтте. Шушы чорда татар дөньясы Татарстан белән бер дулкында яшәүгә ирешә. Бүген дөньяның 42 илендә, Россия Федерациясенең 70тән артык төбәгендә татарның 1000гә якын милли һәм дини оешмалары эшли, алар үзара хезмәттәшлек итә. Татарстан Республикасы һәм Бөтендөнья татар конгрессы тырышлыгы белән бүгенге дөньяда татар факторы көчәеп бара. Кайсы гына өлкәне алма, мәгарифме, фәнме, спортмы, икътисадмы, авыл хуҗалыгымы – һәр тармакта милләттәшләребез үзләрен иң яхшы яктан күрсәтә.

Конгрессның III корылтае алдыннан, 2002 елда, Татарстан җитәкчелеге миңа Башкарма комитетны җитәкләргә тәкъдим ясады. Әлбәттә, бу минем өчен көтелмәгән ва-

кыйга булды. Мин аңа тиз генә ризалашмадым, чөнки әлеге вазыйфаның ни дәрәҗәдә җаваплы булуын аңлый идем. Ләкин Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиевнең үтемле сүзләре ризалык бирергә мәҗбүр итте. Шул рәвешле, III корылтайдан мин Конгресста эшли башладым. Оештыру эшләрендә шактый тәҗрибә туплаган кеше буларак, Конгрессның эшчәнлеген яңа юнәлешләргә боруны хуп күрдем. Монда аерым чаралар гына түгел, ә системалы, киң күләмле хәрәкәт кирәк иде. Күп катламлы һәм күп тармаклы татар дөньясын бер юнәлештәге хәрәкәткә китерү зур һәм катлаулы бурыч иде. Шушы бурычны аңлап, без масштаблы чаралар уздырырга карар кылдык һәм эшкә керештек.

Академик Миркасыйм Госмановның ялкынлы чыгыш ясаган мәле

Әйтергә кирәк, III корылтайда күп кенә делегатлардан татар яшьләрен милли хәрәкәткә җәлеп итү турындагы фикерләр яңгырады. Ә Башкарма комитет әгъзасы, Сарытау татарлары лидеры Камил Әбләзов 22 пункттан торган тәкъдимнәрен БТК рәисе өстәленә кертеп салды. Әле дә истә, аның беренче пунктында чит төбәкләрдәге һәм чит илләрдәге татар яшьләрен Татарстан югары уку йортларында укыту мәсьәләсе куелган иде. Проблема шактый четерекле булып чыкты, күп мәсьәләләрне федераль хакимият һәм төбәк җитәкчеләре белән хәл итәргә кирәк иде. Бу өлкәдә без махсус программа булдыруга ирештек. Ел саен йөзләгән татар баласы, Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы юлламасы белән, республика югары уку йортларына укырга керде.

БТКның бу проекты чит илләрдә яшәүче яшь милләттәшләребез өчен бик кулай булды. Әйтик, Кытайдан чыккан 100дән артык татар егетләре-кызлары төрле елларда Казан югары уку йортларында уку бәхетенә иреште. Шушы гамәл ерак гасырлардан килгән элемтәләрне яңарту буларак кабул ителде.

Яшьләр белән тыгыз элемтәдә эшли башлагач, мондый эшчәнлекнең төп оештыручысы кирәклеге ачыкланды. Шулай итеп, 2004 елда без беренче Бөтендөнья татар яшьләре форумын уздырдык. Ул чара яшьләргә кагылышлы бөтен эшчәнлекне колачлады, ике елга бер үткәрелә башлады, татар яшьләрен берләштерде һәм рухландырды. Яшьләр – милләтебезнең киләчәге, шуңа да алар белән эшләү, һичшиксез, туктап торырга тиеш түгел.

Дин белән милләт эше тыгыз бәйләнештә барырга тиеш

Илдәге демократик үзгәрешләр чорында иң көчле күтәрелеш дин өлкәсендә күзәтелде, чөнки халык рухи яңарышка мохтаҗ иде. Шуның нәтиҗәсе буларак, Казанның 1000 еллыгын бәйрәм иткәндә Кол Шәриф мәчете ачылды. Бер үк вакытта дин өлкәсендә шактый катлаулы проблемалар барлыгы ачыкланды – дин әһелләре арасында бердәмлек булмавы үзен сиздерде. Моны аңлап, Бөтендөнья татар конгрессы араларны аралаштыру өчен бер мәйданчык оештырырга алын-

ды. Илдәге мөфтиләрне бергә җыйдык. Уртак фикергә килү җиңел булмады. Алай да, очрашу тәмамлангач, күпчелек хәзрәтләр Конгресска рәхмәтен җиткерде. Уңышлы башлангычтан соң имамнарның зур күләмле җыеннарын уздырырга кирәк, дигән карарга килдек. Татарстан Президенты Р.Н.Миңнеханов бу эшне хуплады һәм бик зур ярдәм күрсәтте. Конгресс «Дин һәм милләт» шигаре астында ел саен форум үткәрә башлады. Кыска гына вакыт эчендә анда катнашырга теләүчеләрнең саны меңнән артты. Соңрак форумның Координация Шурасы сайланды, аның рәисе итеп танылган галим, академик Рәфыйк Мөхәммәтшин билгеләнде. Форумны оештыру эшләре системага салынды.

Бөтендөнья Яшьләр форумы делегатлары Арча районының Яңа Кырлай авылында

Дин әһелләре форумнарының милли тормышка тәэсире бик тиз сизелде. Яшерен-батырын түгел, мәчетләребездән татар телен кысрыклап чыгара башлаганнар иде. Мондый күренешләр Россия төбәкләрендә генә түгел, Татарстанның үзендә дә пәйда булды. Бу тискәре күренештән арыну йөзеннән, форумга җыелган татар дин әһелләре, җомга вәгазьләрен татар телендә генә уку зарур, дигән карарга килде. Күп кенә мәчетләрдә әлеге карар хәзер дә үтәлә. Татарстан Диния нәзарәте һәм аның җитәкчесе мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин бу эшне эзлекле һәм кыю алып бара. Шулай итеп, дин әһелләребез татар телен саклау эшенә дә лаеклы өлеш кертәләр.

Кызганыч, кайбер төбәкләрдә әлеге эшнең нихәтле мөһим булуын аңлап бетермиләр. Нәтиҗәдә, ул якларда яшәүче милләттәшләребез хәтта тарихи татар мәчетләреннән дә читләшә. Күп кенә төбәкләрдә имамнар: «Татарлар мәчеткә йөрми», – дип зарланырга ярата. Сәбәбе бик гади югыйсә: дин белән милләт эше тыгыз бәйләнештә барырга тиеш, моны инкяр иткән очракта милләтнең мәчеттән читләшүе бер дә гаҗәп түгел.

Сүзләремнең хаклыгын Иваново шәһәрендәге мәчет мисалы расылый. Андагы милли оешма җитәкчесе дин эшләрен дә үзе җитәкли. Ул – Фәрит Ляпин. Аның мәчете каршында милли мәдәни үзәк уңышлы эшли. Мәчеттә татар теле дәресләре укытыла. Әлбәттә, татарлар да бу мәчеткә бик теләп йөри.

Мәгълүм булганча, татар халкында Бөек Болгар тарихына ихтирам һәрвакыт зур булды. Элек-электән Болгар җире халкыбызны үзенә тартып торды. Һәр заманда әби-бабаларыбыз анда барып дога кылуны изге гамәл дип санады. Дини яңарыш кичергән чорда халык анда күпләп йөри башлады. Шуны күреп, Бөтендөнья татар конгрессы бу эшне яңача оештыру кирәклеген аңлады. Илдәге барлык дин әһелләре белән киңәшкәннән соң, без «Изге Болгар җыены» дип аталган яңа чараны гамәлгә куйдык. Аның беренчесенә үк, Конгресснең чакыруын кабул итеп, 50 меңнән артык дин кардәшебез җыелды. Бүген әлеге чарага барлык кыйтгалардан меңләгән кеше килә, Татарстан Республикасы Шәһре Болгарны торгызып, аны дөньяга танытуда

күп көч куя. Моны халкыбыз бик югары бәяли.

Конгресс Казандагы Россия ислам институты белән дә хезмәттәшлеген ныгытты. Безнең тырышлык белән монда татар теле барлык студентлар өчен төп фәннәрнең берсенә әйләнде. Бу фәнне укытуның максаты шул иде: барлык яшь белгечләр татар телендә камил итеп вәгазь сөйли белергә тиеш, дидек. Әйтергә кирәк, Казанга татар оешмалары юлламасы белән укырга килгән яшьләрнең бер өлеше нәкъ шушы институтны сайлый. Мондый эш максатчан алып барыла: яшь белгечләр, үз төбәкләренә кайтып, дин эшләрен җитәкләргә тиеш, дип күз алдында тотыла. Дөрес, әлеге өлкәдә проблемалар җитәрлек әле, әмма, куелган максаттан читләшмәсәң, алга китеш, һичшиксез, булачак.

Бөтенроссия татар авыллары оешмасы барлыкка килде

Илебез базар шартларына күчкән чорда милләттәшләребез арасыннан бик күп уңган-булдыклы кешеләр килеп чыкты. Аларның шактый өлеше урыннарда милли тормыш коруның барлык чыгымнарын үз өстенә алды. Кайберләре милли оешмаларга җитәкчелек тә итте. Оешкан көннәреннән үк Бөтендөнья татар конгрессы аларга таянды. «Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре» форумы миңа кадәр үк уздырыла башлаган иде инде. Анда Татарстанда җитештерелгән продукцияне төбәкләрдә сату мәсьәләсе күтәрелә иде. Һәм әлеге эшне нәкъ менә татар эшмәкәрләре җәелдерде – утызлап төбәктә «Татарстан сәүдә йортлары» барлыкка килде.

Татар эшмәкәрләренең милли тормышта катнашуы хакында аерым әйтәсем килә. Мәсәлән, Сарытау шәһәрендәге саллы бизнес вәкиле Камил Әбләзов озак еллар үз хисабыннан татар мәктәбенә ярдәм күрсәтә. Ул шулай ук Алтын Урда чорына караган Үкәк шәһәренең тарихын өйрәнү мәсьәләләрен, аңа багышланган конференцияләр уздыруны, тарихи китаплар чыгаруны да үз өстенә алды. Мондый мисаллар башка төбәкләрдә дә бар. Самара эшмәкәре Фәхретдин Канюкаев Камышлы район үзәгендә узган Бөтенроссия авыл Сабан туеның байтак чыгымнарын берүзе күтәрде. Ульяновск өлкәсе эшмәкәре Эдуард Ганиев үзен данлыклы татар меценаты итеп танытты. Аның бихисап изге гамәлләрен туган җирендәге генә түгел, башка төбәкләрдәге милли һәм дини оешмалар да тоеп яшәде. Ул «Түгәрәк уен» татар фольклор бәйрәмнәрен финанслауны һәм оештыруны үз өстенә алды. Эдуард Ганиев бүген арабызда юк инде, әмма игелекле гамәлләре күңелләрдә һаман яши. Якташлары аның истәлегенә «Ганиев укулары» үткәрә башлады. Әлеге чара һәр елны Ульяновск өлкәсенең Кулаткы район үзәгендә Бөтендөнья татар конгрессы катнашында уза.

Соңгы елларда татар тормышының иң авырткан мәсьәләсеннән берсе – татар авылларының яшәеше. Сер түгел, авыллар картая. Бу тискәре тенденцияне Татарстан авылларына кертелгән зур инвестицияләр дә әкренәйтә алмый әле. Балалар саны киму сәбәпле, халкыбызга зур шәхесләр биргән атаклы мәктәпләр дә күзгә күренеп сүрелә бара. «Оптимальләштерү» шаукымына эләгеп, соңрак аларның шактые ябылды да. Бөтендөнья татар конгрессына эшкә килгәч, минем өчен тагын бер нәрсә ачыкланды: шәһәр белән авылда милләт яшәеше бер-берсеннән нык аерыла икән. Конгресс эшчәнлегендә моны исәпкә алырга кирәк иде. Беренче эш итеп илдәге иң гайрәтле татар авылларын карап-күреп кайтырга булдым. Алар арасында Самара өлкәсенең Гали, Чуашстанның Шыгырдан һәм Тукай, Мордовиянең

Әзүркә, Пенза өлкәсенең Урта Әләзән авыллары бар иде. Бу авыллар мине таң калдырды: андагы матур-матур йортлар, мәчетләр, асфальт түшәлгән юллар, ә иң мөһиме – балаларның күплеге. Могҗизаның сере бик гади булып чыкты – җирле халык, шәхси милеккә таянып, эшмәкәрлеккә керешкән. Әйтик, Гали авылында күпчелек гаилә, бәрәңге бакчаларында парниклар корып, яшелчә үстерә. Продукцияне җитештерү арткач, якындагы шәһәр ширкәтләре әлеге тауарны сатып алырга үзләре үк килә башлаганнар. Ягъни андагы халык хөкүмәттән дә, «инвесторлардан» да берни көтеп ятмаган, үз көче белән яшәүне өстен күргән. Бу авылларның тагын бер үзенчәлеген әйтмичә булмый: аларда мәхәлләләр оешкан һәм дини тормыш яхшы куелган. Эшмәкәрләр төзегән өр-яңа мәчетләр мәхәллә тормышының үзәген тәшкил итә.

Урта Әләзән авылында 11 мәчет тирәсендә милли тормыш кайнап тора. Авыл җитәкчесе үзенең эшчәнлегендә әлеге мәхәлләләргә таяна.

Мондый тәҗрибә белән танышканнан соң, без, Конгресс аша, аны илдәге башка татар авылларына да таратырга кирәк, дигән фикергә килдек. Шулай итеп, 2012 елның язында I Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре форумы узды. Әлеге чара илдә зур кызыксыну уятты. Нәтиҗәдә, Бөтенроссия татар авыллары оешмасы барлыкка килде. Аның беренче рәисе итеп Чуашстанның Озын Куак авылы эшмәкәре Рәшит Сәнҗапов сайланды. Бүген оешманы Башкортстанның Туймазы районындагы Төмәнәк авылы эшмәкәре Фәнир Галимов җитәкли. Алар икесе дә, бизнес белән бергә, җәмәгать эшләрен дә оста алып баручы шәхесләр.

Татар конгрессы делегациясе Кырым татарлары мәҗлесе вәкилләре белән. 2008 ел, апрель

Быел Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләренең унынчы форумы узды. Бер чорда анда катнашучылар саны меңнән арткан иде, соңгысында, пандемия сәбәпле, 500 делегат белән генә чикләнергә туры килде. Без, шундый хезмәттәшлек корып, авылларны кризистан чыгару юлын таптык кебек – аларны эшмәкәрлек хәрәкәте коткара алачак.

Сабан туе – татар халкын берләштереп торучы чара

Бөтендөнья татар конгрессының мәдәниятка, халык традицияләренә кагылган проектлары турында әйтеп китәсем килә. Болар – Сабан туе бәйрәмнәре, фольклор фестивальләре, «Татар кызы» конкурслары, җыр фестивальләре. Шушы чаралар нигезендә күпчелек төбәкләрдә дистәләгән иҗат коллективлары барлыкка килде.

Әлбәттә, татар халкын берләштереп торучы төп чара – Сабан туе бәйрәме. Бүген илебезнең күпчелек төбәкләрендә ул рәсми бәйрәмнәр исемлегенә кертелде. Һичшиксез, мондый күренеш Татарстан Республикасы һәм аның Президенты Р.Н.Миңнехановның абруе турында сөйли.



Бөтендөнья татар конгрессының беренче корылтае делегатлары Шәһри Болгарда. 1992 ел, июнь

Татарлар яшәгән чит илләрдә дә Сабан туйлары үткәрү гадәткә керде. Төркия, Кытай, Австралия, АКШ һәм Канадада милли бәйрәмебез инде күптән оештырылып килсә, Европа Берлегенә кергән илләр өчен бу әле яңалык иде. Соңгы елларда Европа Сабан туйлары Рига (Латвия), Берлин (Алмания), Вильнюс (Литва), Таллин (Эстония) шәһәрләрендә уңышлы узды. Шушы эшчәнлекне күреп, Россия Тышкы эшләр министры С.В.Лавров чит илләрдәге татар оешмалары турында: «Бу – илебезнең йомшак көче», – дип әйтте. Мондый сүзләр юкка гына әйтелмәде – Бөтендөнья татар конгрессы дистә еллар буе Тышкы эшләр министрлыгы белән хезмәттәшлек итә.

Түмәндә «Түгәрәк уен» фольклор фестивале. 2009 ел

Башкортстан татарлары мәнфәгате

Конгресс өчен ул елларда иң четерекле мәсьәлә булып Башкортстан татарларының мәнфәгатьләрен хәл итү тора иде. 2002 елгы халык санын алу чарасы аны тагын да катлауландырды. Ике республика арасында мәдәни багланышлар кимеде. Татар телендәге тапшыруларга зур мохтаҗлык булуга карамастан, Татарстан телевидениесен Башкортстан кабель челтәрләренә кертмәделәр. 2007 елгы IV корылтайга әзерләнгәндә, без, мондый каршылыкны туктатырга кирәк, дигән фикергә килдек. Ул корылтай татар һәм башкорт халыкларына юнәлтелгән махсус мөрәҗәгать кабул итте. Анда ике тугандаш халыкның уртак тарихы, мәдәнияте һәм мәнфәгатьләре турында тәфсилләп әйтелгән иде. Моның ише гамәлләрдән соң, вазгыять шактый йомшарды. Ниһаять, Башкортстанда да Татарстан телевидениесен карый башладылар, ике республиканың иҗат коллективлары янә бер-берсенә гастрольләргә йөрүен яңартты, Башкортстаннан чыккан бөек татар шәхесләренә дә мөнәсәбәт үзгәрде, аларны зурлау мөмкинлеге ачылды.

Бүген Башкортстан җирлегендә ике профессиональ татар театры, дистәләгән фольклор коллективлары иҗат итә. Яңа гасыр башында килеп чыккан киеренкелек басылды. Бу, әлбәттә, татар халкының мәнфәгатьләренә туры килә.

Чит илләрдәге татар оешмалары

«Россотрудничество» белән ике яклы килешү имзалангач, Бөтендөнья татар конгрессы чит илләрдәге эшчәнлеген тагын да киңрәк җәелдерде. Әйтик, 2013 елда Европа парламенты бинасында Европа татарлары альянсын оештыру җыелышы узды, ул җыелышта Тышкы эшләр министрлыгы вәкилләре дә катнашты. Соңрак әлеге оешма Бельгиядә рәсми теркәлде. Татарларга мәдәни чаралар уздыруда төрле халыкара оешмалар ярдәменә таяну мөмкинлеге ачылды.

Чит илләрдәге татар оешмалары бик күп мәдәни чаралар үткәрә. Әйтик, Татар-

стан Президенты катнашында Габдулла Тукайга багышланган юбилей кичәләре Анкарада (Төркия), Дрезденда (Алмания), Хельсинкида (Финляндия) узды, үзгә мәдәни чаралар Брно (Чехия), Оттава (Канада), Сан-Франциско (АКШ), Будапешт (Маҗарстан), Өремче (Кытай), Аделаида (Австралия), Астана (Казакъстан) һәм Бишкәк (Кыргызстан) шәһәрләрендә үткәрелде.

Татар тарихына кагылган халыкара чаралар турында да әйтәсем килә. Мәгълүм булганча, Польша-Литва дәүләтләрен саклау сугышларында татар гаскәрләре мөһим урын тоткан. Шуңа күрә ул дәүләтләрдә татарларга хөрмәт бик зур. 2010 елда Польшаның Гданьск шәһәрендә тантаналы рәвештә татар сугышчысына һәйкәл ачылды. Анда Татарстан делегациясе составында миңа да катнашырга насыйп булды. Тантана халыкара мәгълүмат чараларында киң яктыртылды.

Татар йогынтысы көчле булган чит илләрдән Үзбәкстанны, Казакъстанны, Кыргызстанны билгеләп үтәргә мөмкин. Бу илләрдә татар зыялылары XIX гасырда ук мәгърифәт-мәдәният өлкәсендә тәрбия-агарту эше алып барганнар. Татар мөгаллимнәре ерак кышлакларда мәктәп-мәдрәсәләр ачып, балаларга белем биргән, олыларны уку-язуга өйрәткән. Татар укытучылары ярдәмендә бу илләрдә җәдиди мәктәпләр барлыкка килгән, җирле халыктан милләт зыялылары тәрбияләнгән. Мондый йогынты читтән торып тәэсир итү генә булмаган, татарларның күбесе җирле халык белән туганлашкан, уртак гаиләләр корган. Чыңгыз Айтматов, Олжас Сөләйманов, Бибигөл Түлегенова, Камил Муллашев, Чыңгыз Әхмәров, Мидхәт Булатов, Латыйф Хәмиди, Айсылу Токымбаева, Фуат Мансуров кебек шәхесләр бөтен дөньяга билгеле. Аларның иҗатлары җирле мәдәнияткә хезмәт итсә, исемнәре татар халкын зурлый, бүгенге буыннарда милләтебез өчен горурлык хисләре уята. Бу илләрдәге татар зыялыларының яңа буыны да үзен сынатмый.

Көчле диаспора булган җирдә милли оешмалар да көчле. Андый оешмалардан чын лидерлар үсеп чыга. Үзбәкстан татарлары җитәкчесе Ришат Нәбиуллин, Казакъстан татарларыныкы – Тәүфикъ Кәримов, Кыргызстан татарлары башлыгы Гөлсинә Үлмәскулова – шундыйлардан. Аларның тырышлыгы нәтиҗәсендә җирле хакимиятләр татарларга бик уңай мөнәсәбәттә.

Татар тарихы белән кызыксыну артты

Туксанынчы еллардагы милли күтәрелеш халкыбызда үз тарихы белән кызыксынуны арттырды. Сер түгел, совет чорында татар тарихын өйрәнү шактый чикләнде, ә Алтын Урда тарихы бөтенләй тыелган иде. Вазгыятьнең үзгәрүе Татарстан Фәннәр академиясен ачарга мөмкинлек бирде. Академиядә профессиональ тарихчыларны туплаган махсус институт эшли башлады. Шушы елларда институт тырышлыгы белән 7 томлы «Татар тарихы» дигән фәнни хезмәт нәшер ителде.

Бөтендөнья татар конгрессы Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты галимнәре белән һәрвакыт тыгыз элемтәдә булды. Халкыбызда милли үзаң тәрбияләүдә алар бик актив катнашты. Конгресс һәм аның оешмалары уздыра торган күпсанлы фәнни-гамәли конференецияләр, төрле юбилейлар, тарихи вакыйгалар һәм бөек шәхесләргә багышланган «укулар» һәрвакыт бу институт галимнәре катнашында үтте.

Икенче яктан, тарихи эзләнүләргә күпсанлы һәвәскәр тарихчылар – төбәкне өйрәнүчеләр килеп керде. Алар, күпчелек очракта җирле халыкның һәм татар авылларының тарихын өйрәнде, эзләнүләренең нәтиҗәсе итеп матур-матур китаплар чыгарды. Басмалар саны йөзләрчәгә җитә башлагач, Бөтендөнья татар конгрес-

сы әлеге хәрәкәтне үз тирәсендә тупларга кирәк тапты. Шулай итеп, Бөтенроссия төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте оешты. Озак та үтмәде, конгрессның яңа проекты барлыкка килде. Ул Россия һәм чит илләр шәһәрләрендәге татар бистәләрен өйрәнү, саклау һәм торгызуга багышланган. Әлеге проектка йөзләгән һәвәскәр тарихчы кушылды.

Без этнотуризм юнәлешен башлап җибәрергә булдык

Бөтендөнья татар конгрессы беренче көненнән үк халкыбызның милли бердәмлеген саклауны төп максат итеп куйды. Шушы елларда татар халкы Татарстан тирәсендә туплана башлады һәм аның моңа мохтаҗлыгы ачыкланды. Мине иң гаҗәпләндергәне шул булды: меңләгән кеше катнашында зур чаралар уздырганда милләттәшләребез, кайда гына яшәсәләр дә, үз хисабына Казанга килеп җитә иде. Шөкер, бу бүген дә шулай дәвам итә.

Татар кешеләренең Казанга тартылуын күргәч, без этнотуризм юнәлешен башлап җибәрергә булдык. Эш бик уңышлы китте, аппаратта махсус кешеләр билгеләдек, милләттәшләребезне күпләп кабул иттек. Юл чыгымнары һәм яшәүләре үз өсләреннән булса, мәдәни чараларны һәм экскурсияләрне Конгресс оештыра иде. Сәфәр тәмамлангач, аралашып-гәпләшеп, китаплар бүләк итешеп, милләттәшләребезне озата идек.

Бигрәк тә Башкортстаннан килгән төркемнәрнең күплеге хәтердә саклана. Алар арасында укытучылар, әти-әниләренә ияргән балалар шактый иде. Ике як өчен дә зарыгып көтелгән мондый аралашулар күңелләрне нечкәртә һәм бик җылы уза иде. Милләттәшләребез һәрвакыт: «Без әле монда яңадан кайтырбыз», – дип саубуллашты.

Этнотуризм кысаларында Финляндиядән, Төркиядән, Австралиядән, АКШтан, Кытайдан, Үзбәкстаннан, Казакъстаннан, илебезнең дистәләгән төбәкләреннән Казанга татар иҗат төркемнәре килде. Аларның башкала сәхнәсендә һәм Татарстан районнарында уңышлы чыгыш ясаулары милләт бәйрәменә әверелде. Бу – Россия халыклары өчен уникаль күренеш, монда халкыбызның нихәтле көчле-кодрәтле булуы чагыла.

Бөтендөнья татар конгрессы башкалар өчен үрнәк

Бөтендөнья татар конгрессы эшчәнлеген Татарстан Республикасы уңышларыннан аерып карау мөмкин түгел. Конгресс миллионлаган милләттәшебезнең яшәешенә мәгънә бирде, шулай итеп илдә татар факторы барлыкка килде. Татарлар бүген иң югары даирәләргә үтеп керделәр. Алар Россия Хөкүмәтендә дә, парламентта да, төбәкләр җитәкчелегендә дә, бизнеста да, фән, сәнгать һәм спорт өлкәләрендә дә үзләрен иң яхшы яктан таныталар. Мондый уңышлар халкыбызның көч-куәтен күрсәтә, аның якты киләчәгенә өмет уята. Әгәр Бөтендөнья татар конгрессы 30 ел дәвамында уңышлы эшләп килә икән, аның нигезендә, һичшиксез, халкыбызга таяну төп фактор булып тора. Чит илләрдәге милләттәшләребез дә сынатмый. Конгрессның алар белән эшчәнлеген Тышкы эшләр министрлыгы да югары бәяли. Россия ватандашларының халыкара җыеннарында Сергей Лавров һәрвакыт Бөтендөнья татар конгрессын башкалар өчен үрнәк итеп куя. Бу – Татарстан Республикасы өчен дә зур дәрәҗә. ■

Фәрит Уразаев: «Ак бай»ларыбыз туып килә!»

Бөтендөнья татар конгрессының Татар эшмәкәрләре белән эшләү бүлеге җитәкчесе Фәрит Язкәр улы Уразаев

Күп проектларның башлангычында татар эшмәкәрләре тора

Татар эшмәкәрләре элек тә, бүген дә милли мәдәниятебезне, горефгадәтләребезне, рухыбызны саклауда инвестиция чыганагы булып тора. Бигрәк тә Татарстаннан читтәге төбәкләрдә бу юнәлештә эш аеруча актив. Мәчет, мәктәп, балалар бакчалары төзелеше, газета-журналлар чыгару, милли ансамбльләр оештыру, туризм юнәлешендәге эшчәнлекләрнең, хәтта милләткүләм бәйге-конкурсларның да башлангычында эшмәкәрләребез тора. 22 ел дәвамында федераль Сабан туе уздырабыз. Аның беренчесе Сарытауда игелекле эшкуар Камил Әбләзев иганәсе белән башланып киткән иде. Икенчесе – Җәмил Рәхимҗан улы Вәлиуллин ярдәме белән Тольяттида, өченчесе Азат Курчаков иганәсе белән Сембер өлкәсенең Мәләкәс шәһәрендә оештырылды. «Түгәрәк уен» Бөтенроссия фольклор уеннары фестивале дә тәүге мәртәбә Эдуард Ганиев ярдәме белән Сембердә узды. Ул соңрак Төмән һәм Самара өлкәләрендә дәвам итте. Бөтенроссия татар авыллары Сабан туе да Самарадагы Гали авылында Расих Латыйпов тырышлыгы белән башланды. «Татарстанның эшлекле партнерлары», татар авыллары фермерлары җыены да эшмәкәрләребезнең инициативасы белән оештырыла башлады. Хәтта Россиякүләм «Татар кызы» бәйгесенә дә Чиләбе эшмәкәре Лена Колесникова нигез

салды. Ык буе татар авыллары Сабан туе да иганәчеләребез катнашында уза. Бу – шул төбәктәге халыкның шәҗәрәсен өйрәнү, гореф-гадәтләрен саклау, татарның җир-су милкенә мөнәсәбәтен формалаштыру дигән сүз. Эшебезне: «Авылларыбыз сакланса – милләтебез яши» дигән девиз астында да алып барабыз. Шулай итеп, хәзерге эшмәкәрләр Рәмиевләр, Акчуриннар, Хөсәеновлар эшчәнлеген күпмедер дәрәҗәдә дәвам итәләр. «Ак бай»ларыбыз туып килә. Алар милләтебезгә хезмәт итә.

Татар брендларын булдырдык

Оренбургтагы Фаил һәм Альбина Әбсәләмовлар гаиләсе инде 20 елдан артык мамык шәлләр бәйләү белән шөгыльләнә. Алар, үз коллекцияләрен Казанга алып килеп, «Татар мамык шәле» бренды итеп тәкъдим итте. Чимал табудан башлап, зур сәнәгать дәрәҗәсенә кадәр үсеп җиткән мамык шәлен җитештерүдә һәм сатуда алар гаилә белән тырышып хезмәт итә. Әлбәттә, мондый бизнес милләтебезне матур яктан гына таныта. Шундый ук эшчәнлекне Башкортстанда яшәүче Фәнир Галимов та алып бара. Ул «Бабаем утары» аркылы кымыз һәм казылык җитештерү эшләрен гаиләсе белән бергә җайга салды. Мөслим районындагы Ирек Хамадишин үз гаиләсе белән каклаган татар казлары брендын көннән-көн җәелдерә бара. Узган ел Мөслимдә беренче мәртәбә Бөтенроссия күләмендә «Каз өмәсе» этнофестивален дә уздырдык. «Рамай» үрдәкләре Лаеш районында «Кәүсәр» бренды астында татар дөньясына танылып килә (Фермер – Фәрит Хәйретдинов). Ә иң зур казанышыбыз – татар атлары. Меңьеллык татар атлары яңадан милләтебезгә кайтырылды. Бу юнәлеш Лениногорск районындагы Фәрит әфәнде Нәбиуллин эшчәнлегендә уңышлы гамәлгә ашырыла. Ул Карабаш авылында «Аргамак» милли брендын булдырды. Хәзер татар атлары чабышларда гына түгел, ә «Аударыш» бәйгесендә дә катнаша. Сабан туебызның һәм «Түгәрәк уен»ның да милли символлары – тулпар ат. Мордовиядә Рәфыйк Фәтхуллин, елкы үрчетеп, «Юлдаш» һәм «Сабантуй» исемле казылык брендын булдырды. Аңлашылганча, милли ризык, милли төшенчә һәм символларны да халкыбызга кайтарабыз. Татар эшмәкәрләренең бизнес клублары да оештырылды. Алар Мордовиядә, Сембердә уңышлы эшчәнлекләрен дәвам итәләр.

VII Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыенында ТР Президенты Р.Н.Миңнехановка татар брендларын тәкъдим итү. 2018 ел

«Аударыш» – татар атларына утырып көрәш. Арча районының Яңа Кырлай авылы, 2019 ел.
Салават Камалетдинов фотосы

«Габдулла Тукай» теплоходы

Ата-бабаларыбыз юлында татар бизнесы җәелү – шатлыклы күренеш

Аеруча кызыклы һәм мактауга лаек юнәлешләр дә бар. Логистика юнәлешендә дә татар эшмәкәрләре нәтиҗәле эш алып бара. Мәсәлән, Ринат Әюпов – Әстерхандагы ике портның хуҗасы, Дәүләт Думасы депутаты. Аның бер теплоходы Габдулла Тукай исемен йөртсә, икенчесе Муса Җәлил исеме белән аталган. Яңа теплоходларына да милли исемнәр кушар дип өметләнәбез. Идел, Каспий, ягъни ата-бабаларыбызның борынгы юлы буйлап татар бизнесы җәелү дә – шатлыклы күренеш.

Бизнес милләтне күтәрә

Әлбәттә, методик, оештыру һәм мәдәни чараларның сыйфатын күтәрү, эчтәлеген баету җәһәтеннән, Бөтендөнья татар конгрессының роле искиткеч зур. Конгресс хәзерге көндә татар милләтенең йөзек кашы булып тора.

Эшмәкәрләребез һәм Бөтендөнья татар конгрессының уртак эшчәнлеге нәтиҗәсендә, Россиядә татар факторы ныгыды. Милли аңыбызны кайтаруда татар эшкуарларының йогынтысы бик зур. Милләт һәм авыллар тарихына багышланган китаплар да, нигездә, алар акчасына дөньяга тарала. Балаларыбызга, оныкларыбызга нигез ташы итеп шушы эшчәнлекне, динебезне, хәер-фатиханы, ата-бабаларыбызның рухын һәм, әлбәттә, туган җирне тапшыра алсак, милли бурычыбызның иң зур өлеше үтәлгән булыр дип саныйм. Хәзерге көндә эшмәкәрләр арасында 5-6 балалы гаиләләр бар. Бизнес татар милләтен күтәрә һәм аны дөньяга яхшы яктан гына таныта. ■

Альберт Борһанов: «Тулы бер институт эшен башкара торган төбәкчеләребез бар»

Бөтендөнья татар конгрессының Төбәк тарихын өйрәнүчеләр белән эшләү комитеты җитәкчесе Альберт Әхмәтҗан улы Борһанов. ***Солтан Исхаков фотосы***

Төбәкне өйрәнүчеләрнең 103 җирле оешмасы булдырылды

Мәгърифәтчеләребез, гомумән, һәр укымышлыбыз үз туган төбәге, тарихы белән кызыксынган. Габдерәхим Утыз Имәни, Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов, Каюм Насыйри, Гайнетдин Әхмәров – кемне генә искә төшермә, алар үз заманы өчен бик яхшы төбәк белгечләре булган. Казан Император университеты да бу юнәлештә актив эшләгән. 1920 елда төбәкчеләр хәрәкәте янәдән активлашып киткән. Соңрак, Сталинның тоталитаризм сәясәте аркасында, милли төбәк тарихын өйрәнүчеләр хәрәкәте сүлпәнәйгән, колхоз, авыл советлары һәм пионерия тарихларын өйрәнү мәктәп музейлары дәрәҗәсендә генә калган.

Үзем исә Татарстанда әлеге эш белән 1995 елдан актив шөгыльләнәм. Шул елда Биектау районында беренче конференция оештырдык. Аңа атаклы тарихчы, туган төбәгебезне тирәнтен өйрәнгән Газиз Гобәйдуллинның оныгы Эдуард Кульпин-Гобәйдуллин да кайткан иде. 2015 елда Тарих һәм Энциклопедия институтлары, Татар конгрессы тарафыннан татар төбәкчеләрен бергә туплау мәсьәләсе кузгатыла башлады. 2016 елда – Республикакүләм татар төбәк тари-

Төбәкне өйрәнүчеләр бастырып чыгарган китаплар күргәзмәсе

хын өйрәнүчеләр җыенын, 2017 елда исә I Бөтенроссия татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр съездын оештырдык. 2018 елда Татар конгрессы каршында Төбәк тарихын өйрәнүчеләр белән эшләү комитеты булдырылды. Нәтиҗәдә, Россия буенча 103 оешма ачуга ирештек. Аның Марий Эл һәм Татарстандагылары рәсми теркәлде. Ә күп урыннарда төбәкне өйрәнүчеләр җәмгыятьләре татар милли мәдәни мөхтәриятләре, Татарстанның рәсми вәкаләтле вәкиллекләре, Конгресс оешмалары аша эшчәнлекләрен дәвам иттеләр. Татарстанда исә 62 төбәк тарихын өйрәнү оешмасы булдырылды. Алар район музейлары, мәктәпләр яки җирле иҗтимагый оешмалар аркылы берләштеләр. Һәр төбәктә «уң кулым» дип әйтерлек лидерлар барлыкка килде.

Көзен төбәкчеләр десанты ун көнлек фәнни сәфәргә чыгачак

Төбәкчеләр оешмасы Конгресска һәм татар милләтенә зур файда китерде. Беренчедән, узган елгы җанисәп алу вакытында аеруча актив эшләдек. Уралга, Башкортстанга, Чиләбе, Пермь һәм Курган өлкәләренә барып, милләттәшләребез белән очрашып, фәнни җыеннар уздырып кайттык. Пенза, Сарытау һәм Ульяновск өлкәләре белән сөйләшүләр булды. Нәкъ шул вакытларда Омск һәм Свердловск өлкәләрендә татар төбәкчеләренең VI форумы матур гына узды.

Хәзер исә чираттагы форумга әзерләнәбез. Ул ун көн дәвамында, фәнни төбәкчеләр десанты рәвешендә, Россиянең дүрт төбәгендә – Бардада һәм Пермьдә, Свердловскидагы Серов һәм Екатеринбург шәһәрләрендә, Чиләбе өлкәсенең Коншак районындагы Бәгәрәк Тамагы авылында һәм Чиләбенең үзендә, ә аннары Уфада үтәчәк. Бу шәһәрләрдә «түгәрәк өстәл»ләр яки фәнни конференцияләр оештырылачак. Татарның мәдәнияте, сәнгате, танылган шәхесләренең тормыш юллары да өйрәнеләчәк һәм җитди проблемалар күтәреләчәк.

Җитәкчеләр тарихны белергә тиеш!

Район җитәкчеләре арасында акыллы кешеләр бик күп. Мин һәрвакыт аларга: «Сез, иң беренче чиратта, тарихны белергә һәм шуңа таянып райондашларыгызга, без монда – җирле, төпле, бай мираслы халык, дип әйтергә тиеш!» – дим. Биредә ата-бабаларыбыз яшәгән һәм алар өчен бу җирләр уңайлы булган икән, киләчәктә татар халкы шушында торырга тиеш дип уйлыйм. Тарих аркылы халыкның милли үзаңын күтәрү бик мөһим! Икенчедән, җир ул эшкәртү, икмәк үстерү, матди табыш алу урыны гына түгел икәнлеген, ә аңа туган җир, туган нигез буларак карарга, аны читләргә сатмаска кирәклеген төшендерәм. Өченчедән, табигый сулыкларны, елга һәм күлләрне, чишмәләрне саклау мөһим. Чиста су елдан-ел иң кыйммәтле чыганакка әйләнеп бара. Ә татар халкына Аллаһы Тәгалә эчә торган суны мулдан биргән. Без Идел, Агыйдел, Ык, Казансу, Чулман һәм Нократларыбыз белән горурланырга, аларны сакларга тиеш. Дүртенчесе – киләчәгебез акыллы, милли рухлы яшьләрдә. Без аларны җиң сызганып әзерләү турында да онытырга тиеш түгелбез.

Кемнәр актив: төбәкне өйрәнүчеләрме, әллә галимнәрме?

Без фәнни институтлар белән иңне-иңгә куеп эшләргә тиеш. Әмма галимнәр арасында төбәкне өйрәнүчеләргә «югары»дан карау әлегә кадәр күзәтелә. Фәкать Энциклопедия институты, аның җитәкчеләре генә безнең белән бик тыгыз эшчәнлек алып бара. Төбәкне өйрәнүчеләрнең шактые галимнәр инде. Араларында гыйльми дәрәҗәгә ия булганнары, гомере буе башка өлкәдә эшләгәннәре дә шактый. Аларның күбесе гыйльми эшчәнлек, уку-язу белән шөгыльләнә, архивларда баш күтәрми тарих яза, чыганак эзли. Нәтиҗә буларак, «Татар авыллары тарихы» исемле җыентыкның алтынчы китабы, «Восток и Запад: диалог культур и цивилизаций Евразии» җыентыгының 24 нче китабы, «Алтын Урда һәм Казан ханлыгы» сериясенең 12 нче басмасы дөнья күрде. Ел саен авыл тарихларына багышланган китаплар языла тора. Бу эштә Пенза, Сембер һәм Себер татарлары аеруча актив. Казан, Мәскәү яки башка шәһәрләрнең галимнәре аларга киңәш һәм ярдәм сорап еш мөрәҗәгать итә. Күрүебезчә, татар төбәкчеләре дә рәсми оешмаларның фәнни хезмәткәрләреннән ким эшләми. Тулы бер институт эшен башкара торган төбәкчеләребез дә бар.

Эшебез күп тармаклыга әверелде

Иң төп юнәлеш төбәкләрдәге татар авыллары тарихын язу иде. Бу эш актив бара. Шуңа өстәп, төбәкчеләр хәрәкәтендә яңа тармаклар да барлыкка килде. Шуларның берсе – аерым шәхесләрнең тормыш юлын, эшчәнлеген, бай мирасын өйрәнү. Әлеге уңайдан күптән түгел генә Питрәч районында Мәүла Колыйга багышланган ике конференция үткәрдек. Өченче юнәлеш – этнотуризм. Бу эштә Туймазыдагы Төмәнәк авылы һәм Фәнир Галимов аеруча актив. Омскида да матур гына башлангычлар күзәтелә. Дүртенче юнәлеш – архивларда эшләү методикасы, авыллар тарихын язу, әзер материалларны китап итеп бастырып чыгару буенча консультацияләр бирү. Бишенче юнәлеш – музейлар төзү. Әле узган ел гына шәхси музейларга багышланган конкурс үткәрдек, анда танылган тарихчы

Генерал, тарих һәм хәрби фәннәр докторы, профессор Мәхмүт Әхмәт улы Гәрәев тә I Бөтенроссия татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр съездының мөхтәрәм кунагы иде. 2017 ел

Нурулла Гариф беренче урынны алды. Шулай итеп, бер юнәлештә башланган эшебез күп тармаклыга әйләнде.

Татарның ике канаты бар

Татарның ике канаты – Татарстан һәм Башкортстан татарлары бар. Милләт үсешендә безнең төп таянычыбыз шулар булырга тиеш. Башка төбәкләр безгә карап тора.

Татарның ике аягы бар. Беренчесе – Идел буе татарлары, икенчесе – Урал һәм Көнбатыш Себер татарлары. Бу җирләр элек тә татарның тарихи ватаны булган, киләчәктә дә шулай булачак. Татар төбәген өйрәнүчеләр әлеге җирлекләрдә аеруча актив эшчәнлек алып бара.

Конгрессның ярдәме бик зур

Төбәкчеләр хәрәкәте Бөтендөнья татар конгрессы ярдәмендә формалашты һәм күркәм нәтиҗәләргә иреште. Бу юнәлештә элек олылар гына эшләсә, хәзер яшьләр дә килде. Тарих, археология һәм башка институтларга төбәкчеләрне эшкә дә ала башладылар, чөнки милли һәм җирле тарихны язуда алар алып барган эш күпкә нәтиҗәлерәк булып чыкты. Мәсәлән, «Татары Уфимского уезда» исемле китапка материалларны да, нигездә, татар төбәген өйрәнүчеләр туплады. Оренбург һәм Пермь өлкәләре буенча да әлеге юнәлештәге эшне башкарып чыгасы калды.

Һәр башлангычыбызда Бөтендөнья татар конгрессының ярдәме бик зур. Транспорт, конкурслар, конференцияләр үткәрүдә матди һәм оештыру ягыннан таянычыбыз булмаса, безнең эшләр хәзерге югарылыкта башкарылмас иде. Конгресска һәм татар халкына таянып, республикабызда һәм Россиядә төбәкчелек хәрәкәте алга бара, елдан-ел яңа уңышларга ирешә. ■

Безнең мирас №8 август 2022

Узган гасыр Милли Шурасыннан бүгенгесенә кадәр

Татар конгрессының корылтае ачылыр алдыннан

Мәгълүм вакыйгалардан соң дәүләтчелеген югалтса да, татар халкы беркайчан да милли хисен, азатлыкка, милли алгарышка, үсешкә омтылышын җуймаган. Моны тану өчен тарихка күз ташлап, милли дәүләтчелекне торгызу өчен сугышларны, Батырша хәзрәтләре «фетнә»сен, көчләп чукындыру сәясәтенә каршы баш күтәрүләрне, татар матбугатын булдыру өчен йөз ел дәвамында барган көрәшне һәм башка шундый вакыйгаларны искә төшерү дә җитә. Дөнья азмы-күпме игә килүгә, татар халкы, мәчет-мәдрәсәләр, абыз-абыстайлар тирәсенә тупланып, милли хәятен алга сөргән; теленә, диненә җуелырга юл куймаган, эчке потенциалын сүндермичә, аның учагына һәрдаим утын өстәп торган; иман, гыйлем тараткан, лаеклы дәвам үстергән һәм киләчәккә карап гомер иткән.

Гайрәтле, милләтпәрвәр яшьләр алга чыга: «Иттифак әл-мөслимин»нән ТАССРга чаклы милли сәяси хәрәкәт

Кешелек дөньясын танымаслык итеп үзгәртәчәк XX гасырга татар халкы әзерлекле, өлгергән милләт булып килеп керә. Шушы елларда заманча милли әдәбият, профессиональ театр, музыка сәнгате, журналистика барлыкка килә, яңа, гади халыкка да аңлаешлы әдәби тел формалаша. Әдәбият мәйданына Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан, Дәрдемәнд, Мәҗит Гафури, Галимҗан Ибраһимов кебек гайрәтле, милләтпәрвәр яшьләр чыга. Иҗтимагый фикер, теология өлкәсендә Йосыф Акчура, Садри Максуди, Галимҗан Баруди, Ризаэддин

Фәхреддин, Муса Бигиев, Габдерәшит Ибраһимов һәм башка күп зыялылар үз сүзен әйтә. Россия империясенең төрле почмакларында дистәләгән татар газета-журналлары чыга башлый, китапларның гомуми тиражы миллионнарга җитә.

Нәкъ шушы чорда татарның рәсми иҗтимагый хәрәкәтләре формалаша. Беренче Россия инкыйлабы дулкынында, 1905 елда, Түбән Новгород шәһәрендә «Иттифак әл-мөслимин» исемле беренче Бөтенроссия мөселманнары фиркасе оеша. 1906 елның язында I Дәүләт Думасына сайлаулар уза, парламентка мөселман депутатлары, шул исәптән, татар милләте вәкилләре дә сайлана. Бер-бер артлы җыелып, бер-бер артлы таратылып торган Дәүләт Думасының дүрт чакырылышында да татар депутатлары була.

Билгеле, милли хокуксызлыктан иза чиккән барча халыклар сыман, татарлар да 1917 елгы Февраль революциясен дәртләнеп, куанып һәм өметләнеп каршылый. Татар милләте, үз язмышының үз кулында булуын аңлап, иҗтиһадка бирелә: 1917 елның мартында меңләгән мөселман гаскәриләрен берләштергән Хәрби Шура оеша, 1917 елның язында Бөтенроссия мөселман укучы яшьләре һәм Бөтенроссия мөслимәләр съездлары уза, 1917 елның 1 маенда Мәскәүдә I Бөтенроссия мөселман съезды ачыла һәм ике атна дәвамында эшли. Әлеге съездда Бөтенроссия мөселманнарының Милли Шурасы сайлана. Аңа кергән әгъзалар арасында Садри Максуди, Гаяз Исхакый, Галимҗан Баруди, Муса Бигиев, Фатих Кәрими, Ильяс Алкин кебек милләтебезнең күренекле затлары була. Бөтенроссия мөселманнарының икенче съезды июль-август аралыгында Казанда җыела. 22 июльдә Бөтенроссия мөселман руханилары корылтае һәм Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең беренче корылтае делегатлары берләштерелгән утырышта Эчке Россия һәм Себер төрки-татарларының Милли-мәдәни мохтариятын (автономиясен) оештыру турында декларация кабул итә, автономиянең нигезләрен эшләү комиссиясен төзи.

Татар милли хәрәкәте, эшне милли-мәдәни мохтарият булдырудан башласа да, Октябрь түнтәрелешеннән соң Милләт Мәҗлесе (милли парламент) сайлый, төрле нәзарәтләрдән (министрлыклардан) торган Милли идарә кора, халык тормышына кагылышлы законнар кабул итә. Болар барысы да милли дәүләтчелеккә таба адымнар булып тора. Милли идарәнең рәисе итеп – Садри Максуди, финанс министры итеп – Шәйхулла Алкин, мәгариф министры итеп Нәҗип Корбангалиев сайлана, Дин эшләре министрлыгын Галимҗан Баруди җитәкли.

Милләт Мәҗлесе Совет хакимиятен танымый, 1918 елда Идел-Урал Штатын төзү турында карар кабул итә. Шуңа ирешү өчен, ул махсус комиссия төзи.

1918 елның 8 (21) гыйнварында Казанда II Бөтенроссия мөселман хәрби съезды ачыла, шушы съездда Идел-Урал Штатын игълан итү ниятләнелә. Әмма большевиклар бу эшкә көчле каршылык күрсәтә, II Бөтендөнья мөселман хәрби съездында Мулланур Вахитов, Камил Якубов, Мирсәет Солтангалиев кебек революционерлардан торган төркем оештыралар. Шулай итеп, Казанда татар милли хәрәкәте һәм большевиклар арасында ачыктан-ачык каршылык башлана, большевикларга Мәскәүдән һәм Петроградтан хәрби ярдәм җибәрелә. Нәтиҗәдә, Идел-Урал Штаты проекты тормышка ашырылмый кала. Бу чорда Ватандашлар сугышы җәелә башлый, ирекле татар милли хәрәкәте бөтенләй басыла…

1920 елның 27 маенда В.И.Ленин, М.И.Калинин, А.С.Енукидзе имзалаган Декрет нигезендә Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы оештырыла. Ни кызганыч, аны татарның ирекле формада башкарылган үзбилгеләнү гамәле дип танып булмый. Соңрак, 1922 елда Советлар Союзы барлыкка килгәндә дә, 1937 һәм 1977 нче елларда илнең яңа Конституцияләре кабул ителгәндә дә, республика

җитәкчелеге һәм интеллигенциясе Татарстанга союздаш статус бирүне, милли хокукларны арттыруны сорап, шактый омтылыш ясап карый. Ләкин Мәскәү ишетми. Ул 1980 нче еллар азагында, татар халкы мәйданнарны тутырып, оран сала башлагач кына, игътибар итәргә мәҗбүр була.

Минтимер Шәймиев: «Ниятебез изге, юлыбыз туры»

Туксанынчы елларны искә алганда, әлбәттә, Татар иҗтимагый үзәге, Милли Мәҗлес, «Иттифак» фиркасе һәм башка бик күп иҗтимагый оешмалар турында әйтми китәргә ярамый. Гасыр башындагы кебек, бу чорда да, милләт үз язмышын үз кулына алырга омтыла, дәүләтчелек, тел, дин, милли мәгариф, милли мәдәният, милли азатлык хакына урамнарга чыга, үз сүзен кистереп әйтә, хокук даулый, ачлыкта утыра... Нәтиҗәдә, яңа Татарстан оеша. Бу елларның иң зур казанышы булырлык вакыйгалардан Җөмһүриятебезнең дәүләт суверенитеты турында декларация кабул итүне, дәүләт статусы турында референдум уздыруны, Татарстан Республикасы Конституциясен гамәлгә кертүне атарга мөмкин. 1992 елда Бөтендөнья татар конгрессын җыю турында Указ имзаланып, аның тормышка ашырылуы да, һичшиксез, шундый ук әһәмиятле вакыйгаларның берсе булып тора.

Чыннан да, иң җитди мәсьәләләрне уртага салып сөйләшер һәм аларны хәл итәр өчен, ата-бабаларыбыз элек-электән җыеннарга җыелган. 1992 елның 19-21 нче июнь көннәрендә узган беренче Бөтендөнья татар конгрессының I корылтае бу матур традицияне яңартып җибәрә. Милли-мәдәни, социаль-икътисадый, сәяси мәсьәләләр буенча фикер алышу, аларны чишү юлларын табу өчен беренче съездга Австралия, Кытай, Польша, Румыния, АКШ, Төркия, Финляндия, Япония, Латвия, Литва, Эстония кебек илләрдән меңнән артык кеше килә. Конгресс эшендә шулай ук Үзбәкстан, Украина, Кыргызстан, Казакъстан, Башкортстан һәм Россиянең бик күп өлкәләрендә яшәүче кардәшләребез дә катнаша.

Пленар утырышта беренче булып Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев чыгыш ясый. «Ниятебез изге, юлыбыз туры» дип аталган чыгышында ул татар халкының ачы, михнәтле язмышы, көчле рухлы, каһарман йөрәкле, мәгърифәтле, ярдәмчел булуы, дөнья мәдәниятен үстерүгә шактый зур өлеш кертүе һәм үзен беркайчан да кол итеп тоймавы турында әйтеп үтә, суверенитет һәм аның киләчәге хакында тәфсилләп сөйли. Бу чыгыш бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмый әле.

Съездның пленар утырышы Бөтендөнья татар конгрессы карарын чыгару һәм дөнья халыкларына, дәүләтләренә, Берләшкән Милләтләр Оешмасына Бөтендөнья татар конгрессы исеменнән Мөрәҗәгать юллау белән тәмамлана.

Икенче көнне, 20 июньдә, делегатлар, төркемнәргә бүленеп, «Татар халкының тарихы», «Милли мәгариф системасын үстерү мәсьәләләре», «Татар мәдәниятенең үсеше мәсьәләләре», «Татарстанда фәнне үстерү мәсьәләләре», «Массакүләм информация һәм нәшрият», «Татар телен үстерү мәсьәләләре», «Милли белгечләр әзерләү мәсьәләләре», «Мирас һәм заман», «Татар эшмәкәре», «Милләт, хатын-кыз һәм гаилә», «Иске татар бистәсе: үткәне һәм киләчәге», «Татар эмиграциясенең тарихы һәм бүгенге хәле», «Яшьләр мәсьәләләре», «Татарстан Республикасы дипломатиясе һәм халыкара элемтәләре», «Милли һөнәрчелекне тергезү» дип исемләнгән «түгәрәк өстәл»ләр эшендә катнаша. 21 июнь көнне фикер алышулар һәм файдалы очрашулар Сабан туе мәйданнарында дәвам итә. Азактан, 22 июньдә, теләге булган делегатлар Шәһри Болгарга сәфәр кыла.

Татар конгрессының шәһәр бүлеге җитәкчесе Ф.Гарифуллин (сулда), ТР Президенты М.Шәймиев, Казан шәһәре администрациясе башлыгы К.Исхаков һәм Татар конгрессы рәисе И.Таһиров яңа бина ачылышы вакытында. 1998 ел, август

Бөтендөнья татар конгрессының беренче корылтае делегатлары Шәһри Болгарда. 1992 ел, июнь

Татар конгрессының Шымкент (Чимкент) шәһәрендә узган күчмә утырышы. 1996 ел, 8 июль

Бөтендөнья татар конгрессының беренче съезды татар дөньясы өчен зур вакыйга була, милләтебезнең киләчәгенә өмет белән карарга ышаныч тудыра. Яшәгән җирләре төрле булуга карамастан, милләттәшләребез Татарстан Президентын татар халкын берләштерүче символ, ә Казан шәһәрен бөтен татар халкының рухи мәркәзе итеп таный.

Икенче корылтай (ул заман төшенчәләре белән сөйләшкәндә – икенче чакырылыш) 1997 елның 28-29 нчы август көннәрендә җыела. Бөтендөнья татар конгрессының биш ел элек сайланган Башкарма комитетының ике съезд арасындагы эшчәнлеген рәис Индус Таһиров яктырта. Ул Конгресс эшенә фәнни оешмаларның, дәүләт структураларының һәрвакыт игътибарлы булуын, ярдәм итеп яшәүләрен билгеләп үтә һәм аларга рәхмәтен белдерә.

Корылтай барышында Конгрессның статусын билгеләү, Уставын кабул итү һәм шушы Устав нигезендә җитәкче органнарны формалаштыру, телебезне, динебезне, гореф-гадәтләребезне саклау, латин графикасына күчү, татарларның бөтенлеген саклау мәсьәләләре күтәрелә. Делегатлар арасында татар яшьләренең бик аз булуын истә тотып, яшь буын вәкилләре киләчәктә Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетында Яшьләр комиссиясе булдыру һәм Бөтендөнья татар яшьләре съездын үткәрү тәкъдиме белән чыга. Пленар утырышларда, фәнни-гамәли конференцияләрдә, «түгәрәк өстәл»ләрдә рәхмәт сүзләре генә түгел, тәнкыйть фикерләре, махсус тәкъдимнәр дә яңгырый, делегатлар үзара тәҗрибә дә уртаклаша. Шул рәвешле Бөтендөнья татар конгрессының төп документларына, Уставына һәр кешегә аңлашылырдай гап-гади милли идеология салына: беренчесе – Татарстанның суверенлыгы, икенчесе – дөнья татарларының Татарстан тирәсендә рухи берләшүе.

Өченче корылтай 2002 елның 26-30 нчы август көннәрендә җыела. Татарстан халкына, кунакларга һәм делегатларга Татарстан Республикасы һәм Казан шәһәре көннәренә багышланган бәйрәм чаралары тәкъдим ителә. Татар

мәркәзе белән якыннан танышу максатыннан, «Меңьеллык Казан», «Әдәби Казан», «Музыкаль Казан», «Театраль Казан», «Гүзәл архитектуралы Казан», «Казан – студентлар каласы», «Казан университеты», «Казан күлләре», «Казан мәчетләре», «Раифа монастыре», «Зөя утравы» дигән экскурсия маршрутлары оештырыла. Программа нигезендә 28 августта, көннең беренче яртысында, өч секция утырышы үткәрелә: «Татар халкының фәне, мәгарифе һәм мәдәнияте», «Хәзерге заман татар яшьләре һәм аларның киләчәге» һәм «Татарстанның эшлекле партнерлары». Бу көнне делегатлар Татарстан Республикасының Арча, Биектау, Яшел Үзән, Питрәч һәм Теләче районнары белән дә таныша. Корылтай эшендә 25 ерак һәм якын чит илләрдән, Россия Федерациясенең 57 төбәгеннән 562 делегат һәм мәртәбәле кунак катнаша.

Пленар утырыш 29 август көнне уздырыла, аны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин алып бара.

Башкарма комитетның ике съезд арасындагы эшчәнлеге хакында сөйләр өчен сүз Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Индус Таһировка бирелә. Үз чиратында ул, Татарстанның киләчәген кайгырту йөзеннән, Россиягә яңа тәкъдимнәр белән чыгарга кирәклеген искәртә, татарлык факторына басым ясый. Милләтебезне өлешләргә бүлү һәм милләтләрне бер-берсенә каршы кую (бу очракта татар белән башкортны) омтылышларын алга сөргән сәясәт барлыгын ассызыклый.

Көн тәртибе кысаларында Бөтендөнья татар конгрессының эш документлары кабул ителә, 39 кешедән торган Башкарма комитет сайлана.

Ф.Х.Мөхәммәтшин пленар утырышны тәмамлаганда мондый белдерү ясый: «Җәмәгать, безнең барыбызның да Татар конгрессы кебек саллы иҗтимагый оешманы беренче көннәреннән үк җигелеп тарткан Индус Ризак улы Таһиров алдында бурычыбыз бар. Ул бик әйбәт эшләде, ләкин күптән түгел Президенттан, республика җитәкчеләреннән, коллегаларыннан үзен әлеге вазыйфадан азат итүне сорады». Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе итеп «Казан» милли мәдәният үзәге директоры Ринат Зиннур улы Закиров сайлана.

Бөтендөнья татар конгрессының дүртенче корылтае 2007 елның 12-16 нчы декабрь көннәрендә, Россия Федерациясе белән Татарстан арасында барган сәяси процессларның яңа шартларында, милли үсешнең актуаль проблемалары һәм перспективалары хәл ителгән чорда уза.

Пленар утырышта беренче сүз М.Ш.Шәймиевкә бирелә. Ул чыгышын: «Съездга дөньяга сибелгән татарларның меңгә якын вәкиле җыелып килү беренче адымнардан ук юлыбызның дөрес икәнлеген раслый. Хәзер инде Бөтендөнья татар конгрессын халкыбыз тарихында иң уңышлы проектларның берсе дип бәяләргә мөмкин. Әгәр дә без элеккеге елларда, нигездә, татар телен һәм мәдәниятен саклау турында сүз алып барсак, бүген инде XXI гасыр шартларында халкыбызның үзаңы үсү таләпләренә җавап бирерлек сәясәт алып бару турында план корабыз, – дип, Бөтендөнья татар конгрессы эшчәнлегенә югары бәя бирүдән башлый. Аннары игътибарны ул 2002 елда узган халык исәбен алу мәсьәләсенә юнәлтә: – Татарларны бүлгәләргә теләүчеләр дә аз булмады. Әмма бу барып чыкмады. Без моңа юл куймадык. Бу алга таба да Бөтендөнья татар конгрессы эшчәнлегенең мөһим юнәлеше булып калырга тиеш».

Һәр съездда, милләт язмышына кагылышлы җитди мәсьәләләр күтәрелү белән бергә, башкарган эшләргә йомгак та ясала. Бу уңайдан сүз Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Ринат Зиннур улы Закировка бирелә.

Башкарма комитетның эшчәнлеге канәгатьләндерерлек дип табыла. Пленар утырыш 47 кешедән торган Башкарма комитет, ревизия комиссиясен сайлау һәм эш документларын кабул итү белән тәмамлана.

Борынгыдан килгән милли гореф-гадәтләрне, традицияләрне юкка чыгаруга китерә торган заманча глобализация һәм унификация, күпләгән мәгълүмат технологияләре кертелү этник кыйммәтләрне саклау һәм яшәтүнең яңа ысулларын эзләп табуны таләп итә. Мондый шартларда Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче татарларга милли үзенчәлекләрне, бердәмлекне саклап калу аеруча проблемалар тудыра. Боларның барысын да игътибарга алган хәлдә, татар халкының этник үзенчәлекләрен саклап калуны күздә тотып, 2012 елның 6-9 нчы декабрь көннәрендә Бөтендөнья татар конгрессының бишенче корылтае үткәрелә. Съездда Татарстаннан, Россия Федерациясе төбәкләреннән, якын һәм ерак чит илләрдән 796 делегат, 302дән артык шәрәфле кунак катнаша. Конгресс тарихында беренче тапкыр Бельгия, Испания һәм Нидерландтан, Амур өлкәсеннән, Ямал-Ненец һәм Яһүд автономияле округыннан вәкилләр килә. Съездны Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасында Рөстәм Нургали улы Миңнеханов ача.

Әлеге корылтайда, татар халкының алга таба үсеш юлларын билгеләү ниятеннән, «Татар халкының этник үзенчәлеген саклау концепциясе» проекты тәкъдим ителә. Алга китеп шунысын әйтү зарур: соңрак бу концепция «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау» исемле дәүләт программасына нигез булачак. Әлеге концепция (һәм аның нигезендә эшләнгән программа) – Татарстан Республикасында һәм аннан читтә яшәүче татарларның асылын, мәдәниятен, телен саклап калу һәм үстерү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән принциплар, максатлар һәм бурычлар системасы.

Бөтендөнья татар конгрессының алтынчы корылтае 2017 елның 2-6 нчы август көннәрендә уза. Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов тәкъдиме белән, пленар утырышта Конгрессның яңа идарә органы – Милли Шура оеша, аның рәисе итеп Татарстан Республикасы Премьер-министрының урынбасары Васил Шәйхразыев сайлана. Съездда татар халкының милли үзенчәлеген, телен, гореф-гадәтләрен саклау, аның якын киләчәккә үсеш юлларын билгеләү мәсьәләләре күтәрелә.

Җиденче – чираттан тыш корылтай 2018 елның 19-22 нче июль көннәрендә җыела. аңа Россия Федерациясенең 57 төбәгеннән һәм 24 чит илдән делегатлар һәм кунаклар чакырыла. Көн кадагында төп мәсьәлә булып, Милли Шура оешу сәбәпле, «Бөтендөнья татар конгрессы» Халыкара Берлегенең Уставына үзгәрешләр кертү тора. Съезд вәкилләре, мәдәни программа кысаларында, бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның Яңа Кырлай авылында урнашкан әдәбимемориаль музеен зиярәт итә, 21 июль көнне борынгы мәркәзебездә узган Изге Болгар җыенында катнаша.

Бу елларның тере шаһитләре – шәхесләр, истәлек-хатирәләр, нотыклар, кабул ителгән документлар, фотосурәтләр – әлбәттә, күбрәк мәгълүмат саклый. Бөтендөнья татар конгрессының бөтен тарихын колачламаса да, алар вазгыятьнең нинди булуын, кайдан башлап кая таба баруын чамаларга ярдәм итә.

*Журналга **Рүзәл Мөхәммәтшин** әзерләде.* ■

«Безнең мирас» котлый!

Танылган шәхесләребез – галимнәр, әдипләр һәм сәнгать әһелләре август аенда үзләренең гомер бәйрәмнәрен билгеләп үтә. Менә алар:

1 август – әдәбият галиме, тәнкыйтьче, педагог, профессор **Рифат Хәсән улы Сверигин**га 90 яшь (1932);

11 август – җырчы, педагог, Татарстан Республикасының халык артисты (2008), Апас районының Югары Балтай авылы тумасы **Илсур Кәриб улы Сафин**га 60 яшь (1962);

16 август – шагыйрь, Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (2006), Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (2010), 2001 елдан ТР Язучылар берлеге әгъзасы **Рамил Мотаһар улы Чурагулов**ка 60 яшь (1962);

21 август – актриса, ТАССРның атказанган артисты (1982), Татарстанның халык артисты (1999), Казан шәһәре тумасы **Ләлә Рафаил кызы Миңнуллина**га 70 яшь (1952);

29 август – шагыйрә, 2015 елдан ТР Язучылар берлеге әгъзасы, А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты, Пермь өлкәсендәге Барда районының Солтанай авылы тумасы **Нурия Сәйяр**гә (Нурия Камил кызы Сәярова) 70 яшь (1952).

Олуг затларыбызның барысын да юбилейлары белән ихластан котлыйбыз һәм аларга саулык-сәламәтлек, иминлек, иҗат уңышлары теләп калабыз! ■

Безнең мирас №8 август 2022

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

Кытай мөселманнары мәчете. XIX гасыр

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

Мәчеттә танышкан хатыйб әфәнде дә безнең арада иде. Форсатны ычкындырасым килмәде, бу җыелыш турында сорашырга уйладым. Мондый рәвештә җавап бирде:

– Һиндстанда моннан 20 ел элек барлыкка килгән кадияни мәзһәбе бар икән. (Бу мәзһәп турында сәяхәтнамәнең Һиндстан бүлегендә тулырак мәгълүмат бирәчәкбез. – *Г.И.*). Шул мәзһәптә булган бер кеше инде менә шактый вакытлар биредә яши икән. Бу кешегә бик күп мөселман ияргән, хәзер инде мәчеткә дәгъва

белдерәләр ди: «Мәчеткә йөрергә безнең дә хакыбыз бар, без дә мөселман, бер дә булмаса, мәчеттә бер атна сөнниләр гыйбадәт кылсын, бер атна без кылыйк», – дип, инглиз хөкүмәтенә мөрәҗәгать иткәннәр. Инде хөкүмәт: «Бөтен шәһәр халкы җыелышып хәл итегез: күпчелек кайсы якта булса, мәчет шуларныкы булсын», – дигән.

Биредәге мөселманнарның барысы да һинд сәүдәгәрләре, ди. Боларның зур күпчелеге исмаили шигый, бик азы гына шәфигый сөнни икән. Имам әфәнделәре исә хәнәфи мәзһәбендә. Болар шул рәвешле бүлгәләнеп бетсәләр, кадияниләрнең җиңеп чыгачаклары, күпчелекне тәшкил итәчәкләре бик ихтимал, ди. Шул сәбәпле, бу юлы сөнни-шигый бергәләшеп: «Мәчет безнең барыбызныкы да», – дип җавап бирер өчен җыелганнар. Тик болар арасында да тавыш киткән, сүз киткән. Шигыйләрнең кайберләре: «Имамның катыйленә[1] тарзия[2] иткән кешеләр белән без берләшә алмыйбыз», – диләр икән. Шулай тавыш-гауга дәвам итсә дә, ахыр чиктә, берләшергә һәм шул юл белән кадияниләргә каршы торырга, дигән карарга килгәннәр.

Мәзһәпләр һәм дәүләтләр

Әлегә бу хакта киңәеп сүз алып баруны бик вакытлы дип санамыйм, ләкин «Галәме Ислам»ның («Ислам дөньясы»ның) Һиндстан турындагы бүлегендә бөтен мәзһәпләр хакында әтрафлы мәгълүмат бирү белән бергә, мәзһәпләрнең барлыкка килү сәбәпләрен дә аңлатырга сүз бирәм.

Биредә бары тик мәзһәпләрнең хөкүмәт һәм дәүләтләр белән мөнәсәбәте турында бераз сөйләп китәргә уйлыйм.

XX гасырда христиан голамәсе, диннең әһәмияте калмады, дип язып, бөтен халыкларга кешелеклелек тәкъдим итмәкче була. Болар туры Көнчыгыш халыкларына юнәлгән, бигрәк тә безнең Көнбатыш гыйлеме, Аурупа мәдәнияте гашыйкларыбызның рухын яхшы беләләр һәм боларга динсезлекне киңәш итәләр.

Икенче яктан исә, үзләре бөтен эш-гамәлләрендә динне корал итеп кулланалар. Монда да инглизләрнең ләгънәт төшкере динчеләре, бичара һинд мөселманнарының мәзһәп аерымлыгыннан файдаланып, аларны бер-берләренә каршы куюга ирешкәннәр. Хәзер инде шигый-сөнни берләшеп, мәчетләрен кадияниләр бәйләнүеннән коткара алган булсалар да, вакыт киләчәк, форсаттан файдаланып, боларны яңадан бер-берсенә каршы куячаклар, мәзһәп исеме астында тавыш-гауга китереп чыгарачаклар да, үзләре, бер кырыйга китеп, тамаша кылачаклар.

Бичара мөселманнар, кайда гына булсалар да, хөкүмәтләр тарафыннан гел бу рәвешле кулланылалар, үз араларында бүлгәләнү, таралулар аркасында харап булалар.

Бу әфәнделәрдән сорашып, мәсьәләне бераз аңлаганнан соң, мәчетнең мосафирлар өчен махсус билгеләнгән бүлмәләреннән берсенә урнаштым. Әле шәһәрне күргәнче үк, ул көнне шундагы мөсафирлар белән таныштым.

Бу хөрмәтле мосафирлар арасында Мәккәдән, Мәдинәдән, Һиндстаннан килгәннәр дә, кытай кешеләре дә бар иде. Биредәге мосафирханә төн кунып

---

[1] Катыйль – үтерүче. Хәлифә Хәзрәте Гали бин Әбү Талиб (599-661) һәм аны агулы кылычы белән үтергән Габдерахман ибне Мүлҗәм дигән кеше турында сүз бара булса кирәк *(тәрҗ.иск.)*.
[2] Тарзия – үкенеп гафу үтенү, ризалыгын алу *(тәрҗ.иск.)*.

чыга торган бүлмәләрдән генә гыйбарәт. Һәммәсе дә үз кесәсеннән акча чыгарып ашый-эчә, бары тик бүлмәдә кунган өчен генә түләми. Бөтен юлаучы әлеге мосафирханәгә туктала икән. Бу, гомумән, Кытай иленең бөтен җирендә шулай.

Иртәгесен бераз шәһәрне карап йөрим дип чыктым һәм бар җирен күздән кичердем. Бу җирләрнең кытай шәһәре икәнен белсәм дә, үземне моңа ышандыра алмый идем. Биредә хәтта озын чәчле кытайлар да бик аз очрый. Кая карама – Аурупа кешесе, һинд кешесе, японнар. Бары тик йөк ташучылар, кечкенә кибет тотучылар һәм башка шундый кешеләр арасында гына кытайлар күренә. Шулай бик аптырап карап йөргәндә, бик зур кибетләр арасында автомобиль, велосипед салонының тәрәзәсе каршында туктап калдым. Бер Аурупа кешесе килде дә салон ишеге янында торган әфәндегә: *«Сәламүн аләйкүм, кәйфә хәлүк»,* – диде. Аннары инглизчә сөйләшә башладылар. Бераздан бу кеше китеп барды. Хәзер инде мин, ул кеше янына барып: *«Сәламүн аләйкүм»,* – дидем. *«Вә аләйкүм сәлам, әһлән вә сәһлән»,* – дип җавап бирде һәм шунда ук безнең арабызда якынлык хасыйл булды. Ул минем кем булуымны һәм кайдан килүемне сорады. Мин дә аның *әүләде араб* – гарәп углы икәнен белдем. Мине кибет эчендәге бүлмәсенә чакырды. Кибетнең мөкәммәллеге белән гарәп арасында бернинди мөнәсәбәт юк кебек күренсә дә, ул, кибет кенә түгел, хәтта автомобильләр дә үз заводының тауары икәнен әйтте. Шуннан соң мин шуларның барысын да күрсәтүен үтендем.

Кибетнең артында 200 эшче эшли торган бик зур завод бар икән. Кытай илендә гарәп улы гарәпнең автомобиль заводы бар! Бу мөбарәк затның исеме – Мөхәммәд Муса. Менә шушы кешедән ишетеп, мин Ханкан шәһәренең нинди шәһәр икәнен белдем. Ханкан, ягъни Хонг-Конг шәһәре Кытай илендә булса да, шәһәр белән тагын да шул ук инглизләр идарә итә. Инде 70 елга якын инглизләр бу җирләрне үз кулларында тоталар. Бик зур пароход депосы булган бу зур сәүдә портын кайчандыр инглизләр үзләренә алганнар. Хәзерге көндә исеме буенча кытайларныкы булса да, гамәлдә инглизләр куллана.

Мөхәммәд Муса әфәнде миңа бик зур хөрмәт күрсәтте, шәһәрнең алдынгы кешеләреннән кайбер шәхесләр белән танышып күрешергә ярдәм итте. Биредәге һинд, иран кешеләре арасында зур сәүдәгәрләр бар икән. Мөхәммәд Муса әфәнденең ярдәме белән мин шул көнне үк берничә кеше белән күрешә алдым. Бу чит-ят җирдә андый шәхесләрне очрату бик сөенечле хәл. Мин ул көннәрне шөкер әйтеп искә төшерәм. Аллаһка хәмд һәм шөкерләр булсын, исламиятнең бер билгесе булган «Сәламүн аләйкүм» белән кардәшлек күрсәткән мәлеңнән самими һәм дә бик самими кардәш буласың да куясың.

Ханкан шәһәрендә яшәүче иран кешесе Мөхәммәд Хасан Нәмази исемле бер сәүдәгәр белән таныштык. Мөселман булуы белән искиткеч дәрәҗәдә горурланучы бу кеше биредә сәүдә белән шөгыльләнә икән. Бөек шәхес, Аурупа телләрен белә, гарәпчәсе сөйләшеп аңлашырлык булмаса да, үзе бик белемле, күп укый, күп белә икән. Бу мөхтәрәм зат белән бик озак сөйләштек.

Бомбейдан килгән Абдулкадыйр әфәнде белән дә күрештек. Бу да бөек һәм бай кеше икән. Шулай итеп, Ханканда бер көн эчендә шактый кеше белән таныштым, кунак булдым.

Биредә мөселманнарның күптөрлесе булса да, араларында Бомбейдан килгән исмаили шигыйләр күпчелекне тәшкил итә икән. Болар арасында бик бай кешеләр бар һәм сәүдә дә күбесенчә алар кулында. Бу җирләрнең иң элекке мөселманнары арасында биредә туып-үскән һәм инглизләрнең таянычы булган Абдуллаһ Факир әфәнде дигән бер кеше бар.

Абдуллаһ әфәндене Ханканның иң баш кешесе дип тә әйтергә мөмкин. Шәһәрнең суы, электр белән яктыртылуы – бар да бу кешенең кул астында икән. Исеме Факир, ягъни фәкыйрь булса да, үзе шәһәрнең иң бай, иң хөрмәтле кешесе. Зур кунакханәләр, мосафирханәләр, пар мунчалары – барын да бу кеше эшләтә икән.

Электр трамвайлары да әлеге шәхеснең кулында булган, ләкин соңгы елларда, инде шактый карт булуы сәбәпле, ул эшләрне шәһәр хакимиятенә тапшырган. Мондый зур урыннар биләгән мөселманнарның булуы – бик шөкер итәрлек хәл.

Ханкан шәһәре

Шәһәр бик зур булмаса да, бик матур тау итәгенә урнашкан, төрле җиләк-җимеш бакчалары белән бизәнгән. Һәр йортның үз бакчасы бар. Шәһәрнең бер өлеше тау башына урнашкан булганга, югарыгы һәм түбәнге өлешләре бер-берсенә телефон линияләре, электрлы трамвай юллары белән тоташкан. Тау итәгендәге йортларның юллары да бик төзек. Шәһәр зур сәүдә шәһәре булганга, төрле милләт кешеләре бар. Тик безнең госманы төрекләреннән һәм руслардан бер генә кеше дә очрамый. Мин моны гел сораштым. Бөтен җирен йөреп чыктым. Шул ук вакытта берничә гарәп кешесенең булуы барыбер шул госманлылар бар дигән сүз инде.

Биредә минем вөҗданымны газаплаган нәрсә – шәһәрдә тауга таба һәм мәхәлләләр арасындагы юлларда хәрәкәт рәвеше иде. Монда тигез юллар өчен рикша булса да, тауга күтәрелү өчен ике кешенең иңбашына куеп ташый торган «гөрүмә» дигән чара бар – бу искиткеч авыр эш. Колга кебек ике озын агач өстенә кәнәфи куелган. Юлчы шул кәнәфигә утыра, «гөрүмә»ләр иңнәренә алалар да, таудан югарыга таба күтәрелә дә башлыйлар. Бу йөк ташучыларның барысы да – кытайлар. Тик болар да нәкъ безнең кебек кеше һәм Адәм углы лабаса! Без, кешеләр, бик аз гына акча түләп, боларның иңнәренә менеп утырабыз, хайван кебек авыр хәрәкәтләнеп, бу бичаралар тауга 300-400 метр күтәреләләр. Бер километрдан артык җир үтеп күтәрелергә дә мөмкиннәр. Юлчылар боларга бик аз акча түлиләр. Мин бу бичараларның иңбашларына, бигрәк тә ул агачның иңбашына тиеп торган урынына игътибар белән карадым: ул урыннар хайван тиресе кебек булган. Бик йөрәккә тия торган хәлләр болар. Тик мәдәни Аурупа голамәсе бу хакта сүз сөйләмидер дип уйлыйм.

Аурупада хайваннарны яклау, саклау хыялы белән җәмгыятьләр оештырган кешеләр биредә хайваннар да түзә алмаслык авыр йөкне кеше өстенә төйиләр. Шулай булса да, үзләре мәдәният һәм кешелеклелек дигән сүзләр белән авыз чайкыйлар.

Мин моннан Кантон шәһәренә киттем. Бу шәһәр турында да мәгълүмат биреп үтәргә телим.

Кантон

Ханкан шәһәреннән ярга якын йөри торган пароход юлы белән 3 сәгатьлек ераклыкта Кантон шәһәре бар. Бу ике шәһәр арасында көнгә ике-өч тапкыр пароход йөри. Бер көнне китеп, икенче көнне әйләнеп кайтырга була. Теләгәндә, шул көнне үк кире кайтырга да мөмкин.

Кантон Кытай илендә иң борынгы шәһәр булып санала, биредә миллион ярымнан артык кеше яши. Бу шәһәр халкының барысы да кытайлар дип әйтергә

мөмкин. Тик аурупалылар да шактый һәм бигрәк тә миссионер-комиссионерлары күп.

Җирле кытайлар арасында мөселманнар бик ишле. 50ләп мәчет бар, диләр. Биредә бар нәрсәдән элек Сәйидина Саад бине Әби Ваккасныкы дип саналган мәчет шәрифләрен күреп, бер яктан, бик сөендем, тик икенче яктан, бик күңелсезләндем.

Алда да әйткәнемчә, Кантон шәһәре Кытай илендә бик борынгы мәдәни үзәк булып тора. Шул ук вакытта бу шәһәр исламият бишеге булып та санала. Кытайлар үзләре үк, мәмләкәттә исламиятнең нигезе биредә салынган, Кытайга исламият менә бу капкадан килеп кергән, диләр.

Җәннәт белән бүләкләнәсенә алдан хәбәр алган дип беленгән ун кешенең берсе булган Сәйидина Саад (бин Әби Ваккас) бу җирләргә килгән, халыкка хак юлны күрсәтүгә ирешкән. Мәчет шәрифләрен һәм мәдрәсә салдырган. Сәйидина Саадныкы дип саналган мәчет шәрифләре әле дә бар, бик иске. Аның бик борынгы икәнлеге эченнән, тышыннан һәм, гомумән, бар җиреннән аңлашылып тора. Ул шулкадәр иске ки, ишелергә тора. Күп җире инде хәзер үк кулланылмый, җимерелгән, ә кайбер җирләре терәүләр белән терәтелгән. Мәчет янында ук бер кабер бар: Сәйидина Саадның юлдашларыннан берсе булган Касыйм исемле бер кешенең кабере, диләр.

Мәчетнең төзелгән елы һәм төзәтелгән вакыты турында чокып язылган таш та сакланган, ләкин бик иске булганга, язуны укып аңлавы авыр. Бары тик бер җире генә укыла: «*Кад таммә бинаү-л санийән 588*». 588дәге 5 һәм 8 саннарын бик ачык танып була, ләкин соңгы сан бик ачык түгел. 6 да булуы мөмкин, 8 дә, шуларга охшап тора. Ике юл түбәнрәк кытай телендә дә ел язылган, диләр һәм кытайлар үзләре аны: «814 ел булды», – дип тәрҗемә итәләр.

Шулай итеп, мәчетнең салынган яки төзәтелгән елын якынча булса да исәпләргә мөмкин. Бик үк катгый булмаса да, боларга таянып, Сәйидина Саад бин Әби Ваккасныкы дип саналган мәчет бар, дип әйтергә була. Аның борынгы ислами әсәрләрнең берсе икәнлеге бер генә җәһәттән дә шик тудырмый. Болар кытай елъязмаларыннан да билгеле булганга, шул ике хәлнең берсен исбатларга бик җитәрлек: йә бу күрсәтелгән еллар барысы да ялгыш һәм нигезсез ялганнарны яклый, яисә ислами әсәр дип атарлык нәрсәләрдән биредә бер әсәр бар, дип әйтә алабыз. (Мин үзем, мәсәлән, беренчесен кабул итәр идем). Мәчетнең михрабы ягында гарәп язуы белән язылган бик борынгы һәм төрле-төрле язулы ташлар бар. Кыскасы, бу җирләрдә Сәйидина Саад исеме бик мәшһүр. Бездә Әйүб Солтан һәм башка сәхабәләрнең каберләре кебек[3], аннан гел ярдәм сорыйлар.

Бу мәчетне төзекләндерергә кирәк икәнен күргәннән соң, мөтәвәлли идарәчеләре һәм имамнары белән күрешеп, төзекләндерүгә мохтаҗ булса да, гыйбадәтханәнең ни өчен төзекләндерелмәве турында сорадым. «Вакыфы юк, мәхәлләбез фәкыйрь», – дип җавап бирделәр. «Алайса ярдәм дәфтәре ачарга кирәк», – дисәм дә, иңбашларын гына сикерттеләр.

Кантон шәһәре сәүдә үзәге булганга, чит илләрдән бирегә меңнәрчә кеше килә, китә. Килгән бөтен кеше әлеге борынгы мәчетне килеп карамый калмый икән. Бик кызганыч ки, бу җимереклекне, мәчетнең хәрабә хәлендә булуын да исламият белән бәйләми булдыра алмыйлар.

[3] Исемне (яки каберләрне) изгеләштереп, алардан кыенлыклардан котылуны өмет итеп ярдәм сорау турында сүз бара, мөгаен *(тәрҗ.иск.)*.

Мин анда Халәб[4] яһүдиләреннән бер кешене очраттым. Күргәч тә башта мин бу кешене, Госманлы голамәседер, дигән идем, чөнки җөббәле һәм чалмалы иде. Сәлам бирешкәннән соң, кайдан килгәнен сорадым, ул миңа: «Мин чыгышым белән Халәбтән, яһүди милләтеннән», – дип җавап бирде.

Бу кеше миңа менә нәрсәләр сөйләде:

– Сезнең мөселманнарда дингә тугрылык дигән нәрсә беткән икән, әгәр шулай булмаса, җәннәт белән бүләкләнәсенә алдан хәбәр алган дип беленә торган ун изге кешенең берсе булган бу бөек шәхеснең мәчете мондый хәлгә төшәргә тиеш идеме? Хәтта бу мәчетнең аныкымы, түгелме икәне төгәл билгеле булмаса да, шундый бөек кешенең исеме бередә саклана икән – бу хәл исламият өчен шәрәф, дәрәҗә ләбаса?! Христиан дине кешеләре безнең Кодүс (Иерусалим) әйләнә-тирәсендә әнә һәр ел, һич асылы-нигезе булмаса да, изге җирләр, изге чишмәләр, тагын әллә ниләр эзләп табалар.

Бу сүзләрне бер яһүди кешесеннән ишетү гаять авыр булса да, эндәшми калудан да яхшырак җавап таба алмадым. Минем кебек бер гаҗизнең кулыннан ни килсен?! Гарьләнүемнән бу яһүди белән башка күрешмәдем дә, кем икәнен, биредә нишләп йөрүен дә сорамаганмын. Бары тик, ничектер, сүз арасында гына бирегә Лондоннан килүен әйткән иде.

Тагын миссионерлар

Кантонның әйләнә-тирәсендә бу котылып булмый торган корткычлар бик ишле. Алда да Кытай иленең һәр төбәгендә булуларын әйтеп үткән идем инде, тик биредә алар искиткеч күп. Ник дигәндә, бу җир шактый әһәмиятле мәркәз булып санала. Аны басып алу – Кытай иленең капкасын кулга төшерү дигән сүз. Ханкан инде мәҗбүриләү юлы белән Англия колониясенә әйләнгән, бер заман бу җирләр дә басып алынырга мөмкин, чөнки инде хәзер үк инглизләр идарәсендә кебек күренә. Христианлык җәелгән саен, христианлык исеме астында басып керергә хокук алачаклары бик билгеле.

Бөтен Кытай илендә христианлык исеме белән болар үзләренә керү, тыкшыну хокукын алдылар. Шул рәвешле, дин исеме астында басып керү сәясәтенең иң нык, ышанычлы һәм кыска юл икәнен христианнар бөтен яктан таныттылар. Кытайда гына түгел, бөтен Көнчыгышта да бу дәүләтләр алып барган сәясәт – дингә ышыкланып басып керү.

Көнбатыш милләтләре Көнчыгыш дәүләтләренә карата: «XX гасырда диннең нинди әһәмияте булсын?! Мәдәният бар, фәлән-төгән…» – дигән булсалар да, үзләре бөтен сәяси гамәлләрендә динне корал итеп кулланалар.

Бүгенге көндә Көнчыгышта ачылган мәктәпләре барысы да дин исеме белән оештырылган. Безнең мәркәзләребездә, хәтта хәлифәлек мәркәзендә дә, төрле мәктәпләр Америка, Франция капитал хуҗаларының дин һәм христианлык хакына бүләк итеп биргән миллионнары белән тәэмин ителүе һәм аларда белем алган ватан балаларының чынбарлыкта ауланууларын, ел саен меңнәрчә баланың дошман кочагына атылуын игътибарга алсак, бары миссионерлар, дип кенә карау зур ялгыш яки боларны күрмәгәнгә, аңламаганга салышу булып чыга. Ялгышучыларны күпмедер дәрәҗәдә гафу итәргә мөмкин, ләкин күрмәгәнгә-белмәгәнгә салышучылар, һичшиксез, һәр яктан җавап тотачаклар.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

[4] Халәб – Алеппо шәһәре *(тәрҗ.иск.).*

Ислам. Дини сүзлек

Зәкят

Зәкят (гарәпчә – арыну, сәдака, салым) – мал-мөлкәт хисабыннан чыгып, ярлы мөселманнар өчен дип бирелә торган салым, сәдака. Ул Коръән нигезендә билгеләнгән. (Акчасының яки башка малының 1/40 өлеше.) Башта ул азмыкүпме мөлкәте булган барлык мөселманнар бирергә тиешле сәдака булган. Дини берләшмә аны ярлыларга, тол хатыннарга, картларга, гарипләргә, ятимнәргә өләшкән. Шәригать тарафыннан билгеләнгән зәкятнең башка салымнардан аермасы шунда: ул балигъ булган мөселманнардан гына алынган, башка диндәге кешеләр аны түләмәгән. Зәкят, мөлкәт күләменнән, сәүдә һәм һөнәрчелек кеременнән, гаиләдәге балигъ булган кешеләр санынннан чыгып, елга бер тапкыр бирелә.

Ислам дине, зәкят һәм гошердән, фитыр сәдакасыннан тыш, ирекле сәдака бирүне дә хуплый, гөнаһларны ярлыкауда аның әһәмиятенең аерата мөһим булуын раслый. Хәзерге чорда халкы ислам динен тоткан илләрдә зәкятне «ирекле сәдака» диләр. Шунысын да искәртик, үзен иманлы дип санаган мөселман кешесе аны бирмичә калмый. Инкыйлабка кадәр татар байлары зәкят сәдакасын даими рәвештә биреп килгән, чөнки ул мохтаҗлар һәм мескеннәр өлеше санала.

Язма «Ислам. Белешмә сүзлек» (төзүчесе – Заһид Шәфигый, фәнни редакторы – Равил Үтәбәй-Кәрими) китабын (1993) файдаланып әзерләнде. ■

Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре*

Әхмәдвәли Рәхими

49

Әл-Бәра разыйаллаһу ганһү риваять итә. «Рәсүлуллаһның «ястү» намазында «Үәттиини үәз-зәйтүүүн» сүрәсен укыганын ишеттем. Башка беркемнән дә ул күркәм тавышны ишетмәдем».

Укы һәм исеңдә калдыр!

50

Катәдә разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Адәмнәрдән иң яман угры – намазыннан урлаучысыдыр. Намаздан урлау – рөкүгъны, сәҗдәне тәмам кылмау (җиренә җиткереп башкармау)».

Укы һәм исеңдә калдыр!

51

Ибн Габбас разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Җиде әгъза белән сәҗдә кылырга боерылдым: маңгай, ике кул, ике тез, ике аяк башлары».

Укы һәм исеңдә калдыр!

52

Әнәс разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Сәҗдәгезне камил кылыгыз. Сәҗдәдә һичберегез эт кулын түшәгән кебек беләкләрегезне түшәмәгез».

Укы һәм исеңдә калдыр!

53

Әл-Бәра бин Газиб разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Сәҗдәдә ике учыңны куй, ике терсәгеңне күтәр».

Укы һәм исеңдә калдыр!

54

Әбү Һөрәйра разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Бәндәнең Аллаһка иң якын хәле – сәҗдә хәле. Сәҗдәдә доганы күп кылыгыз».

Дәвамы. Башы журналның 12 нче (2021) санында.

*Хәдисләр Шәех әл-Камил Вәли әд-Динмөхәммәд бине Габделхатыйб әт-Тәбризинең «Мишкәтүль мәсабих» китабы буенча әзерләнгән һәм 1913 елда 3 китапта басылып чыккан.

*Текстны басмага **Айсылу Вәлиева** әзерләде.* ■

Безнең мирас №8 август 2022

САБЫЙЛАР ӨЧЕН ДИНИ МИРАС

Дин дәресләре

Сөнгатулла Бикбулат

Ундүртенче дәрес

Сәхабәләрнең мөшрикләрдән җәбер күрүләре. Хабәшәгә (Эфиопиягә) һиҗрәт итүләре. Мөшрикләр белән ара киселү. Хәдичә вә Әбү Талибның вафаты. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) Таифкә баруы. Пәйгамбәребез (с.г.в.) догасы

Мөгаллим: Мөшрикләр пәйгамбәрләргә (г.с.) дә, сәхабәләргә дә бик начар мөгамәлә кылганнар. Алар Пәйгамбәребезгә (с.г.в.) вә сәхабәләргә мөгамәләләрен һаман да начарлата гына барганнар. Пәйгамбәребез (с.г.в.) үзе Әбү Талиб химаясендә булганлыктан, аңа улкадәр җәбер итә алмасалар да, сәхабәләргә бик зур җәфа кылганнар. Бигрәк тә кешедә хезмәттә булучылар хуҗаларыннан әйтеп бетергесез кысынкылыклар вә катылыклар күргәннәр. Хуҗалары аларны чиллләдә, ялангач көе эссе ком өстенә яткырып, өсләренә ташлар белән бастырып газаплый торган булганнар. Кайбер кешеләрне, муеннарына баулар тагып, балаларга тоттыралар да, аларны ат иттереп уйнатып, мәсхәрә иттерәләр икән. Соңыннан Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) мәзине булган хәзрәти Билалны менә шулай итеп җәфалаганнар. Ул мескен мөшрикләрдән бик күп газаплар чиккән. Кайбер кешеләрнең тәннәренә тимер кыздырып басканнар. Мондый газаплар байтак кына хатын-кызларга да күрсәтелгән. Мөшрикләрнең максатлары аларны диннәреннән чыгару булган, ләкин сәхабәләр моңа сабыр иткәннәр. Бервакыт Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте килер әле дип түзгәннәр, өметләрен өзмәгәннәр, диннәреннән аерылмаганнар. Шулай газаплардан үлүчеләр дә булган. Мондый кешеләр бик изге кешеләрдер бит инде, балалар?

Шәкерт: Әлбәттә, изгеләр инде.

Мөгаллим: Шулай, Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен шундый авырлыклар күтәрүдән дә изге эш булырмы?! Мәккә гарәпләренең сәхабәләргә җәбер вә золымнары бигрәк тә арта башлагач, Пәйгамбәребез (с.г.в.) аларга Хабәшә дигән җиргә күченергә кушкан. Ул җирнең падишаһы бик яхшы вә тугры бер кеше икән. Шулай итеп, сәхабәләрнең күбесе, хатын вә бала-чагалары белән сөекле ватаннарын, туган-үскән җирләрен ташлап, чит җиргә – Хабәшәгә китәргә мәҗбүр булганнар. Болар ни өчен алай ватаннарын ташлаганнар, Габдуллаһ?

Шәкерт: Мәккә гарәпләре аларга җәбер иткәннәр, шуңа күрә аннан китәргә мәҗбүр булганнар.

Мөгаллим: Шулай шул. Аларга мөшрикләр җәбер вә золым кылганнар, диннәрен тотарга ирек бирмәгәннәр. Шунлыктан, диннәрен тыныч вә рәхәт тоту өчен, гадел падишаһның канат астына кергәннәр. Пәйгамбәребез (с.г.в.) үзе бәгъзе сәхабәләре белән Мәккәдә калган.

Моннан соң Мәккә гарәпләре Пәйгамбәр (с.г.в.) вә сәхабәләренә тагы да артыграк җәбер итә башлаганнар. Алар Пәйгамбәрне (с.г.в.) яклаган Әбү Талиб белән

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2021) санында.

дә бик нык дошманлашканнар. Әбү Талиб вә аңа ияргән кешеләр белән араны бөтенләй өзәргә булганнар. Алар белән алыш-биреш итмәскә, алардан кыз алмаска, кыз бирмәскә, бөтенләй мөнәсәбәтне кисәргә сүз биргәннәр. Шулай итеп, Пәйгамбәребез (с.г.в.), Әбү Талиб вә аңа ияргән кешеләр Мәккә халкыннан аерылып тора башлаганнар. Болай аерылып тору өч елга сузылган. Шул вакыт эчендә алар бик зур кыенлыклар күргәннәр, ач калганнар, сусыз торганнар.

Моннан соң озакламый Пәйгамбәребезгә (с.г.в.) тагы да зуррак кайгы килгән: башта сөекле хатыны Хәдичә, аннан соң аның артыннан ук Әбү Талиб вафат булган. Пәйгамбәребез (с.г.в.) моңа бик кайгырган, чөнки Хәдичә бик бай, акыллы, үтемле булып, Пәйгамбәребезне (с.г.в.) гел юата, аны башкаларның җәбереннән саклый торган булган. Ә Әбү Талиб, Пәйгамбәребезне (с.г.в.) үз канаты астына алып, аны мөшрикләрдән тулысынча яклаган. Менә шунлыктан Пәйгамбәребез (с.г.в.) болардан аерылуына бик көенгән. Әбү Талиб вафат булгач, Пәйгамбәргә (с.г.в.) бик авыр көннәр килгән: мөшрикләр инде аңа бик каты бәйләнә башлаганнар – кайвакыт аны тотып алып, суккалаганнар. Ул намаз укыганда аның өстенә пычрак, тизәк ыргытканнар. Аның капкаларына пычрак ягып, буяп киткәннәр. Шуңа күрә Пәйгамбәребезгә (с.г.в.) Мәккәдә тору бик авырлашкан. Ул Мәккәдән ерак түгел Таиф дигән бер шәһәргә торырга бармакчы булган. Таиф халкы Мәккә гарәпләренә дошман булганлыктан, Пәйгамбәребез (с.г.в.) үзен анда яхшы кабул итәрләр дип уйлаган. Шулай итеп, ул, янына бер сәхабәне алып, Таифкә киткән. Тик Таиф халкы моңа бик салкын караган. Аны канат астына алу кайда, хәтта куып җибәргәннәр.

Шуннан соң Пәйгамбәребез (с.г.в.) бик пошынып-кайгырып Таифтән чыгып киткән. Аннан чыкканда, яшь-җилкенчәкләр Пәйгамбәребезгә (с.г.в.) ташлар атканнар. Шулвакыт Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) мөбарәк аяклары, үкчәләре җәрәхәтләнгән, канаган.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) Таифтән яңадан Мәккәгә кайткан. Юлда ул Мәккәгә якын бер йөзем бакчасы янына хәл җыярга утырган. Шулвакыт ул боек, җәрәхәтле күңеле белән, Аллаһыга, зарилык белдереп, дога кылган: «Йа Раббым, миңа ярдәмеңне төшер. Синнән башка һичбер арка таянычым юк. Миңа ачуың гына төшмәгән булса ярар иде. Мин бу мәшәкатьләр, бу кыенлыкларның барсына да түзәчәкмен, тик миңа ачуың гына булмасын», – дигән. Әлеге йөзем бакчасы Пәйгамбәребезгә (с.г.в.) дошман кешеләрдән булган Мәккәнең ике олуг кешесенеке икән. Алар шулвакыт бакчада булганнар. Пәйгамбәрне (с.г.в.) шундый кайгылы, йончыган хәлдә күреп, аны кызганганнар һәм үзләренең бер малайлары аркылы аңа бер тәлгәш йөзем җибәргәннәр. Шуны ашап, Пәйгамбәребез (с.г.в.) азрак хәл җыйган. Пәйгамбәребез (с.г.в.) Мәккәгә якын килеп җитсә дә, анда керергә курыккан, чөнки бер мәртәбә аннан чыгып яңадан кайткач, аларның аңа тагы да ныграк ачуланачакларын белгән. Шунлыктан ул, берәүне Мәккәнең олуг бер кешесенә җибәреп, үзен канаты астына алуын үтенгән. Теге кеше бик яхшы күңелле икән. Мөшрик була торып, ул Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) үтенечен кабул иткән: каршы чыгып өенә алып, аны сау-сәламәт килеш илтеп куйган. Менә, балалар, Пәйгамбәребез (с.г.в.) никадәр авырлыклар, газаплар һәм мәшәкатьләр күргән. Башка пәйгамбәрләргә (г.с.) килгән авырлыклар Мөхәммәд пәйгамбәргә (с.г.в.) дә килгән, хәтта артыгы белән дә килгән. Ләкин Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте киң шул: Ул һаман аны саклаган. Пәйгамбәр (с.г.в.) Таифтән Мәккәгә кайткач, аңа тагы да авыррак булган – Мөшрикләрнең җәбер-золымнары тагы да арта төшкән. Ләкин ул моңа һаман да түзгән.

*Текстны басмага **Мәдинә Әбделганиева** әзерләде.* ■

Морад Рәмзи хакында фикер-күзәтүләр

Хатыйп Миңнегулов, филология фәннәре докторы

Тормыш юлының катлаулылыгы, уку һәм яшәү урыннарының төрлелеге, эшчәнлегенең күпкырлылыгы белән татар дөньясында Морад (Мөхәммәдморад) Рәмзигә (10.10.1854-2.04.1935) тиңләшерлек гыйлем әһелләре, Габдерәшит Ибраһимовтан (1857-1944) кала, күзгә бик ташланмый. Аның тәрҗемәи хәле, кылган эш-гамәлләре роман-бәяннарга, күпсерияле кинофильмнарга лаек. Шунысы кызык: бу могътабәр шәхес яшәгән урыннарының шактыен псевдоним-тәхәллүс буларак та куллана: Минзәләви, Казанлы, Мәккәи ... (Әмма болар арасында мин туган авылы, гомер ахырында яшәгән шәһәр исеме белән бәйләнешлеләрен очратмадым. Гарәп-фарсы телләрендә «серле», «символик» һәм кайбер башка мәгънәләрне белдергән «Рәмзи» атамасының нәрсәгә нигезләнеп алынуы хәзергә ачыкланмаган.) Аларга карап кына да бу затның гомер сукмакларын шактый күзалларга була.

XIX гасырның соңгы чирегендә үк дини-иҗтимагый, гыйльми-педагогик эшләр белән ныклап шөгыльләнә башлаган Морад Рәмзинең тәрҗемәи хәле, кылган эш-гамәлләре инде менә бер гасырдан артык вакыт эчендә дистәләгән каләм әһелләре тарафыннан телгә алынып, төрлечә бәяләнеп килә. Болар арасында Ризаэддин Фәхреддин, Н.Катанов, Г.Тукай, Һ.Атласов, Г.Гобәйдуллин (Г.Газиз) һәм кайбер башка билгеле затлар бар.

Совет чорында һәм җирлегендә бу шәхескә («дин әһеленә») бик игътибар булмады. Әмма узган гасырның соңгы чирегендә, аеруча Советлар Берлеге таркалгач, М.Рәмзи белән кызыксыну бермә-бер көчәйде. Аның исем-хезмәтләре Ә.Кәримуллин, М.Юсупов, М.Госманов һәм кайбер башка авторларның язмаларында күзгә ташлана. Болар арасында шәрык белгече Нурия Гәрәеваның* татар һәм рус телләрендә дөнья күргән хезмәтләре аеруча игътибарга лаек. Аның, мәсәлән, «Казан утлары» журналында (1990. – №2) басылган «Кем ул Морад Рәмзи?» дип исемләнгән мәкаләсе [1: 171-175] татар милли җәмәгатьчелегенең тормышында мөһим бер вакыйга рәвешендә кабул ителде. Автор, ышанычлы чыганакларга һәм хезмәтләргә таянып, галимнең тормышы һәм эшчәнлеге хакында төпле бер күзаллау тудыра алган. Шунысын да искә төшерим: соңгы икеөч дистә ел эчендә М.Рәмзи хакындагы язмаларда Н.Гәрәева мәкаләсендәге факт-мәгълүматлар, фикер-күзәтүләр шактый мул файдаланыла.

Сарман төбәгендә туып, гомере буе шунда яшәүче Дамир Гарифуллин (минем яшьтәшем!) җәмәгатьчелеккә шагыйрь, археограф галим буларак яхшы таныш.

* Нурия Гәрәева (1955 елгы) – 1977 елда Ленинград университетының гарәп теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Озак еллар Казан университетының фәнни китапханәсендә сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегендә эшләде. Хәзерге вакытта Татарстан Фәннәр Академиясе составындагы «Мирасханә»нең гыйльми хезмәткәре.

Ул якташы М.Рәмзине өйрәнүгә, пропагандалауга да үзеннән сизелерлек өлеш кертеп килә. Мәсәлән, «Морад Рәмзи – Бикчура хан нәселеннән» исемле язмасында [2: 461-473] галимнең нәсел шәҗәрәсе, тәрҗемәи хәле, эшчәнлеге турында мөһим факт-мәгълүматлар китерә. Гомеренең төп өлешен Кытайда уздырган Мөнир ага Ерзинның «Морад Баһадиршаһ улы Рәмзинең тууына 150 ел тулу уңае белән» язылган мәкаләсендә [3: 143-147] бу зат «бөек галим» дип югары бәяләнә, аның Кытайдагы тормышы яктыртыла.

Соңгы вакытларда М.Рәмзи белән кызыксыну Башкортстанда аеруча көчәеп китте. Дистәләгән мәкалә-хезмәтләр язылу – шуның ачык билгесе. Әмма аларның кайберләрендә татар галимен башкортлаштыру омтылышы да күзгә ташлана. Хәтта И.Насыйров дигән бер авторның «Великий сын башкирского народа» дигән мәкаләсе дә дөнья күргән [Ислам. – 2004. – №1 (8). – С. 24-26] [4: 208]. Төрек дөньясында элегрәк тә, хәзер дә Морад Рәмзи турында язмалар чыгып тора. Болар арасында аеруча милләттәшебез Әхмәд Тимер (1912-2003) тикшеренүләре игътибарга лаек. Мәгълүм ки, бу зат чыгышы белән Әлмәттән (хәзерге Әлмәт шәһәре). 1929 елда ул Төркиягә китә, аннары дистә елга якын Алманиядә укый, эшли. 1943 елдан янә Төркиядә. Дөньякүләм билгеле галим (тюрколог, монголовед). Бик күп телләрне белә. Миңа Әхмәд ага Тимер белән узган гасырның 90 нчы елларында Анкарада берничә мәртәбә аралашырга туры килде. Сарман яклары белән бәйләнешле булуымны белгәч, аның бу районнардагы Иске Әлмәт белән Әлмәт шәһәре арасындагы бәйләнешләр, Морад Рәмзи белән кардәшлек җепләре, аның улы Фәһми белән Төркиядә, Берлинда очрашулар, үзара дустанә мөнәсәбәтләрдә тору хакында сөйләгәннәре бераз хәтердә калган.



Соңгы елларда бу олуг зат турында чыккан хезмәтләр арасында Уфаның яшь галиме шәрыкшенас Салават Әхмәдуллинның (1988 елгы) «Мурад Рамзи как историк тюркских народов России» монографиясе (М., 2022) [4] аерылып тора. Бу китап берничә яктан игътибарга лаек. Беренчедән, ул – гыйльми-академик басма, төрле телләрдәге чыганакларга, шул исәптән архив, кульязма материалларга нигезләнеп язылган.

Анда Морад Рәмзигә мөнәсәбәтле мәкалә-хезмәтләрнең, чыганакларның чагыштырмача тулы библиографик исемлеге бирелгән. Иллюстратив материаллар да бар. Икенчедән, Морад Рәмзинең тәрҗемәи хәле, күпкырлы эшчәнлеге шактый тулы яктыртыла. Кайбер бәхәсле, каршылыклы мәсьәләләр дә телгә алына. Өченчедән, анда кушымта («приложение») рәвешендә «Тәлфикел-әхбар…» хезмәтеннән аерым өзекләр дә (күбрәк башкорт тарихына мөнәсәбәтле өлешләр) шәрех-аңлатмалар белән гарәпчәдән урысчага тәрҗемә итеп бирелә. Кыскасы, С.Әхмәдуллин монографиясе Морад Рәмзине өйрәнүдә, аның мирасын фәнни җәмәгатьчелеккә җиткерүдә мөһим бер баскыч, алдагы тикшеренүләрдә җитди бер таяныч та булып торырлык.

2022 елның 5-6 нчы маенда галимнең туган ягында – Сарманда «Күренекле галим, дин әһеле, мәгърифәтче һәм җәмәгать эшлеклесе Морад Рәмзи: тарих һәм хәзерге заман» темасына багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция үткәрелде. Бөтендөнья татар конгрессы, Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институты, Сарман район хакимияте оештырган бу чарада Татарстан, Башкортстан, Мәскәү һәм кайбер башка төбәкләрнең галимнәре, дин әһелләре, җәмәгатьчелек вәкилләре, Морад Рәмзинең берничә оныгы катнашты. Татар эшмәкәрләренең бөтендөнья ассоциациясе рәисе, тарихчы, Сарман егете, Морад Рәмзи нәселенең бер вәкиле Фәрит әфәнде Уразаев бу конференциянең хәзерлек һәм аны үткәрү комиссиясе җитәкчесе булды. Әйтергә кирәк: әлеге гыйльми-мәдәни чара тиешле югарылыкта узды, матбугатта, электрон чараларда бик тә уңай бәяләнде [5]. Конференциянең чакыру-программасына М.Рәмзинең мондый юллары язылган иде: «Ата-бабаларының нинди кешеләр булганнарын аңлагач, аларда туган илләренә карата мәхәббәт, диннәренә һәм иманнарына карата ашкынулы мөнәсәбәт барлыкка килер дип өметләнәм». Бу гыйльми-гамәли, мәдәни чарада яңгыраган доклад-чыгышларның төп рухы Морад Рәмзинең нәкъ әнә шул сүзләрендәге мәгънә белән сугарылган иде.

Мәгълүм ки, олуг мәгърифәтченең туган төбәге Сарманнан 8 чакрым ераклыкта гына. Бу тирәдә тоташтан татар авыллары. Аларда элек-электән милләттәшләребез яши. Халкыбызның күп кенә әдәбият, сәнгать, гыйлем әһелләренең әлеге төбәктән чыгуы һич тә очраклы түгел. Морад Рәмзи дөньяга килгән Иске Әлмәт авылында электән үк гыйлем-мәгърифәт киң таралган, мәчет-мәдрәсәләр гөрләп эшләгән. Минем әти ягыннан әби – Фатыйма абыстай (ул йөз яшьләр тирәсендә узган гасырның 70 нче елларында Әлмәт шәһәрендә вафат булды) чыгышы белән шул ук Иске Әлмәт авылыннан. Әтисе Фәхреддин (аның бабалары: Шәрәфеддин, Яхъя, Ишгол). Әнисе – Бибихәдичә. Әби еш кына әби-бабаларының укымышлы кешеләр, мәгърифәт әһелләре булуы, Истанбул, Мәккә-Мәдинә якларына барулары хакында сөйли иде. Әлмәт шәһәрендә минем карендәш Бәдерләмган яши (ире – билгеле язучы Әсгать Сәлахов). Аның әти-әниләре узган йөзнең урталарында Апачтан (минем туган авылдан) Әлмәткә киткәннәр иде. Бәдерләмган ханым Дамир Гарифуллин ярдәмендә үзенең нәсел шәҗәрәсен төзеткән. Аның бабасы Гарифеддин (Гариф – 1888-1937) – минем әбинең бертуган энесе. Апач белән Иске Әлмәт арасында, гәрчә аралары 40 чакрымлап булса да, тыгыз элемтәләр яшәп килә. Фатыйма әби минем бабай Миңнеголга кияүгә чыга. Гариф бабай исә Апачка мулла итеп җибәрелә. (Совет чорында – дин әһеле буларак, репрессия корбаны.)

Фәнни әдәбиятта [1; 2; 4; 23] кечкенә Морадка белем-тәрбия бирүдә аның әнисе ягыннан кардәше («дядя»сы) Хөснеддиннең зур роль уйнавы еш искәртелә.

Морад Рәмзигә багышланган фәнни-гамәли конференциядән кайбер күренешләр. Сарман һәм Иске Әлмәт авыллары. 5-6 май, 2022 ел

Бәдерләмгән ханымдагы шәҗәрә буенча, Хөснеддин – безнең Фатыйма әбинең әтисе Фәхреддиннең туганы булып чыга. Димәк, бу юлларның авторы да Морад Рәмзиләрнең XVI гасырдан ук килүче Бикчура ханның нәсел шәҗәрәсенә барып тоташа. Бу бик мөмкин, чөнки әлеге нәсел белән гаять күп кешеләр, хәтта Ризаэддин Фәхреддин буыны да бәйле.

Кечкенә Морад туган авылында белем ала. Кайбер авторлар фикеренчә, ул Сарманнан ерак булмаган Нөркәй мәдрәсәсендә дә бераз укып йөри.

Элек шаулап-гөрләп торган, мәчет-мәдрәсәле күп кенә авылларның хәзер бетеп, сүнеп баруын күреп, йөрәк яна. Шөкер Ходайга, Иске Әлмәт андый түгел. Район үзәгенә якын булуына да карамастан, анда урта мәктәп, мәчет, мәдәният йорты, 2016 елдан бирле Морад Рәмзи музее эшләп килә. Авыл – төзек, чиста, яшеллекле. Урамнарда – асфальт. Аеруча куандырганы шул: мәктәптә укытутәрбия үзебезнең телдә алып барыла. Янә бер куанычлы хәл: Иске Әлмәтнең үзеннән һәм тирә-юнь авыллардан йөздән артык бала җыелып, биредә дини белем һәм тәрбия дә ала, гарәп язуын һәм телен дә өйрәнә.

Морад Рәмзигә багышланган чараларның беренче көне Иске Әлмәттә узды. Конференциянең икенче көне район үзәгендә булды. Кунаклар белән бергә (алар арасында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Мәскәү татар штабы җитәкчесе Рөстәм Ямалиев та бар иде), Сарман төбәге вәкилләре дә докладчыгышлар ясады, рухи, дини-әхлакый мирасны, җирле тарихны өйрәнү буенча кызыклы гына фикерләр, тәкъдимнәр яңгырады.

Сарман, дигәч, бераз гына төп темадан читкәрәк китеп булса да, шәхси характердагы уйлану-фикерләрне, тәэсирләрне дә әйтеп китим әле. Минем туган авыл (Апач) хәзерге вакытта Зәй районында. Әмма ул чоры белән Әлмәт, Сарман районнары составында да була. Бу – бер. Икенчедән, без фәкыйрегез урта белемне Апачтан 25 чакрым ераклыктагы Иске Кәшер мәктәбендә алды. Ул да Сарман районында. Минем газиз әнкәй дә шушы төбәктәге Сарайлы авылында туып-үскән. Әйткәнемчә, әти ягыннан әби дә – Иске Әлмәт кызы. Өченчедән, университетны тәмамлагач, без фәкыйрегез өч елдан артык Сарман районындагы Чукмарлы мәктәбендә директор, КПСС райкомында партия мәгарифе кабинеты мөдире булып эшләде. Шунда ук гаилә корып җибәрдем. Хатыным Рәмзия дә төп чыгышы белән шул райондагы Яңа Имән авылыннан. Ике баламның да туган җире – Сарман. Бу төбәктә минем күпләгән туган-тумачаларым, танышларым бар. Шуңа күрә Сарман минем өчен туган җирем кебек, бик тә якын-кадерле. Сарманлылар үзләре дә мине якташ дип хөрмәт итәләр, төрле очрашу-чараларга чакырып торалар. Рәхмәт үзләренә!

Морад Рәмзи хакында мин махсус хезмәтләр язган кеше түгел. Әмма аның шәхесе, эшчәнлеге турында азмы-күпме мәгълүматым бар. 60-70 нче еллар аралыгында ук Морад Рәмзинең гарәп телендәге «Тәлфикел-әхбар...» хезмәте белән танышып чыккан идем. Ул хезмәттән һәм галимнең аерым язмаларыннан аз-маз мәгълүматны үземнең гыйльми-педагогик эшчәнлегемдә файдаланып торам. Сармандагы Морад Рәмзигә багышланган чараларда доклад-чыгышлар да ясарга туры килде. Хәзер, үзгәләрнең фәнни хезмәтләренә таянып, үземдә тупланган кайбер факт-күзәтүләремне бик кыскача гына бәян итәм.

Ахыры киләсе санда ■

Бөек рәссам Урманче

Зөфәр Мөхәммәтшин

Бакый Урманче Казанга кайткач. 1957 ел

Архив чыганакларына таянып, Бакый Урманченең беренче иҗат җимеше 1926 елда Мәскәүдән укуын тәмамлап кайткач ук башлана дип әйтергә мөмкин. 1926 елда Мәскәүдә аның «Балалар тәрбиясендә сынлы сәнгать» исемле китабы кереш мәкалә белән басыла. Шул ук елда «Безнең юл» журналында «Төркстан милли архитектурасын яңартуда бер тәҗрибә» дигән беренче язмасы дөнья күрә. 1958 елда кабат Казанга кайтып төпләнгәнгә кадәр аның кайда да булса, нинди дә булса темага карата язылган мәкаләләре шәхси архивта әллә ни күренми. XX гасырның 60 нчы елларыннан рәссам бу өлкәдәге эшчәнлеген дәвам итә. Татар мәдәниятенең төрле юнәлешләре, тел, татар тарихы, әдәбият, шигърият проблемалары турында дистәләгән язмалары дөнья күрә, күбесе шәхси архивта каралама хәлдә дә калган. Әлбәттә, максатым аларга нинди дә булса фикер белдерү, анализ ясау түгел. Игътибарны олпат ил агасының татар халкының милли мәсьәләләренә бервакытта да битараф булмавына гына юнәлтермен.

Урманченың язмаларында татар халкының милли тарихында күренекле роль уйнаган шәхесләргә бәя бирүе дә кызыклы. Ул аларның күбесе белән

якыннан аралашкан, бергә эшләгән яисә Соловки лагерьларында бергә утырган. Очраклы очрашкан кешеләре булса да, Бакый Урманче аларның хезмәтләренә үз бәясен биреп, язмалары белән уртаклаша. Мәсәлән, милли тарих һәм мәдәнияттә үз эзләрен калдырган Җамал Вәлиди, Мирсәед Солтангалиев, Камил Якупов, Микъдәт Борындыков, Мәхмүт Бөдәйле, Фатыйх Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Муса Җәлил, Хәсән Туфан, Сара Садыйкова, Сәйфи Кудаш, Исмәгыйль Гайнетдинов, Мирзаҗан Байкиев, П.Беньков, Мәснәви Хәйретдин, казакъның күренекле әдибе, җәмәгать эшлеклесе Мохтар Әүвәзов, милләте буенча казакъ, совет дәүләте һәм партия эшлеклесе Нәзир Төрәкулов һ.б. турында истәлек язмалары гына да рәссамның XX гасыр тарихын ничек иңләвен, нинди затлы, зыялы шәхесләр белән аралашуын ачык дәлилли сыман. Ул әлеге шәхесләр хакында язганда, аларның мәдәни һәм тарихи процесста тоткан урынарыннан тыш, иҗтимагый, сәяси, иҗади эшчәнлекләрен дә тасвирлый. Кайберләре гади генә иҗат портретлары итеп язылса да, бигрәк тә Сталин репрессияләре иләгең узган шәхесләрне искә алганда, аларның фаҗигале язмышларына да тукталып уза. Бу язмаларны укыганда, рәссамның язучылык сәләте барлыгына, әдәби әсәр язу алымнарын файдалануына, замандашларына карата нинди җылы мөнәсәбәттә булуына ышанасың. Хәтта алар үз чорларында җәмгыять өчен каршылыклы шәхесләр булсалар да…

Истәлек язмалар арасында Б.Урманченең «альма матер»е, 1907-1914 нче елларда Казанда мөселман югары мәктәбе саналган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе хакында да хатирәләре сакланган. Рәссамның мәдрәсә турындагы истәлекләре берничә вариантта. Совет чорында татар халкының үткәндәге мирасына игътибарның кимүе, мөселман рухы сеңгән корылмаларның күпләп юк ителүе, дин уку йортларының хәрабә хәленә килүләре, исәннәрен төрле дәрәҗәдәге совет оешмаларына бирүләре белем биргән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең үзе белгән кадәрге тарихын кәгазь битләренә төшереп калдыру ниятен уяткандыр, күрәсең. Хатирәдә шул мотив чагылыш тапкан. Истәлек язмадан күренгәнчә, рәссам мәдрәсәне төрле аспектта ачарга омтылыш ясаган: анда мәдрәсәнең төзелеше, уку-укыту процессы, шәкертләр тормышы, эчке тәртипләре, уку йортын тәмамлаган күренекле шәхесләр хакында мәгълүмат һ.б.ны искә алып китүе, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен шактый киң күләмдә яктыртырга теләве ачык сизелә. Укучыга да шул тулырак вариантны тәкъдим итү урынлы булыр кебек тоелды. Бүгенге «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе укытучылары, шәкертләре өчен дә кызыклы чыганакка дәгъва кылуын да истән чыгармадым.

Бакый Урманче, искә алганча, фәнни фикер йөртә белә торган шәхес тә. Аның кульязмалары арасында һәм шулар нигезендә басылган китапларга бәяләмәләр әлеге фикерне раслыйлар сыман. Мәсәлән, «Яшел бишек нурлары» мәкаләсендә ул Гомәр Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» әсәренә күзәтү ясый, «Күптән көтелгән китап» бәяләмәсендә Тел, әдәбият һәм тарих (хәзер сәнгать) институты тарафыннан әзерләнгән һәм тарихи-этнографик темага язылган «Казан татарлары орнаметлары» (рус телендә) китабына үз бәяләмәсен бирә. Китапның авторы – белгечлеге буенча архитектор, сәнгать белгече, сәнгать фәннәре докторы (мәкалә язылганда тарих фәннәре кандидаты) Фоат Вәлиев. Әлеге китапка бәяләмә язган рәссам, этнографиядән дә хәбәрдар булуын күрсәтеп, бу мәсьәләдә киңрәк фикерләү башка халыкларның этнографик үзенчәлекләре белән чагыштырып тикшерү кирәклеген искә төшерә. Бакый Урманче мәкаләнең йомгагында: «Инде китапның татарча басмасын көтик. Авторның үзенә бер

теләк – татар дигән олы халыкның аерым өлешен генә бүлеп алмыйча, аның башка локаль төркемнәренә дә хас үзенчәлекләрне күрсәтеп, янәдән бер хезмәт булдырса иде», – дип, үз киңәшен дә җиткерә. Мәкалә уңай язылган, әлбәттә. «Яңа китап чыгу уңае белән» язмасында Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты тарафыннан 1985 елда нәшер ителгән «Татар иҗтимагый фикерендә эзлеклелек проблемалары» (рус телендә) исемле җыентыкка бәяләмәсе дә кызыклы. Шәхси архивында сакланган, татар тарихына карата багышлап җыелган материаллар буенча фикер йөрткәндә, Бакый Урманченың тарихи хезмәтләргә бигрәк тә Ш.Мәрҗанинекенә аеруча игътибарлы булуы аңлашыла. Монда рәссамның гарәп һәм фарсы телләрен белүе дә әһәмиятле роль уйнаган. Ул бу бәяләмәдә әле XX гасырның 80 нче елларында Ш.Мәрҗанинең бик аз галимнәргә генә билгеле «Вафийәт әл-әсляф вә тәхийәт әл-әхляф» («Ата-бабаларыбыз турында тәфсилле хәбәрләр һәм килүче буынны сәламләү») һәм 20 нче йөзнең күренекле тарихчысы Морад Рәмзинең «Тәлфикъ әл-әхбар вә тәлкыйх әл-асәр фи вәкагаи Казан вә Болгар мөлүк әт-татар» («Казан, Болгар вакыйгалары, татар патшалары турында мәгълүмат һәм ядкярләр») китабын тикшеренүгә алуларны хуплап чыга. Кызганыч, бу чыганакларның бүген дә үз укучысын таба алганы юк дип әйтерлек. Һәрхәлдә, шуңа омтылышлар булса да… М.Рәмзинең атап үткән китабы, 1917 елгы Октябрь инкыйлабына кадәр басылып чыгу белән, сатудан цензура тарафыннан тыела, аны шул заман укучысы да күрми кала диярлек. Шуны да искәртеп үтү кирәк: Б.Урманченың шәхси архивын күзәткәндә, аерым кәгазьләргә язылган искәрмәләрдә, шулай ук башка тарихи чыганакларны өйрәнү процессында М.Рәмзинең исеме еш искә алынуны исәпкә алсак, ул бу хезмәт белән таныш кына булган дип әйтә алмыйбыз, ә бәлки, шактый материал да туплаган дигән фикер кала. Рәссамны әлеге җыентыкка бәяләмә язарга, гомумән, игътибарын юнәлтергә әлеге хезмәтләр этәргеч биргән дә инде. «Әдәби юллар хакында китап» исемле мәкаләсендә исә аның күренекле әдәбият галиме Тәлгат Галиуллинның татар шигъриятенә багышланган «Еллар юлга чакыра» китабына бәяләмәсе кызыклы. «Кайсы ягы белән кызыклы?» дигән сорау туарга мөмкин. Җавап рәвешендә искәртеп үтим: Б.Урманче – гомере буе шигырь язган шәхес. Ул шәрык һәм европа шигърияте үрнәкләрен, алымнарын яхшы белгән, үзе дә шул стиль-формаларга мөрәҗәгать иткән. Ягъни рәссам бу китапка бәһа биргәндә шигърият кануннарын шактый үзләштергән шагыйрь буларак та чыгыш ясый. Гомумән, Б.Урманче шигърияткә битараф түгел. Аның архивында икенче бер танылган шагыйрь Равил Фәйзуллин шигырьләренә язган бәяләмәсе дә саклана. Кульязма чыганактан күренгәнчә, ул шагыйрьнең яңа төрле шигъри формалар белән мавыгуын бик үк кабул итеп бетерә алмый. Бу – Б.Урманченың шәхси фикере. Рәссамны да аңларга була: ул – күңеле белән шәрык шигъриятенә тартылган, 20 нче йөз башы һәм XX гасырның 20-30 нчы еллар шигъриятендәге шигъри формаларга өстенлек биргән, шул традицияләргә тугрылык саклаган шәхес.

Фәнни язмаларының төп юнәлешләренең берсе – сынлы сәнгать. Ул сынлы сәнгать тарихына, һәм, гомумән, сынлы сәнгатькә багышлап язылган кайбер теоретик фикерле мәкаләләр, рәссамнарның күргәзмәләре уңаеннан басылган язмаларны тәшкил итә. Мәсәлән, аның татар сынлы сәнгате тарихына багышланган «Татар халык сәнгате турында», «Сынлы сәнгать хакында бер-ике сүз», «Казан сәнгать техникумы», «Казан сәнгать мәктәбе һәм ул заман» мәкаләләре аша без татар халкының сынлы сәнгатькә килү юлларын, каршылыкларны,

аның үсешен, татар сынлы сәнгатен формалаштыруга һәм аның үсешенә өлеш керткән шәхесләр белән якыннанрак танышабыз. Һәм, әлбәттә, аерым вакыйгаларга һәм шәхесләргә бәя биргәндә рәссамның субъектив фикерләре белән дә очрашмый калмыйбыз. Ничек кенә булмасын, ул татарның башлангыч чор сәнгать тарихын шактый тирән һәм фәнни яктырткан. Сынлы сәнгатьнең теоретик нигезләрен, мәсәлән, «Абстракционистлар безгә юлдашмы?», «Төркестан милли архитектурасын яңартуда бер тәҗрибә» һәм шулар рәтенә кергән «Балалар сәнгате хакында ата-аналарга, тәрбиячеләргә ни белергә кирәк?» исемле язмаларында ачык күрергә мөмкин. Аеруча аның «Абстракционистлар безгә юлдашмы?» исемле мәкаләсе теоретик фикерләргә бай. Язмадан аңлашылганча, Н.Хрущев идарә иткән елларда сәнгатьтә дә ирекле уйлау, эшләү өчен мөмкинчелекләр туа. Мәкаләдә, рәссам, нигездә, фигуратив һәм абстракт сәнгатьләрнең үз өстенлекләре һәм кимчелекләре турында яза, шулай ук башка агымнарның да сәнгать өчен зарарлы якларын искә алып китә. Һәм, нәтиҗәдә, ул совет чорында сәнгатьнең реалистик агым белән үсәргә тиешлегенә басым ясый. Шәхси архивта сәнгатьнең теоретик нигезләренә караган кульъязма материаллар болар белән генә чикләнми, әлбәттә. Бу очракта мин фәкать басма материалларга гына таяндым.

Гомумән, Б.Урманче сәнгатьнең башка төрләренә дә битараф түгел. Аның шәхси архивында җыр-музыка проблемасына караган язмалары да бар. Кайберләре матбутта да басылган. Мәсәлән, «Филармониядә концерт караганнан соң уйланулар», күренекле татар композиторы Нәҗип Җиһановның 50 еллык иҗатына багышлап язылган «Ярты гасырлык иҗади хезмәт», Казан консерваториясендә Шамил Монасыйпов җитәкчелегендә эшләп килгән кыллы квартетның эшчәнлеге хакында язылган «Казан консерваториясендә квартет», татар җыр сәнгате үсешенә зур өлеш керткән Сара Садыйкова шәхесенә һәм иҗатына бәя биргән язмалары – рәссамның музыка өлкәсеннән дә хәбәрдарлыгын раслаучы мисаллар. Татар музыка сәнгатенә караган һәрбер язмасы гомум күзәтү рәвешендә булса да, Б.Урманченың музыканы аңлавы, күпмедер дәрәҗәдә белүе гаҗәп түгел. Гомерен иҗатка багышлавы, шул исәптән, күпкырлы иҗади сәләтенең шәкертлек елларыннан килүе һәм «лаеш шулпасы»н эчкән чорда ук күңелен биреп скрипкада уйнарга өйрәнүе, гомер көзенә кадәр сакланган баритон тавышлы, моңлы җырчының музыка сәнгатенә үз бәясен бирә һәм белгечләр дәрәҗәсендә мәкаләләр яза алуы үзе үк мактауга лаек.

Б.Урманче язмалары арасында көнүзәк мәсьәләләргә кайтаваз рәвешендә язылганнары да бар. XX гасырның 80 нче елларында үзгәртеп кору чоры башлану белән, милли мәсьәләләр өскә калыкты. Шуларның беренчесе – татар зыялылары арасында «болгарчылык» хәрәкәтенең башланып китүе, ягъни татар исемен «болгар»га алыштыру буенча язмаларның көндәлек матбугатта күренә башлавы. Аларның фикерләре үзләренә күрә теоретик яктан да, тарихилык ягыннан да дәлилләнгән иде, әмма бу төркем вәкилләре күп очракта сәяси мотивларны аңлаудан ерак тордылар. Икенчедән, исем алыштырып кына чит милләтләр арасында нәрсәгә дә булса ирешеп булмаслыгы аларны кызыксындырмады да кебек.

Әлеге вакыйгаларның бер шаһите буларак, азрак лирик чигенеш ясап, бер вакыйганы искә алып китәсем килә. Б.Урманченың мәкаләсе дә шуңа этәрә. Татар исемен алыштыру матбугатта гына түгел, трибуналарда, кара-каршы

бәхәсләрдә дә кабатлана килде. Һәм ул заман өчен табигый да иде. Чөнки җәмгыятьтә, иҗтимагый тормышта тарихи үткәннәрне торгызуга, коммунистлар фиркасы «буып торган» күп кенә фикерләргә юл ачылды. Шулар арасында «күршеләр»нең татар исеменә тискәре мөнәсәбәтенә җавап бирү вакыты да җитүе «болгарчылык»ка кайтырга сәбәп бирде. Бу юнәлештә аеруча күренекле галимнәр тырышлык күрсәттеләр. Әлеге елларда күренекле галимебезнең (исемен язмыйм. – З.М.) шул темага карата китабы басылып чыккан иде. 1990 елда Казанга Мисырда яшәгән татар галимәсе кайтып, галимебезнең әлеге китабы белән кызыксынган иде. Гарәп дөньясында да татарга басып алучылар, кыргыйлар итеп карыйлар икән. Ә ул, шуларга дәлил йөзеннән, галимнән әлеге китапны сорап алып, гарәп телендә бастырырга теләү ниятен әйтте. Галим китапта этноним, этногенез проблемаларына кагылган иде. Бәхәскә без фәкыйрегезгә дә кушылырга туры килде. Гомумән, милләтнең этногенезын табу, билгеләү бик катлаулы, аның өчен фән һәм сәнгатьнең төрле тармакларын – музыка, тел, әдәбият, археология, этнография, антропология һәм башка гуманитар фәннәрнең тарихын белү кирәклеген һәм бүгенге сәяси вазгыятьтә дәүләте булмаган халыкка бу теманы кузгату ярамаганын аңлатырга тырыштым. Шул ук фикерләр Б.Урманче кулъязмалары арасында сакланган, заманында басылмый калган мәкаләдә дә кузгатылган. Флора ханым Әхмәтова-Урманче «Баки Урманче и татарская культура» җыентыгына әлеге мәкаләне «Хәвефле адым (Халкыбызның исемен үзгәртү мәсьәләсенә карата)» исеме белән урнаштырган. Рәссамның бүген дә әһәмиятен югалтмаган төп фикере шушы өземтәдә ачык әйтелгән: «...Кара-каршы сугышларыннан начар истәлек калган да, шуларны ишетеп, «тоеп тору» безгә «бик авырга килә» икән, хәтта халыкның исемен корбан итеп булса да, шул уңайсызлыктан тизрәк котылырга кирәк икән!

Әйтәсе дә юк, бик тә юмартланып китү булып чыгар иде бу! Ләкин һич тә җитди сәбәп түгел, куак астына кереп посу кебегрәк беркатлылык килеп чыга. Шунда ук беренче сөаль туа. Хуш. Ә исемне алыштырганнан соң тискәре бәндәләрнең ул исемне тагын да ярсыбрак битәрли башлаулары ихтимал түгелмени? Ул чагында безгә нишләргә генә кала соң? «Без – без түгел, без татар түгел!» – дип, бернәрсә дә ишетмәгәнгә салышыргамы? Исемне алыштыру белән генә башка халыкка әверелеп булмый бит! Менә нәрсәне бик тирән аңларга кирәк». Бу фикергә нәрсә дә булса өстәү урынсыздыр дип уйлыйм. Б.Урманче сәясәтче түгел, әмма болгарчылар күтәргән мәсьәләнең милләт өчен фаҗига белән бетәчәген аңлаган, аңлатырга теләгән.

Кыскасы, Б.Урманче, рәсем сәнгате һәм скульптура белән шөгыльләнүдән тыш, татар гуманитар фәненә, музыкага һәм сынлы сәнгатькә, этнографиягә, көнүзәк мәсьәләренә дә битараф булмаган. Ул, төп шөгыленнән аерылып, боларга үз мөнәсәбәтен белдереп килгән. Шунысын да искәртү кирәктер: әлеге язмалар җитди, дәлилле, шул өлкәдә хезмәт куйган белгечләрнең язмаларыннан бер дә ким түгел. Алардагы җитди фикерләр бүген дә актуальлеген югалтмаган. Шул яклары белән әһәмиятле дә.

Дәвамы бар ■

Безнең мирас №8 август 2022

Татарның «наив» сәнгать юнәлешендәге беренче рәссамы

Дания Гайнетдинова, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

Әлфрид Шәймәрданов

Әйе, Әлфрид Шәймәрданов үзе дә, сынлы сәнгатьтә мин – революционер, дияргә ярата. Бу, чынлап та, шулай. Аны күбрәк чит илдә һәм Мәскәүдә беләләр. Татарстанда «наив» сәнгать төре әлегә аз билгеле. Бу сәнгатьне аңлаган белгечләр Әлфрид Шәймәрдановны татарның беренче «наив», татарчалаштырып әйтсәк, беркатлы саф сәнгать остасы, тере классигы дип атыйлар. Әлфрид – белеме буенча киноинженер. Ул тамашачысын чын мәгънәсендә әлеге сәнгать төрен танырга һәм рәссамнарны хөрмәт итәргә өйрәтергә дигән максат куеп эшли. Әлфрид Шәймәрданов үзе дә: «Мин матди байлыкка битараф диярлек, мине идеяләр кызыксындыра. Идея хакына ахыргача барырга әзермен», – ди.

«Наив» сәнгать төре, бер караганда, чынбарлыкка да туры килми кебек. Шул ук вакытта, классиклар – А.Руссо, Н.Пиросмани, М.Генералич иҗатларын барласак, әлеге төрнең никадәр мөмкинлекләр бирүенә таң каласың. Әлфрид Шәймәрданов – Казанда яшәп, иҗаты белән читтә күбрәк танылу алган рәссам. Чөнки сәнгатьнең әлеге төрен чын мәгънәсендә аңлаучылар, абруйлы белгечләр һәм сәнгатьнең бу төрендә иҗат итүчеләрнең эшләрен сатып алырга теләүче коллекционерлар бездә юк дәрәҗәсендә. Әмма аларга чит илдә кытлык кичермисең. «Кешеләр сәнгатьне аңласыннар өчен, наданлык белән көрәшергә кирәк», – дип аңлата моны автор.

Әлфрид Шәймәрданов тумышы белән Саба районының Сабабаш авылыннан. Ленинградның киноинженерлар әзерләүче институтын тәмамлый. Әлфрид аннары, Казанга кайтып, Кинохроника студиясендә эшләп ала. Ләкин күңеле иҗатка тартыла һәм ул, шушы хыялын тормышка ашыру өчен, кулына кылкаләм ала. Моңа төп сәбәпче, бәлки, аның Ленинградта укыган вакытта иң якын дусты, укытучы һәм сәнгать белге-

«Көтү». 2012 ел.
Киндер, майлы буяу, 120х100 см

«Гомерлек бәхет». 1995 ел.
Киндер, майлы буяу, 105×94 см

че Иван Соловьев булгандыр. Буш вакытларда алар бергәләп төрле күргәзмәләргә, музейларга, китапханәләргә йөриләр. Сәнгать белгеченең әйткән һәр сүзе, эчкерсез фикерләре Әлфридкә нык тәэсир итә, аны иҗатка рухландыра. Иван Степан улы Соловьев та Әлфриднең сәнгатькә күбрәк тартылуын сиземләп, бәлки, син кулыңа буяулар алып ни дә булса ясап карарсың, дип киңәш итә. Әлфрид Шәймәрдановка дустының бу сүзләре, әйтерсең лә, канатлар куя. Ул, әлеге белгечлек буенча белеме булмау сәбәпле, үзен «наив» сәнгать юлында сынап карарга була. Әлеге сәнгать юлына кереп китәргә, бәлки, бабасы Шәймәрдан Гәрәевнең агач эшләре буенча чын оста булып, заманында йорт җиһазлары, чүкеп, бизәкләп ясаган сандыклары белән танылуы да этәргеч биргәндер. Ул заманында әлеге кул эшләре белән авылда гына түгел, чит өлкәләрдә дә танылу алган алтын куллы оста санала.

Кулына кылкаләм алуга, Әлфрид Шәймәрданов, тамашачы күңелендә үзенең иҗаты аша шушы сәнгатькә юл ача. Беренче әсәрен ул 1993 елда иҗат итә. Шуннан бирле автор бөтен яшәешен әлеге иҗатка багышлый. 1997 елда Әлфрид Шәймәрданов Татарстанны беренче тапкыр Словакиянең Братислава шәһәрендә узган Бөтендөнья «наив» сәнгате күргәзмәсендә таныта. Аннан соң ул Мәскәүдә Рәссамнарның үзәк йортында «Кышкы бизәкләр» исемле шәхси күргәзмәсен тәкъдим итә. Соңрак Германия, Литва һәм Болгария илчелекләрендә күргәзмәләр оештыра. 2001 елның июнендә Казанга Бөтендөнья мирасы шәһәрләре оешмасында әгъза булу турындагы сертификат тапшыру өчен килгән ЮНЕСКО генераль директорының урынбасары М.Бушенакига аның «Картофель, сорт «Михаил» дигән картинасы бүләк ителә.

Әдфрид Шәймәрдановның 2011 елда – «Казан» милли мәдәни үзәгендә, 2012 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советында шәхси күргәзмәләре уза. Аннан соң Мәскәүдә «Фестнаив-2013» күргәзмәсендә, 2014 елда Латвиянең Рига Конгресслар йортында үткән Россия сынлы сәнгать осталары күргәзмәләрендә катнаша. Рәссамнарның Испания,Чехия һәм Польшада да күргәзмәләре оештырыла. Сәнгатькә тәүге адымнарын ясаганда ул рәссам-абстракционист буларак та шактый әсәрләр иҗат итә. «Шар очып китте», «Яшел ямансулык», «Оверкиль» дигән эшләре узган гасырның туксанынчы еллары башында ук «Авангард кичә, бүген, иртәгә» дигән республика күргәзмәсендә катнаша. Иҗатының башлангыч чорында аңа эшләр өчен остаханә һәм файдалы киңәшләре белән танылган рәссам Харис Якупов та булыша. 2018 елда Республикабызның Дәүләт сынлы сәнгать музеенда

узган шәхси күргәзмәсендә автор күләмле эшләре белән тамашачыны таң калдырган иде. Соңгы елларда Мәскәүдә һәм үзебезнең Татарстаныбызда да Әлфрид Шәймәрдановның күргәзмәләре еш оештырыла. Аның тылсымлы иҗат эшләрен тамашачылар да үз итеп өлгерде. 2018 елда ул Николай Фешин исемендәге премиягә лаек булды, эшләре Лондонда нәшер ителгән «NaiveArt: Volume» наив-рәссамнар каталог-альбомына да кертелде.

«Иҗатым белән Татарстаныбызны чит өлкәләрдә, дөнья күләмендә танытасым килә», – дияргә ярата Әлфрид.

Менә аның гаять зур күләмле «Очевидное невероятное» («Кеше ышанмаслык дөреслек») картинасы. Автор монда Казаныбызның нәкъ үзәгендә, Кол Шәриф мәчете янында Минтимер Шәймиев җитәкчелегендә Ибн Фадлан һәм аның делегациясен каршы алуны сурәтләгән. Бер карашка бу күренеш, чыннан да, кеше ышанмаслык бит! Әмма автор аны шулкадәр оста итеп ясаган ки, ышанмас җиреңнән шул чорга әйләнеп кайтасың. Автор картинаның бер серле урынын табып: «Гомер – кыска, сәнгать – мәңгелек» һәм «Без булдырабыз, без җиңдек», – дип язып та куйган. «Гомер – кыска, сәнгать – мәңгелек» әйтемендә автор сәнгать остасының уйларын чагылдырса, «Без булдырабыз, без җиңдек» дигәнендә исә М.Шәймиевнең уй-хисләрен, эчке кичерешләрен бирергә омтылган. «Әлеге әсәр аша Татарстанны һәм аның зурлыгын күрсәтәсем килде һәм татар рәссамнарын ерак чит илләрдә дә белсеннәр иде дигән уй белән иҗат иттем», – ди ул. Бу – сирәкләргә генә бирелә торган сәләт. Чыннан да, аның үзен дә, махсус белеме булмау сәбәпле, шактый еллар Россия Рәссамнар берлегенә кабул итмичә килгәннәр. Әмма әсәрләре чит илләрдә танылу алгач, Россия Рәссамнар берлеге бу җитешсезлекне тиз арада төзәтә. Әлфрид Шәймәрданов үзе дә чит ил «наив» сәнгатендә танылу алган рәссамнардан үрнәк алып иҗат итә һәм шул биеклектән төшмәскә омтыла. Аның иҗаты чын мәгънәсендә тылсымлы да, уй-кичерешләргә дә бай һәм шул ук вакытта анда сихри яшерен серләр дә таба аласың. 2021 елда «Заман» нәшриятында Әлфрид Шәймәрдановның саллы гына альбомы да дөнья күрде. Анда авторның Россия һәм Европа илләре музей һәм галереяларында, шәхси коллекцияләрдә сакланган иң яхшы эшләре урын алган. Күңелендә туган образларын тиз генә киндергә төшереп, тамашачы хозурына тәкъдим итә автор. Әлфрид Шәймәрданов, көнне төнгә ялгап, тәүлекләр буе остаханәсендә эшләп утырырга мөмкин. Уйланган уйлары, күңелендә туган яңа образлары тизрәк киндердә җанлансын гына. Менә шундый тынгысыз рәссам инде ул. Аңа иҗатында яңадан-яңа үрләр яулап, татарның «наив» сәнгатен алга таба да дөньякүләм танытуда уңышлар теләп калыйк! ■

«Кеше ышанмаслык дөреслек»

Илһам абый

(Филармониядә бергә эшләгән вакытлар истәлеге)

Фәрдия Сәфәргалиева, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе



Илһам Шакиров

2 июнь, 1999 ел. «Моңлы тавышыңны тыңладым»

Илһам абый безнең бүлмәгә керде дә, минем эш өстәле янына килеп: «Иртән синең моңлы тавышыңны тыңладым», – диде. «И-и-и, шаян да инде син, Илһам абый!» – дидем мин сүзнең нәрсә турында барганын абайламыйча. «Юк, чыннан да шулай, – диде ул. Аннан соң: –Филармонияне кем генә сүкми инде аны. Гел начар сүз генә сөйлиләр аның турында», – дип куйды. Шулкадәр дә үзәгенә үткән икән...

Филармониянең күркәм эшләре, яңа гына оештырылачак Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт ансамбле турында сөйләгән идем. Иртән радиодан шуны тыңлаган икән Илһам абый.

3 июнь, 1999 ел. «Ә мин талантларны яратам»

Җәй җылы булмады быел. Эш урынында – Филармониядә дә салкын. Урамда +18° кына.

Салкын бүлмәбездә туңа-туңа эшләдем дә, клей белән кайчы алырга дип, беренче катка төшәргә булдым. Нәкъ баскыч алдында Илһам абый очрады. Исәнләшеп кенә узып китәргә уйлаган идем, Илһам абый кочаклап алды. Ә мин, аптыраган хәлдә: «Әй салкын да инде бүген, Илһам абый», – дип, салкын кулларымны күкрәгемә кушырып куеп, балачакта әтиемә, абыйларыма сыенгандай басып калдым. Илһам абый: «Сине беренче тапкыр кочаклавым бит, Фәрдия!» – диде. Мин: «Әйе шул, Илһам абый», – дип җавап бирдем. Артистларның очрашканда кочаклашып исәнләшүләренә бераз ияләнә башлаган идем инде. Илһам абый: «Нәрсә өчен кочаклаганымны беләсеңме?» – дип сорады. Мин: «Нәрсә өчен соң, Илһам абый?» – дидем. Ә Илһам абый: «Талант бит син, Фәрдия! Мин моны башка вакытта әйтә алмам, шуңа хәзер әйтәм, – диде дә: – Ә мин талантларны яратам!» – дип, тиз генә борылып китеп тә барды. Мин ул киткән якка карап калдым. Илһам абый миңа мондый сүзләр әйтер дип башыма да килгәне юк иде. Төштер бу. Филармониягә килеп бер ел эшләгәннән соң Илһам абыйның бу сүзләрен ишетергә насыйп булды.

Беренче катка төшмичә, кире борылып бүлмәмә кердем дә бергә эшләгән кызларга сөйләдем. Нигә сөйләгәнемне үзем дә аңламыйм, барысы да минем иҗатымны хуплаучылардан түгел иде югыйсә... Шундый бөек шәхеснең: «Талант бит син, Фәрдия!» – дигән сүзләрен бөтен дөньяга ишеттерәсем килгәндер инде. Шулай булмыйча! Ничек тыныч калып булсын, ди, инде?! Сүз минем татлы иҗатым – үзем сценарий язып, үзем сәхнәләштергән, үзем үк, алып баручы буларак, тамашачылар хозурына тапшырган йөздән артык әдәби-музыкаль кичәләр, концертлар, шулай ук матур эчтәлекле афиша текстлары төзүем турында бара бит. Моңарчы иҗат ителгән кичә-концертларның берничәсен генә күреп тә, иҗади эшчәнлегемне югары бәяләгән, татар халкының мәшһүр җырчысы, профессиональ белемле, киң карашлы, Тукайның тормыш юлын, иҗатын тирәннән белгән Илһам Шакировның үземә әйткән сүзләре бит бу! Башың әйләнеп әллә кайларга «очып китүең» дә бар, мондый сүзләрне ишеткәч...

Тинчурин театры бинасында мин алып барган кичәләр вакытында (Хәнәви Шәйдуллин, Флюра Сөләймановаларның иҗат кичәләре) Илһам абыйның сәхнә артында утырулары исемә төште. Барысын тыңлап, күзәтеп утырган, күрәсең... И Илһам абый, Илһам абый!

15 июнь, 1999 ел. «Фольклор ансамблен теләсә нинди урында, теләсә кайсы халык алдында күрсәтерлек булсын иде дип хыялланабыз»

Мәдәният министры карарын тормышка ашыру ниятеннән, Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт ансамблен оештыру эшләренә кереште. Ансамбльгә килергә теләүчеләр өчен конкурс игълан ителде. Бүген гариза бирүчеләрне комиссия тыңлады: Илһам Шакиров, Әсгать Сафин, мин, Ринат Гыйләҗев, Рөстәм Вәлиев, Әнвәр Ибраһимов, Әлфия Кәримова.

Унсигез кеше арасыннан җиде кешене сайлап алдык. Директорыбыз Әсгать Сафин ансамбльгә эшкә алынучылар алдына куелган таләпләр белән таныштырды һәм: «Натан Рахлин да заманында, 1966 елда, үзенең оркестрын өч ел дәвамында бик сайланып кына туплаган. Безнең ансамбль дә әкренләп кирәкле җырчыларны, музыкантларны җыйнар, әлегә шушы состав белән ныклап эшкә тотынырга кирәк. Бүгенге көндә Симфоник оркестрда – 118 кеше, уен кораллары оркестрында – 60, Опера бүлегендә – 17, Эстрада бүлегендә 25 кеше эшли. Филармониядә барлыгы 309 хезмәткәр», – дип, сүзен тәмамлады.

Газетада, игълан белән беррәттән, булачак ансамбль турында Илһам абый язмасы да («Тибрәндерсен күңел кылларын». – «Мәдәни җомга». 23 апрель, 1999 ел) чыккан иде. Бүген ул булачак ансамбль артистларына теләкләрен җиткерде. «Шул фольклор ансамблен теләсә нинди урында, теләсә кайсы халык алдында күрсәтерлек булсын иде, дип хыялланабыз. Кыскасы, тирән милли, югары профессиональ икән, ул инде интернациональ дә була», – диде Илһам абый.

Мәшһүр җырчыбызның хыялы тормышка ашты. Бүгенге көндә Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт ансамбле (сәнгать җитәкчесе – Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахманов) башкалабыз Казанда, республикабыз районнарында, дөньяның төрле почмакларында чыгышлар ясаган, милли моңыбыз сагында торучы, үзенә генә хас башкару осталыгына ирешкән уникаль иҗат коллективы буларак дан казанды.

17 июнь, 1999 ел. Моң

Илһам абый үз бүлмәсендә, Пианинода уйнап, тональностьларны үзгәртә-үзгәртә кабатлап, тавышын чарлый. Русча әйткәндә, «распевка» ясый. Бүген иртәдән үк шулай. Аннан соң аккомпаниатор белән репетиция ясый. «Уянсыннар кырлар», «Өммегөлсем» җырлары – икесен дә кабат-кабат башкара. Баянга җырлый. Әлегә кем уйнаганын белмим. Илһам абыйның тавышы көчле һәм моңлы яңгырый. Белмәгән кеше бу җырларны 64 яшьлек Илһам Шакиров җырлый дип һич уйламас. Филармониягә милли аһәң агыла... Мин Илһам абыйның җырлаганын тыңлыйм. Ярый әле бүлмәләребез янәшә дип шатланам, яхшы ишетелә.

«Ай әле бик еракта идек без...» – дип суза Илһам абый. Моң агыла. Күршемдә – сандугач! 19 июньдә Казанда Сабан туе булачак, Илһам абый шуңа әзерләнә, күрәсең. Башта «Идел буе каеннары», «Җәй айлары» дигән җырларны кабатлый, аннары «Ай янында якты йолдыз», «Бик сагындым Ык буйларын, Ашыгып аккан суларын...» – дип моңлана.

Җыр агыла. Бу моң күңелне сихри бер дулкында йөздерә. Җырчының тере тавышын, микрофонсыз җырлаганын тыңлау бөтенләй башкача шул! Югыйсә туган-

Илһам Шакиров һәм Рөстәм Вәлиев

нан бирле тыңлыйм бит инде Илһам Шакировны, аның безнең өчен җыр эталоны булган моңлы җырларын! Балачакта гаиләбез белән радиодан концерт тыңлап елап утырганда, әти-әниемнең: «Ник елыйсың, кызым?» – дип сорауларына, елаудан туктый алмыйча сулкылдап: «Апаемны сагындым...», – дип җавап биргәнемне хәтерлим. Олы апабыз Флераның Казанда пединститутта укыган чагы. Моңлы җыр уяткан сагыну хисләре...

Илһам абый җыр арасында баянчысы белән сөйләшкәләп ала. Кабат җырлый. Репетиция тәмамлана. Тынлык. Бераздан: «До завтра, ага!» – дигән сүзләр ишетелә. Димәк, баянда Рөстәм Вәлиев уйнаган.

16 сәгать 15 минут. Илһам абый өенә кайтып китә.

23 июнь, 1999 ел. Бүген дә моңлана...

Илһам абый бүлмәсеннән бүген дә моң агыла. Рояльдә – танылган пианист Тәлгать Әхмәтов.

Бүген кич Хәйдәр Бигичевнең тууына 50 ел тулу уңаеннан оештырылган искә алу кичәсендә җырлыйсы бар Илһам абыйның. Кабат-кабат җырлый. Мин, эшемне «ташлап», җыр тыңлыйм...

1 август, 1999 ел. «Ник үзеңне куймадың?»

Көндезге ял вакытында йөреп керергә булдым. Горький урамы буйлап Филармониягә кайтып барышым. Гоголь урамы белән кисешкән урында – Филармония янындагы бакча ягында Илһам абый белән Әхмәт Гадел сөйләшеп тора. Исәнләшеп кенә китмәкче идем, Илһам абый кулымнан тотып туктатты. Әхмәт Гадел комплиментлар әйтә башлады, шунда ук ир белән хатын темасына анекдот

та сөйләп алды. Ә Илһам абый мине иңнәремнән кочып алды да: «Үзе хәтле ике кызы бар, шуңа күрә шундый яшь ул!» – дип куйды. Мин: «Оныгыбыз да булырга тора, Илһам абый», – дип өстәдем. Олы кызыбыз бер ел элек кияүгә чыккан иде. Илһам абый шунда ук Әхмәт Гадел белән саубуллашты да, икәү култыклашып әкрен генә филармониягә таба китеп бардык.

Филармониягә кергәч, эш бүлмәләребезгә юл алдык. Бераздан Илһам абый безнең бүлмәгә килеп керде. Стенадагы Татарстан Республикасы халык уен кораллары дәүләт оркестры (сәнгать җитәкчесе – А.Я.Шутиков) концертының афишасына игътибар итеп: «Ә-ә-ә, чыкты да мени инде?» – дип куйды. Афишада язылганнарны укый башлады. Алып баручы – Эльмира Хәмитова, дип язылган иде. «Кем бу?» – дип сорап куйды Илһам абый. «Яшь кенә кыз, моңарчы концертлар алып барганы бар иде», – дидем. Илһам абый: «Ник үзеңне куймадың?» – ди. «Шутиковның теләге шундый», – дип җавап бирдем мин. Илһам абый: «Һе...», – дип куйды да, бүлмәбездән чыгып китте. Күрсенүен күрмәгән булсам да җитә иде инде миңа. «Ник үзеңне куймадың?» – дип соравыннан күңелем күтәрелеп китте.

1 сентябрь, 1999 ел. Илһам абый белән беренче тапкыр фотога төшү

Иртән эшкә килүемә: «Сине Илһам абый чакыра», – диләр. Сумкаларымны бүлмәмә кертеп куйдым да Илһам абый янына кердем. Ә анда Резидә Галимова, Рөстәм Маликов, читтәрәк Газинур Фарукшин һәм тагын бер мин белмәгән кеше (соңыннан белдем, фотограф икән, Илһам абый махсус чакырткан) нәрсә турындадыр сөйләшеп торалар. Барыбызны да фотога төшәргә чакырган икән Илһам абый. Бергәләп фотога төштек. Илһам абый минем белән аерым да төште. Аның белән беренче тапкыр фотога төшү иде бу. Барыбыз бергә төшкәннәрен Филармониядә буласы чаралар турында язганда газеталарга да биргәләдем.

Бүген шуларны алып карыйм да: «Ничек шәп эшләде Илһам абый шул вакытта фотограф чакыртып, нинди матур истәлек бит!» – дип куям.

Фәрдия Сәфәргалиева Илһам Шакиров белән. 1999 ел

Дәвамы бар ■

Безнең мирас №8 август 2022

Барабаннар кемнеке дә, балалайка кемнеке?

Айрат Чанышев

Фото ddn24.ru сайтыннан алынды.

Сүз уңаеннан шуны да әйтик: иң популяр кыллы музыка коралы гитара да чыгышы буенча – шәрыктан. Ул фарсыларның дутар/гутары. Фарсы телендә ул ике кыл дигәнне аңлата. Өч кыллы гутар/дутарны фарсылар – ситар, дүрт кыллысын – чартар, биш кыллысын – пәнҗтар, алты кыллысын шаштар дип атаганнар. Шәрыкның ул гутар/дутары башта Испаниядәге гарәп Андалузиясенә үтеп кергән, шуннан бар Европага таралган.

Украиннарның атаклы бандурасы да татардан, татарның думбырасыннан. Кавказ татар-төркиләре (кумыклар һ.б.) думбыраны бандыр, бандыра (пандыр, пандур, пандыра һ.б.) диләр. Нәкъ менә шул Кавказ татар-төркиләренең бандырбандырасыннан барлыкка килгән дә инде украиннарның бандурасы. Бандура турында беренче язма искә алулар Польша хроникаларына карый. Мәсәлән, Зигизмунд Август заманындагы хроникаларда король капелласы составында Чурило һәм Длугарай атлы бандурачыларның хезмәт итүләре теркәлеп калган. Монда инде шул күренә: бу бандурачыларның исем-атлары саф татарча – Чүриле һәм Тулыгәрәй. Бу факт үзе үк бу музыка коралының татарныкы булуын дәлилләп тора. Украиннарның бугай (үгез тиресе тартылып эшләнгән барабан, бугай – татарның бога-үгез сүзеннән), торбан (Даль,Фасмер һ.б. татарның торба сүзеннән барлыкка килгән дип исәплиләр), кугиклы дип аталучы музыка кораллары да – татардан. Кугиклы элек кувиклы дип аталган, ул татарның куыклы дигән сүзеннән. Шунысын да әйтеп китәргә кирәк: күп кенә татар-төркиләрдә куык сүзен кугык диләр. Татарның төрле озынлыкта куыклы (эче куыш) үсемлекләрне бергә бәйләп ясал-

Ахыры. Башы журналның 7 нче (2022 ел) санында.

ган бу музыка уен коралы шул ук вакытта русларның да милли мирасы булып киткән. Татарның куыклысы – Европадагы беренче авыз гармуны.

Русларның, шул ук вакытта украиннарның, белорусларның, молдаваннарның, полякларның, румыннарның һәм башка күп кенә халыкларның татардан алган тагын бер музыка уен коралы – кубыз, кыл-кубыз. Русларда ул кобыз (кобуз), украиннарда – кобиз. Шул ук украиннарда кобзарь дигән сүз бар. Ул халык чәчәне, акыны, җыраучысын аңлата торган термин булып кереп калган. Беренче кобзарьлар – казаклар, гадәттә, казакларның сугышта катнашкан, ул сугышларда төрле җәрәхәтләр, имгәнүләр алган өлкән ветераннары булганнар. Алар, кобзаларда (йә бандура-думбыраларда) уйнап, казак дастаннарын башкарганнар, казакларның яулардагы батырлыкларына дан җырлый торган булганнар. Бу факт – украиннарның барлыкка килүендә татар компонентының шактый гына булуын раслый торган тагын бер аргумент. Чөнки казаклар чыгышлары буенча – татарлар, дәүләтләре җимерелгәч, казаклыкка далага китәргә мәҗбүр булган Олы Урда татарлары. Кубыз, гомумән, дала халкының, татар-төркиләрнең борынгы музыка уен коралы, ул атта барганда тартып барырга бик уңайлы-кулай булган.

Тынлы музыка уен коралларына күчик.

Татарның русларга һәм башка күп халыкларга бүләк иткән тагын ике музыка уен коралы – сорнай һәм торба («Сурна была позаимствована нашими предками у татар», В.Михневич). Торба һәм сорнай гаскәри музыка уен кораллары буларак та киң кулланылган, татар сорнае һәм торбасы яугирләрне яуга чакырган, сугыш хәрәкәтләре белән идарә итүдә кулланылган. Татарның торбачысы русларга һәм башка халыкларга трубач (трубачи), сорнайчысы сурнач (зурнач, сурначи, зурначи) булып кереп калган. Монда сүз кушымтасы үзе үк бу сүзләрнең татарныкы булуы турында әйтеп тора. Тагын шунысын да әйтергә кирәк: Московиядә, Рәсәйдә скрипкачылар, гадәттә, татарлардан булганнар (бәлки, ул Европа скрипкасы түгел, ә татарның кыл-кубызы булгандыр). Шуңа да скрипкада уйнаучыларны руслар, украиннар һәм кайбер башка халык вәкилләре, саф татар кушымтасы белән, скрипач дип атап йөртәләр дә. Сорнай – бик борынгы уен коралы, ул кыпчакларга да билгеле булган.

Барсына да мәглүм, киң таралыш алган (русларда, украиннарда, белорусларда, полякларда, венгерларда һ.б.) дуда-дудка дип аталучы музыка уен коралы да татардан. Бу сүзнең барлыкка килүендә (шул ук вакытта уен коралының да) русларның дуть фигыленең бер катнашы да юк. Радлов та: «Дудка – от дудук (чаг., крым., тур.) свирель, флейта, свисток; дудукчу (тур.), флейтист...», – дип яза. Е.Н.Шипованың «Словарь тюркизмов на русском языке» сүзлегендә дә бу уен коралының исеме (шул ук вакытта килеп чыгышы да) шулай аңлатыла.

Хәзер инде иң киң таралган музыка уен коралы – гармунга тукталып китик. Без алда татарның куышлы дип аталучы музыка уен коралы турында язып киткән идек инде. Аның Европадагы беренче авыз гармуны булуы хакында да. Авыз гармуны Европада фәкать XIX гасырда гына барлыкка килгән. Ә Кытайда бу музыка коралы бик күптәннән, моннан 3 мең ел элек, Чжоу династиясе заманында ук билгеле булган. Кытайлылар бамбук таякчыкларын бергә бәйләп йә беркетеп авыз гармуны ясый торган булганнар, бу уен коралы аларда шен (шэн) дип аталган. Төрле юанлыктагы һәм озынлыктагы әлеге бамбук таяклары төрле ноталар барлыкка китергәннәр. Андагы тишекләрне кулланганда аеруча. Соңыннан бу уен коралы камилләштерелгән, ул көпшә-торбаларны эче куышланган бер агачка беркетеп, шул куышка өрер өчен мөштек, бамбук куышлыкларына телчекләр

урнаштыра башлаганнар һ.б. Кытайлыларның шен дип аталучы шул авыз гармуны аннары Алтын Урдада да таралыш алган, татарлар бамбук урынына эче куыш башка үсемлекләрне (камыш, җикән, курай үләне һ.б.) кулланганнар, аны куышлы (эче куышлы) дип атаганнар. Соңыннан татарлар бу уен коралын агачтан да, башка материаллардан да эшли башлаганнар. Шулай итеп, Европада иң беренче авыз гармуннары Алтын Урдада, татарларда барлыкка килгән һәм бар Европага таралган. Мисал өчен, молдаван һәм румыннарның авыз гармуны – найны алыйк. Ул – татарның наеннан. Най (кайвакыт нәй) дип татарлар, гадәттә, камыштан (җикәннән) эшләнгән өреп уйналучы музыка коралына әйткәннәр, аннары эче куыш үлән яки куактан эшләнгән башка өрмә уен коралларын да най дип атап йөрткәннәр. Берничә эче куыш үлән (яки башка материалдан) көпшә-торбаларны бәйләп яки беркетеп эшләгән музыка уен коралларына да татарлар най дип әйтә торган булганнар. Татарның беренче авыз гармуны куышлыдан, ягъни, икенче төрлерәк әйтсәк, татарның наеннан молдаван һәм румыннарның нае барлыкка килгән дә инде. Сүз уңаеннан әйтик, сорнай сүзенең тамырында да шул най сүзе ята. Ул сур+най сүзләрен кушып ясалган. Монда сур – быргы, сурнай – быргы-най була инде (татарча «сур өрерләр» дигән гыйбарәне искә төшерегез).

Гармуннар турында сүз кузгаткач, күрекле гармуннарга да тукталып китик. Анысының кайда барлыкка килүе төгәл ачыкланмаган. Кайберәүләр аны Германиядә уйлап чыгарганнар, икенчеләре исә, бер чех остасы ясаган беренче гармуннан килеп чыккан дип яза. Бу уен коралы шәрыкта барлыкка килгән, шәрыктан ул Россиягә күчкән, Россиядән Европага таралган дип исәпләүчеләр дә бар. Чынлап та, беренче гармуннарның прототибы нәкъ менә шул кытай шены булырга мөмкин. Хәзерге камилләштерелгән шен – шактый катлаулы уен коралы. Ул, инде әйтеп кителгәнчә, куышлыгы булган нигездән тора, әлеге нигез куышлыгына төрле юанлыктагы һәм озынлыктагы көпшә-торбалар беркетелгән. Музыкант шенда уйнаган вакытта мөштектән шул куышлыкка өрә һәм, көпшә-торбалардагы тишекләргә басып, төрле ноталар чыгара. Бу инструментны ниндидер мини орган дияргә дә була. Җитмәсә, ул көпшә-торбаларның эчләренә гармуннардагы кебек металл телчекләр дә беркетелгән. Күпвакыт берничә кеше берничә шенда уйный. Һәрхәлдә, даими һава агымында металл телчекләр кулланып төрле ноталар чыгару иң беренче шул шен дип аталучы уен коралларында файдаланылган, шуннан соң гына ул күрекле гармуннарда урын алган. Анысы да бик соң – XIX гасырда гына. Ә татарлар металл телчекләрне кубызларына моннан күпкә элек куя башлаганнар, кытайлылар да шеннарына, татарларның бабаларыннан күреп, металл телчекләр урнаштырганнар. Шулай итеп, гармун татар кубызларыннан – татар кубызларын бергә, бер тартмага урнаштырып, аңа күрек ялгап килеп чыккан дип бер дә шикләнмичә әйтергә була. Гармуннарның бабалары – татар кубызлары, кытай шеннары.

Гармуннар арасында иң популяр булганы – баян. Монысының атамасы исә – саф татарча. Бар чыганаклар да әлеге уен коралы үз атамасын русларның гөсләдә уйнап җырлап йөрүче чәчәненнән, Баян атлы мифик персонажыннан алган дип раслыйлар. Баян (Боян) «Слово о полку Игореве» дип аталучы тарихи чыганакта искә алына. Баян – үзе үк татар сүзе, борынгы татар-төрки исеме – Байьян. Рус чыганаклары да Баянны богатый дигәнне аңлата торган болгар-төрки исеме дип язалар. Баян атлы тарихи шәхесләр татар-төрки дөньясында күп, шулай ук Баянов фамилияле кешеләр дә. Мәсәлән, татар-төркиләрнең Европадагы атаклы Авар каһанлыгына Баян I хан нигез салган, аннан тыш, Баян IIсе дә булган әле бу

каһанлык ханнары исемлегендә. Бөек Болгариянең (Азак буе Болгариясенең) дә Бат-Баян атлы ханы булган, чыганаклар аны кайвакыт Баян хан дип кенә язалар. Дунай Болгариясенең дә бер ханы Баян атын йөрткән (Баян Владимирович). Бу хан җыраучы-акын да булган, халык аны сихер көченә ия дип санаган. Шактый авторлар (В.Миллер, Ю.Венелин һ.б.) «Слово о полке Игорове»дагы легендар чәчән Баянның прототибы нәкъ менә шул Дунай Болгариясе ханы дип исәплиләр дә. Гомумән, болгарларда (Дунай буе болгарларында) Баян исеме киң таралыш алган.

Татарның борынгы Байьян исеме Баян формасында татар-төркиләрдә дә, русларда да һәм башка халыкларда да шактый киң кулланылышта. Башка халыкларның татар-төркиләр арасында яшәүчеләрендә аеруча күп. Мәсәлән, император Николай IIнең шәхси китапханәчесе Баян исемле булган, Баян Владимирович Иванов. Ул Урал артының татар-төрки (башкорт) Исәнгол авылында (Зианчура районының үзәге) җирле табиб гаиләсендә туып-үскән.

Легендар чәчән Баянның, чынлап та, кайчандыр яшәгән тарихи шәхес икәнлеге күпләрдә шик уятмый. Тик аның тормышы, кем булуы турында гына бернинди дә мәгълүмат юк. Аның сакланып калган җыр текстларын анализлап, галимнәрнең күбесе шулай фараз итәләр: ул Төмәнтарханда (рус чыганакларында – Тьмутаракань) туып, шунда чәчән-җыраучы булып киткән. Аннары Чернигов кенәзенә хезмәткә кергән (аның сараенда гөсләдә уйнаучы, җыраучы булып). Һәркемгә мәгълүм: Төмәнтархан – кыпчак шәһәре, бер кыпчак ханлыгының башкаласы, Баян яшәгән XI гасырда аның халкы татар-кыпчак телендә сөйләшкән.

Шулай итеп, атаклы музыка уен коралы баянның аталышы – татардан, татар-төркиләрдән. Билгеләп үткәнебезчә, ул – татар-төрки чәчән Баянның исеме.

Татарда «Кузы-Көрпеш (Кузы Көрпәч) һәм Баянсылу» дигән дастан бар, аның версияләре бик күп. Шунысы кызык: бар татар-төркиләрдә дә әлеге дастанның бик үк күңелле финал белән тәмамланмаган вариантын төп версия итеп алганнар. Бөтен җыентыкларга да, барлык белешмәләргә дә шуны урнаштырганнар. Бу версия буенча, ике ханның (байның) бер үк вакытта кызлары һәм уллары туа. Алар бу малай белән кызны бала вакытларында ук бер-беренә ярәшеп, кодалашырга килешәләр. Тик соңыннан Кузы-Көрпешнең әтисе үлеп китә, аның гаиләсе фәкыйрьлеккә төшә. Баянсылуның исән ата-аналары, Кузы-Көрпешнең ярлы әнисе белән туганлашырга теләмичә, кызларын башка берәүгә бирергә карар кылалар. Әнисеннән насыйп ярының кем булганлыгын белеп алгач, Кузы-Көрпеш аны юллап чыгып китә, тик Баянсылуны инде башка кешегә кияүгә бирергә җыенып йөриләр. Ярәшелгән ярына барганын белеп, яңа кияү кешеләре Кузы-Көрпешне үтерәләр. Аның үлемен ишеткәч, Баянсылу да үз-үзенә кул сала. Шулай фаҗигале тәмамлана бу ике яшь йөрәкнең мәхәббәте дастанның киң таралган әлеге версиясе буенча. Бу инде совет чоры идеологиясенә 100 процент туры килүче версия, анда байлар һәм ярлылар, патша заманында гади кешеләрнең ирекле булмавы хакында ул чорларда тормышның авыр булуы һ.б. турында бәян ителә.

Тик чынлыкта бу төп версия түгел. Гомумән, Баянсылу белән Кузы-Көрпеш – Алтын Урда чорында гомер иткән тарихи шәхесләр. Чынбарлыкта шулай булган. Урал алды далаларында яшәгән Кузы-Көрпеш музыка коралларында уйнап җырларга бик оста булган. Ул татар шыбырында (волынкасында), кузы-көрпәдә уйнап һәм җырлап, тыңлаучыларны таң калдырган.

Татарның бөек дәүләте Алтын Урда әлеге чорда зур мәдәният үзәге булган, аның йөзләгән шәһәрләрендә меңләгән җырчылар, музыка коралында уйнаучылар,

чәчәннәр татар сәнгатен үстерүгә хезмәт иткәннәр. Мисал өчен, татарның атаклы шагыйре Хисам Кятибның «Җөмҗөмә солтан» поэмасыннан бер өзек китерик:

«Һәм йите мең мотрибчым бар иде:
Меңе – чәңче, меңе – кубызчы иде.
Меңе – найчылар ирди, меңе – быргу;
Меңе – табл орар ирди, меңе – аргу;
Меңе – чалгу чалар ирди, меңе – дәф;
Меңе – чәмбал орар ирди, меңе – кәф...»

Монда саналган ул чор татар музыка уен коралларының никадәр күптөрле булуына гына да сокланып туя алмаслык! Мәсәлән, мин чәңченең нинди уен коралында уйнаганын, аргуның, кәфнең нинди музыка коралдары булуын, матрибчының кем икәнлеген (бәлки, ул – музыканттыр?), чалгу чалуның ни булуын күз алдына да китерә алмыйм. Ә бит элек боларның барысы да һәм аларда уйнаучы меңнәрчә кешеләр дә булган татарда һәм боларның барысы да шул алдарак китерелгән юлларда, татарның әдәби мирасында теркәлеп калган.

Ни кызганыч, татарда Алтын Урда да өйрәнелми тарих дәресләрендә, Алтын Урданың мәдәни мирасы да (ул татар музыка уен коралларын әйтеп тә торасы юк инде), әдәби мирасы да. Татар әдәбиятын Мәүла Колый белән Утыз Имәнидән башлап кына өйрәнә хәзерге татар баласы. Анысы да – татарча белем бирү мәктәпләрендә генә, алары да бик кыскартылган хәлдә генә. Кятиб, Сәйф Сараи кебек татар әдәбияты гигантларын исә татар баласы белми үсә. Ә татарның тарихы – татарның олуг-бөек тарихы, татарның данлы тарихи шәхесләре, күпсанлы шанлы мәмләкәтләре турында хәзерге татар балалары да, татарның олылары да берни дә белмиләр...

Алтын Урданың башкаласы Сарайда ул вакытларда төрле җыраучыларның, чәчәннәрнең, акыннарның, музыка коралларында уйнаучыларның бәйгеләрен үткәргәннәр. Кузы-Көрпеш, шул конкурсларда катнашырга, дип, Сарай шәһәренә киткән. Аның да, таныш-якташларының да Кузы-Көрпешнең җиңеп чыгачагына бернинди шикләре дә булмаган. Тик, егетне таң калдырып, икенче бер яклардан килгән Баянсылу атлы бер кыз, гөсләдә уйнап-җырлап, беренче урынны алган. Бу ике яшь йөрәк шулвакыт бер-беренә гашыйк булган, алар кавышканнар, гаилә корганнар. Аннары инде бик оста чәчәннәр, гөсләдә, кузы-көрпәдә бик оста уйнаучылар, җыраучылар булгач, шәһәрдән-шәһәргә, авылдан-авылга, җәйләүдән-җәйләүгә күченеп тамаша күрсәтеп йөргәннәр. Халык аларны бик яраткан. Кузы-Көрпеш белән Баянсылу бик озак яшәгәннәр, бик бәхетле гомер кичергәннәр.

Хәзер инде бу персонажның ни өчен Кузы-Көрпеш дип аталуына тукталып китик. Кузы татар телендә бәрән дигәнне аңлата. Мәсәлән, кузгалак дигән сүз кузы+колак сүзтезмәсеннән барлыкка килгән, аның формасы бәрән колагына охшаганга, бу үсемлекне шулай атаганнар татарлар. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә көрпә сүзенең мәгънәсе: «бәрән тиресеннән махсус ысул белән эшләнгән мех, тире». Төгәл генә әйткән вакытта, көрпә – бәрәннең малны ярмый гына салдырып алынган тиресе, бөрдек, саба. Бөрдекне татар-төркиләр су, кымыз, башка эчемлекләрне салып йөртү өчен махсус эшләгәннәр. Бу вакытта инде тиренең аяк очындагы бер тишеге бөрдекнең авызы булып хезмәт иткән, калган тишекләре тыгыз итеп бәйләп куелган.

Бөрдек шул ук вакытта музыка уен коралы буларак та кулланылган татар-төркиләрдә (татар волынкасы рәвешендә). Әлеге уен коралын татарлар шыбыр яки кузы-көрпә дип атап йөрткәннәр, ягъни бәрән бөрдеге дип. Бу уен коралында инде бөрдек тишекләренең берсенә һава өрү өчен мөштек урнаштырылган, калган икесенә яки өчесенә тишекле агач көпшәләр беркеткәннәр. Шул көпшәләрнең төрле тишекләренә басып, уенчы төрле ноталар чыгара алган. Татарның шыбыры, кузы-көрпәсе бүгенге көнгә кадәр сакланган, аны кырым татарлары – толып-сорнай, ә Казакъстан татарлары җилбуаз дип атап йөртәләр. Тик Идел-Урал татарлары гына үз шыбырларын, кузы-көрпәләрен торгызырга бер дә ашыкмыйлар.

Гомумән, бөрдек тә, шул җәһәттән аннан эшләнгән шыбыр һәм кузы-көрпә дә мал күп асраган халыкларда – дала халыкларында барлыкка килгән. Утрак тормышлы халык сыеклыкларны саклау һәм күчереп йөртү өчен борынгыдан ук балчык чүлмәкләр, балчык савытлар кулланган. Ә күчмә, ярымкүчмә – атта күп йөрергә кирәк булган халыкларда (шул җәһәттән татар-төркиләрнең бабаларында да) чүлмәк савытлар бер дә уңай булмаган, алар тиз ватылганнар, аларны, мәсәлән, ияргә элеп тә булмаган. Шуңа да алар атта йөрергә кулай бөрдекләр уйлап тапканнар. Аннары инде ул бөрдекне музыка уен коралы итеп тә файдалана башлаганнар. Шуңа да европалыларга һәм башкаларга бөрдекләр, шыбыр һәм кузы-көрпә кебек музыка уен кораллары татар-төркиләрнең бабаларыннан, дала халкыннан – ит ашаган, кымыз эчкән, атта чапкан татар-төркиләрдән үтеп кергән дип без бер дә шикләнми әйтә алабыз. Авыл яки шәһәрдә яшәп, иген үстереп, камыр ризыгы һәм бәрәңге ашаган халыкларда нинди дер бөрдек, кузы-көрпә уйлап табу мөмкин булмаган, бөрдек аларга кирәкмәгән дә. Ә татар-төркидән үзләштерелгән бу уен коралын шотландлар, мәсәлән, үзләренең милли символы дип игълан иттеләр. Алар хәзер ул волынкаларын бик ыспайлап-матурлап – бизәкләп-сырлап, заманча материаллар кулланып эшлиләр. Ә әлеге музыка уен коралының төп хуҗалары булырга тиешле татар-төркиләрдә аны хәзер бәрән тиресеннән эшли белгән кешеләр дә юк диярлек.

Кузы-Көрпешнең дастандагы бу исеме үз исеме түгел, ул кузыкөрпәче (кузыкөрпәч), ягъни кузыкөрпәдә уйнаучы сүзеннән барлыкка килгән. Аның чын исеме – Субра. Әлеге легендар чәчән татар-төркиләрнең тагын бер дастанына Идегәй дастанына үтеп кергән. Идегәй дастаны иҗат ителгәндә ул инде бик картайган чәчән-җыраучы булган. Дастанда бәян ителгәнчә, Токтамыш (Туктамыш) хан аны Идегәйнең чынлыкта кем булуын белү өчен чакыртып ала. Дастанда инде картайган Сабра-Кузыкөрпеш турында болай диелә:

«Йөз туксан ел яшәгән,
Утыз тешен ашаган
Субра сынлы суп җырау...»

Шулай итеп, язмабызны төгәлләп шуны әйтәсе килә: татарның бөек мәдәни мирасы, чиксез бай музыка сәнгате, санап бетергесез күптөрле музыка уен кораллары, аяныч ки, башка халыкларның казанышы, милли горурлыгы булып киткән, кайберләре исә ул халыкларның милли символына да әйләнгән.

Татарларга үз мәдәни мирасын, аерым алганда, үз музыка уен коралларын кире кайтарырга, аларны яңадан торгызырга, кулланышка кертергә, бар дөньяга танытырга вакыт җитмәдеме икән?!. ■

Җуелмас хәзинә

«Яшә, республикам!» җыры

«Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр».

Габдулла Тукай

Тәртип радиосы

«Яшә, республикам!»

(Татар халык җыры)

Биек тауның башларында
Уйный каплан баласы. *(2 мәртәбә кабатлана.)*

Кушымта:
Яшә, минем республикам,
Яшә, Казан каласы!

Аккошлар йөзә күлләрдә,
Былбыл куна гөлләргә.
Җырлый-җырлый без барабыз
Алдагы шат көннәргә.
Кушымта.

Безнең илләр – ямьле җирләр,
Үсә бездә ал гөлләр.
Гөлләр кебек матурланды
Безнең хәзерге көннәр.

Кушымта:
Яшә, минем республикам,
Яшә, Казан каласы!

«Яшә, республикам!» – туган ил, туган җир тематикасына карый торган җыр. Без мәктәптә укыган елларда, аеруча башлангыч классларда укыганда, бу җырны җырламый калган җыр дәресе булдымы икән! Чөнки әлеге елларда балалар җырлардай җырлар күп түгел иде кебек. Без патриотик җырлар, Гражданнар сугышы, Бөек Ватан сугышы турындагы җырларны җырладык. Бу, бәлки, ул заманда шулай кирәк тә булгандыр.

Композитор Җ.Фәйзи әйтүенчә, ул бу җырны Рәшит Мозаффаров дигән кешедән 1951 елда язып алган. Р.Мозаффаров искә алганча, бу җыр 1920 нче елларның башын-

Күренекле опера артисты, җырчы (меццо-сопрано), композитор, фольклорчы, ТАССРның атказанган артисты (1936), Татарстанның халык артисты (1952), РСФСРның халык артисты (1968), Казан шәһәре тумасы Мәрьям Мәннан кызы Рахманкулова (1901-1990)

да, Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы оештырылган вакытта ук яңгырый башлаган булган.

«Биек тауның башларында
Уйный каплан баласы...»

«Әлеге юллар миңа башта сәеррәк тоелды, – дип искә ала композитор. – Татарстанда биек тау да, каплан җәнлеге дә юк бит (каплан – кара таплы, сары тиреле ерткыч җәнлек). Киная белән әйтү икән ул. Биек тау башы – ул югарылыкка, биеклеккә омтылу, ә уйнаган каплан баласы – халык дәрте, көчлелек икән».

Бу җырны заманында җырчы Мәрьям Рахманкулова башкаруында радиодан еш тапшыралар иде.

*Сәхифәне, «Тәртип» радиосында яңгыраган «Саф вә раушан көзге» тапшыруы (авторы һәм алып баручысы – **Гөлфия Мөхәммәтгәрәева)** материалларына нигезләнеп, **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №8 август 2022



КОРМАШЧЫ-ҖӘЛИЛЧЕ
РӘХИМ САТТАРНЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Рәхим Саттар шигырьләре

Рәхим Саттар (1912-1943)

Рәхим Саттар (Габделрәхим Сөләйман улы Габделсаттаров) 1912 елның 15 августында хәзерге Башкортстан АССРның Чишмә районындагы Түбән Каҗәт авылында крестьян гаиләсендә туа. Дүртенче класста укыганда ук инде ул шигырьләр яза башлый. Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, башта туган ягында төрле эшләрдә йөри, аннан Казанга күчеп килеп, «Кызыл яшьләр» газетасында әдәби хезмәткәр һәм җаваплы редактор урынбасары булып эшли.

Рәхим Саттар 1941 елның җәендә үзе теләп сугышка китә, десантчы булып күп кенә хәрби операцияләрдә катнаша. 1942 елның маенда чираттагы хәрби операция вакытында чолганышта калып, фашист әсирлегенә төшә. (Әсирләр арасында каршылык хәрәкәте оештыру өчен махсус җибәрелгән, дигән фараз да бар.) Берничә ай Смоленск һәм Борисов шәһәрләре лагерьларында тоткынлыкта булганнан соң, Берлин янындагы Вустрау шәһәренә озатыла. Шунда ул Абдулла Алиш белән очраша, Муса Җәлил һәм җәлилчеләрнең яшерен антифашистик оешмасы эшенә якыннан катнаша башлый. 1943 елның июнь аенда ул лагерьдан кача һәм билгесез югала. Рәхим Саттарның ничек вафат булуы турында фаразлар гына яши. Имеш, ул җитәкләгән төркемгә качарга урманчы поляк ярдәм иткән. Урман эчендәге яшерен сукмаклар аша поляк аларны Варшавага кадәр озаткан. Соңыннан ул полякны фашистлар кулга алган һәм җәзалап үтергән. Качкын легионерлар исә засадага эләккән. Печән кибәне астында яшеренеп торган вакытта аларга фашистлар ут ачкан. Бер төркем кеше шулай терелэй янып үлгән...

Халкым өчен

Көнчыгышта алсуланып
Ата ал таң.
Күккә калкып таулар күренә,
Гүя, калкан.
Алга карыйм. Анда ята
Томан һаман.
Ерак Туган илдә яши
Газиз анам.
Коралдашлар яу кырында!
Кайда соң мин?!
Кем мин сиңа, ятиммени?
Әйт, Туган ил!
Бар хәсрәтең, бар михнәтең
Миңа уртак.
Син генә сук, син иркәлә,
Син мине как.
Ләкин син бел: һәр сулышым,
Барлык көчем
Синең өчен, Туган илем,
Синең өчен!



Рәхим Саттарның качар алдыннан Абдулла Алишка тапшырган 24 шигыре тупланган 1964 елда Казанга кайтып ирешкән блокноты

Иптәшем

Сары барак шыгрым тулы иде, –
Утырдык без озак.
Күптән инде якын кеше белән
Сөйләшергә сусап.

Күрше булып, зәңгәр күзе белән
Утырды Николай.
Беренче кат күреп аны беләм,
Япь-яшь әле – малай.

Ул сугышта, кан эчендә йөзеп,
Яраланып ауды.
Ерткыч дошман кызганмады аны,
Әсир итеп алды.

Зәңгәр күзен тутырып миңа карый,
Коңгырт күзләремә.
Тавышы моңлы, йөрәгемә җылы
Аның сүзләреннән.

Дус ул миңа, якын иптәш миңа,
Батыр ул Николай.
Әллә кемнәр аны, дошман, диләр,
Юк, түгел ул алай.

Без икебез, кулбашлар беркетеп,
Арысландай булып,
Уртак дошман булган фрицларны
Еракларга кудык.

Уртак Ватанны без бергә саклап,
Ирек өчен аудык.
Кызыл канга батып калды шунда
Сеңелем биргән яулык.

Әнкәм теләп калды миңа саулык,
Сеңелем бүләк итте кулъяулык.
Яраланды янда юлдашым,
Бәйләп киттем аның кулбашын. ■

Татар шигъриятендә мөһаҗирлек хәрәкәте һәм Исхакый

Тәлгат Галиуллин, филология фәннәре докторы

Сибелгәннәр дөнья буйлап

«Мөһаҗир» сүзе, шәхес культы фаш ителеп шактый сулар акканнан соң, үткән гасырның алтмышынчы еллары ахырында, Мәхмүт Галәү наменнән кара тамга алынып, аның «Мөһаҗирләр» исемле тарихи романы дөнья күргәч, киң әйләнешкә кереп китте. Төрле сәбәпләр белән туган илләреннән читтә яшәүчеләрнең атамасы булып киткән мөһаҗирлек бик борынгы чорлардан күченеп, атын иярләп яисә арбасына утырып дөнья кулясасын кулында тоткан татар менталитетның, холык-менәзнең бер атавизмы булса кирәк. Икенче яктан, күреп, татып караганчы ук, Көнбатышның сүздәге милли сәяси иреклелеге ымсындырып торгандыр, күрәсең!

Шул рәвешле, мөһаҗирлек тарихы ерак-еракларга барып тоташа икән. Бигрәк тә Казан ханлыгы Ислам динен кабул иткәч, хаҗга, Мәдинә, Мәккә, Бохара, Стамбул кебек гыйлем үзәкләренә барулар өстенә, сәүдә, алыш-биреш шөгыльләре «дөньяга чыгу» юлларын киңәйткәннәр.

«Элек алар күпме булган да, хәзер елдан-ел туган телләрен, милли гадәтхолыкларын югалта барган мөһаҗир кан-кардәшләребезнең саны нинди?» – дигән сорауның тууы табигый.

Журналист Тәлгат Насыйров мондый мәгълүматы белән уртаклаша: «1917 елгы октябрь түнтәрешеннән соң кузгалган күчеш чорында меңнәрчә татар Русиядән Төркиягә юнәлә... 1970 нче елларда бу илдә 25 меңләп татар яши»[1]. Бу санга Финляндия, Австралия, Америка, Кытай, Япония һ.б. төбәкләргә күчеп киткән татарларны өстәсәк, шактый саллы күрсәткеч килеп чыгар иде.

Профессор Х.Й.Миңнегулов татар мөһаҗирләренең саны турында болай ди: «Аклар», «Әсирләр» (ике Бөтендөнья сугышы тоткыннары. – *Т.Г.*) составында чит мәмләкәтләргә эләккән милләттәшләребезнең саны берничә дистә меңгә якын»[2]. Әлбәттә, бу саннар да төгәллеккә дәгъва итә алмыйлар. Чөнки татар мөһаҗирләренең санын алу, исем-фамилияләрен, һөнәрләрен язып калдыру белән бер оешма да, аерым галим яисә сәясәтче дә максатчан шөгыльләнмәгән. Дөнья совет шымчылары белән шыплап тутырылган чорда бу тыелган темага алынырга бик сирәкләр генә җөрьәт иткән.

Мөһаҗирлек татар кавеме уйлап тапкан хәрәкәт түгел. Матбугатта күренеп алган хәбәрләргә караганда, 1917 елгы октябрь борылышыннан соң 5 млн. рус телле кеше чит илгә чыгып китә. Рус, украин, яһүди, әрмән качакларының чит илләрдәге язмышлары турында сүз алып барганда, бер мөһим үзенчәлек-

[1] «Мәдәни җомга» газетасы. – 2009, 20 ноябрь.
[2] Чит илләрдәге татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2-7. – Б.9

аерманы искә алу кирәктер. Хикмәт шунда: татар мөһаҗирләре томанлы билгесезлеккә бары тик үзләренә ышанып чыгып китсәләр, телгә алынган халыкларның, бигрәк тә рус телле мәдәният әһелләренең Ауропаның Париж, Берлин, Лондон һ.б. шәһәрләрендә барып сыеныр, таяныр диаспорасы, меценатлары, банклары, хәтта үз зиратлары булуы мәгълүм.

Төркия, Франция, Алмания һ.б. мәмләкәт хөкүмәтләренә эшкә ялланып, өлешчә исем-фамилияләрен үзгәрткән, мәгәр мәсләкләренә турылыклы калган укымышлы татар мөһаҗирләре, үз табигый халәтләре, үҗәт тырышлыклары белән, гаҗәеп зур уңышларга ирешәләр. Җөмләдән, Й. Акчура (1876-1935) «Төрк йорды» журналының баш мөхәррире, Төркиянең Бөек Милли мәҗлесе депутаты, Кемал Ататөрекнең киңәшчесе, Стамбул университеты профессоры, 1931 елдан вафатына тикле Төрек тарих җәмгыяте рәисе вазыйфаларын башкара. Русия Дәүләт Думасы депутаты чорында ук Тукай теленә эләккән С.Максуди (1878-1957) әүвәл Парижда Ислам институты профессоры, Төркиягә күчкәч, шул ук вазыйфаны Стамбул дәрелфөнүнендә башкара, ә инде 1930-1938 нче елларда Бөек милли мәҗлес депутаты була. «Зиндан» повестенда ук хакимияткә ярарга тырышуны милләтеңә хыянәт итү дип санаган Гаяз Исхакый, төрле илләрдә яшәгәндә рәсми хезмәткә керүдән баш тартып, ашказанында «бүреләр улый» башлагач кына, тамак ялына эшләп алгалый. Төрле илләрдә яшәгән милләттәшләре дә, аның фидакарьлеген югары бәяләп, матди ярдәмнәреннән ташламыйлар.


Гаяз Исхакый

Мөһаҗирләрнең бөек дәрәҗәгә ирешкәннәре өстәмә итеп төрек фамилияләрен алсалар, Исхакый кушамат-тәхәллүсне, нигездә, саф татар сүзләреннән ясый: Казанлы, Ураллы, Тимер, Хәбибрахман әл-Болгари, Котлы Мөхәммәт, аеруча Иделле дигән ачыкламышны еш куллана. Үзенең чит ил кешесе икәнен ачкан бердәнбер төрек сүзен – Япанчыны (чит ил кешесе) куйгалый. Туган җирендә яшәгәндә дә, мөһаҗирлек чорында да Исхакыйның яшәеш кредосы шул ук кала. Туган халкына каршы алып барылган геноцидны фаш итү, милләтне уяулыкка чакыру, генофондын саклап калу, «Идел-Урал» штаты рәвешендә булса да, татарның дәүләтчелеген торгызу (ул – реалист, теләкне мөмкинлектән чыгып кына калкытып куя) аның мәңгелек хыялы булып кала.

Г.Исхакыйның дусты, якташы журналист Фуад Туктаров (1880-1938) Төркиядә матбугат эшчәнлеген дәвам итә, бу илдә беренче халык китапханәсен ачып дан казана. Ринат Мәннан Г.Исхакыйның 130 еллыгына багышлап, балаларны күздә тотып язылган «Исхакый белән өч кич» шигырендә Гаяз, Максуди янәшәсендә Туктаровны да атый:

«Гаяз, Фуад һәм Максуди
Милли эшләр башкара.
Ике ел үзендә тота
Бөтенләй чит башкала».

Париж, Берлин шәһәрләрендә «Туран» җәмгыятендә хезмәт иткәннән соң, Туктаров, Анкарага килеп, башы-аягы белән мәгърифәт-агарту эшчәнлегенә чума.

«Хөкүмәт китапханәсе»,
Мөдире – Фуад Туктар».
(Р.Мәннан «Көрәштәшләр»)

Туктаровның үлеменнән соң, Г.Исхакый каләмдәшенә сирәк шәхескә эләгә торган югары бәясен бирә: «Фуад – милләтне сөюдә, үз-үзен тәрбия итә белүдә, халкы өчен үзен корбан итә белүдә үрнәк булып калачак». Алдарак китерелгән мисаллар татар мөһаҗирләре, туган илләрендә яшәгән милләттәшләренә матди-сәяси ярдәм күрсәтә алмасалар да, халкыбызның абруена тап төшермичә, дөнья базары биеклегенә күтәрелгән асыл затларны бирә алуларын, бер мохиттә дә югалып калмауларын исбат итәләр.

Урман кисүгә җибәрелеп тә, шунда калып, соңрак төрле өлкәләрдә сәләтләре ачылган фин татарларын искә төшерик. Аларның төрле милләтләр белән уртак тел таба алуы милли холык-гадәтләребез, әхлакый тәрбиябез белән аңлатыла. Әхмәт Рәшит «Мөһаҗирләр» шигырендә «татар табышмагы»ның чишелешен, җавабын эзли. «Сибелә чәчәк» җырын көйли-көйли, Сибелгәнбез ерак-еракка», «Мөһаҗирлек мәллә канга сеңгән» кебек юллар халкыбызның күченеп йөрүгә һәвәслегенә, күңелендә җыр-моңын онытмавына ишарә ясаса, «Ризык мәллә шулай йөртә» гыйбарәсе аңардан гына тормаган, югарыдан иңгән мәҗбүрияткә кинаяли. Бу уйланулар укучыны шигырьнең мәгънәви вә кичереш йөген кабул итүгә әзерлиләр: алгы нәүбәткә туган өммәтнең балалары белән горурлану хисе чыга. Татар милләте баласының язмышы аны кайсы төбәккә ташламасын, ул, солтан булмаса да, олтан дәрәҗәсенә төшми. Әлбәттә, бер йодрык кебек үз туган җирләрендә яшисе урынга халык улларының төрле кыйтгаларга, Русиянең төрле төбәкләренә сибелүе милли фаҗига иде.

Кешене язмыш йөртә

Неон утлары, «тәти уенчыклары» белән үзләренә тартып, ымсындырып торган чит-ят илләргә чыгып киткәннәрнең өметләре акланмыйча, туган илләренә әйләнеп кайтулар мәшәкате, ягъни мөһаҗирләр язмышы бер татар шагыйрен дә битараф калдырмый, дисәк тә, дөреслеккә хилафлык булмастыр.

Халык язмышының көзгесе – әдәбиятта «килү-китү», «кайту-кайтмау» мәүзугы әледән-әле күтәрелә килгән үзәк тормышчан һәм фәлсәфи мотивларның берсе буларак яши, бәгырьләрне өздереп алга таба үстерелә. Күпчелек тезмәләрдә мөһаҗирләрнең хәленә керү, авыр язмышларына теләктәшлек мотивы үзәктә тора:

«Киткәннәр… калган милләте,
Туып-үскән җир, өммәте…
Урталай калган өзелеп
Йөрәге – булган кыйммәте!»
(Равил Рахмани «Киткәннәр»)

Киткән очракта да «үзең» булып калу, милләт каршындагы вазыйфаңны онытмаска чакыру авторның «Китүләр» шигырендә дәвамын таба:

«Китәрбез...
Тик үзең булып кит –
Күтәргән вазыйфаң үтәргә кичекмә!»

Шигъри уйның сәнгатьчә калыбын метафорик фикерләү табу җәһәтеннән, мөһаҗирлек юлын сайлаганнарга төгәл бәяләре белән, «киткәннәр», «китүләр» – тирән фәлсәфи-этик эчтәлекле гыйбарәләр. Читкә чыгып китүчеләрне гаепләргә ашыкмыйк. Берәү дә мөһаҗирлекне ирекле сайлап алмаган. Аны илдә урнашкан иҗтимагый халәт, тиреләк «кысып» чыгарган дигән фикер уздыра Равил Рахмани.

Күренә ки, шагыйрь мөһаҗирлек язмышын дәүләтчелекне югалту, мөстәкыйльлек булмау, кол халәтебез кебек мәҗбүрият белән аңлата. Шул ук фикер сөреше Әхмәт Гаделнең «Горбәтлектә кичкән гомер» шигыренең кичереш үзәгенә алына:

«Сагындым... Тик еллар үтте.
Гүя, таң җилләре исте...
Рәхәт түгел, әлбәттә.
Кичкән гомер горбәттә».

Үзенә читтәнрәк карап бәя биргән мөһаҗирнең эчке сөйләме (монологы) алдарак туып-үскән илләреннән читтә гомер сөрүчеләрнең һәм, гомумән, татарның авыр язмышына алып чыга. Югары өслүб юк. Нибары сәнгатьчә деталь генә:

«Калдырды татар, алдырды
Аякларын чит илдә,
Тимәсен дип «дәү ага»га
Суыгы да, җиле дә».
(Әхмәт Гадел «Горбәтлектә кичкән гомер»)

Харрас Әюп «Хәтер» шигырендә, язмыштан узмыш юк, илдә калганнар, киткәннәрне кире какмыйча, авыр сүзләр әйтмичә, күңел түрләрендә сакларга, берсен дә онытмаска тиешләр, дигән фикер уздыра:

«Яшерелмәс вакыт пәрдәләре,
Киткәннәр дә кире кайтырлар –
Безгә хәтер юкка бирелмәгән,
Югалмасын бары хәтерләр!»

Хәтер – адәм балаларын табигый инстинкт белән яшәүче башка җан ияләреннән аерып торучы бөек байлык, буыннар арасына күпер салган Ходай бүләге, ди шагыйрь.

Мөһаҗирләрне генә күздә тотмаса да, шагыйрь Мөхәммәт Мирза мондый язмышка тарган кешеләрнең рухи бәргәләнүен шактый төгәл ачып бирә:

«Килү-китү арасында
Бертуктаусыз юл икән.
Гомер итү чарасызлык
Урап үтү юк икән».

Рәдиф Гаташның «Мөһаҗир», Зиннур Мансуровның «Мөһаҗирләр» шигырьләре – туып-үскән газиз җир белән аерылу сагышының фәлсәфи-этик, милли-мәдәни нигезләрен ачуга, мөһаҗирлек күренешен киңрәк колачларга омтылышлары белән үзенчәлекле әсәрләр. Р.Гаташның «Мөһаҗир»е, соң чиккәчә тартылган кыл шикелле, югары хисси нотада, күңелнең түрендә яткан кыңгырауларын хәрәкәткә китерердәй фаҗигале тарихи сәхифәне искә алу белән башланып китә:

«Төтен күк язмыш юлыннан
Йөз ел элек, яшь бер шагыйрь –
Мөһаҗир!
Син кая киттең?»

Алдагы юлларда «Туган ярдан» күзен ала алмыйча «таш кебек катып» калган мөһаҗирнең рухи халәтенә юл эзләнә. Аның туган җиренә мәхәббәте укучыга җиһанда барган буталу-чуалулар, ачынулар, югалтулар «шәүләсе»ндә ирештерелә:

«Ил, бул аман!
Кайда соң адашкан җаның,
Кайда ул ялга талган?!»

Бу юллар Дәрдемәнд белән Туфанның олы фәлсәфи фикерләүләренең, аерым кеше язмышын галәм, ил бизмәненә салып сурәтләгән, фикер белән хиснең аерылгысыз гармоник бердәмлегенә ирешкән әсәрләренең дәвамы кебек кабул ителә. Кораб образлары арасындагы символик якынлык турында әйтеп тә торасы юк.

Шагыйрь ерактагы җирдәше язмышын йөрәге аша уздыра. Йөз ел элек туган җирен ташлап китәргә мәҗбүр булган шагыйрьгә – «адашкан җан»га – чиксез ихтирамы, аңлавы сызлануга, сагышка әйләнә… Экзестенциализм фәлсәфәсе, туарылып, алга чыга. Тынгысызлык тойгысы ил, дөнья киләчәге турындагы уйлануларга этәрә. «Кайталар томан артыннан, Күк горизонт аръягыннан Васыятьләр илгә һаман» кебек юллар янәдән исеме билгесез мөһаҗир язмышын искә алу, лирик каһарман күңелен биләгән өермәле, үкенечле, сагышлы кичереш шигырьнең башында алынган киеренке халәткә алып кайта.

Дөрес музыкаль аһәңгә көтмәгәндә читтән килеп кергән «Кояшка баккан Казан» кебек мажор юллар фикри тыгызлыкны, фаҗигале халәтне «рәнҗетә», әсәрнең эчке бөтенлегенә хилафлык китерә.

Рәдиф Гаташның ифрат югары кимәлле, классика дәрәҗәсендә калырлык әсәренә иңгән бу кызыл оптимизм шигырьнең гомуми юнәлешенә ятышмый, аның фәлсәфи җегәрен, әхлакый яңгырашын чикли, тарайта…

Зиннур Мансуров шигырендә мөһаҗирләр язмышы, туган нигезне ташлап китүгә этәргән сәбәп, әссас илдә хакимлек иткән иҗтимагый халәт белән бәйләнештә карала. Кешенең үз тормыш йомгагын үзе чишә алмау тудырган

эчке фаҗигаи гаҗизлек күңелне телгәли. Яшен яшәгән мөһаҗирнең эчке монологы рәвешендә бирелүе аеруча тирән тәэсир итә, «туган йорт» ерактагы идеал булып кала.

З.Мансуровның лирик каһарманы туган иленең кире кайтканнарга мөнәсәбәте өчен җаваплылыкны үз «өстенә» алмый. Шуңа да шигырьнең риторик сорау белән тәмамлануы аңлашыла:

«Ватандагы гүр дә яктырактыр...
Чит туфракта ничек каласың?
Үги итмәс микән туган илкәй
Кабер сорап кайткан баласын?»

Мөһаҗирлекне халкыбызның олы бер фаҗигасе итеп бәяләү татар шигъриятендә аерым шәхесләр язмышына да игътибарны көчәйтте. Җөмләдән, Әхмәт Гадел «Ил урылды...Идел-Урал ауды...» шигырен «Садри Максуди Арсалга» багышлый. Ә Лена Шагыйрьҗан: «Очып китте тагын Җирдән бу Татарның баласы», – дип, бөек биючебез белән саубуллаша («Рудольф Нуриев белән хушлашу»). Аерым шәхесләрнең тормышына, яшәешенә, дөньяга карашына багышланган тезмәләрендә дә шагыйрьләрне тулаем халкыбызның бүгенгесе, аның киләчәге борчый:

«Аһ, милләтнең йокы йоткан бердәмлеген.
Ела өзелеп, Ватан, диеп, киң дөньяга ярсал.
Нигә бездә батырлар һәм хаиннәр күп?
Әйт, Максуди, аңлат безгә, җаным Арсал!»
(Ә.Гадел «Ил урылды. Идел-Урал ауды...»)

Башка илләрдә яшәп яткан милләттәшләребезне туган илләренә кайтырга чакыру ноталары, сирәк булса да, хәзерге шигырьләрдә дә очрый. Мәсәлән, Асия Юнысова «Фин илендә» әсәрендә, Суоми татарларына динен тоткан, туган телне «онытмаган өчен» ихластан рәхмәтен әйткәннән соң: «Туган илдән китү бик тиз лә ул, Кайтыр юллар гына озактан», – дигән бәхәсле фикер әйтә. Бер яктан, буйсынган милләт кешесенә (бигрәк тә совет чорында) илдән чыгып китү психологик яктан да, хокукый тарафтан да җиңел булмаган, кире кайтып кергәнен төрмә, репрессия, һичьюгында, ачлык, хәерчелек көткән. «Сагынулардан азат бу буынга (фин татарлары яшьләренә. – Т.Г.) Идел ярында да Ватан бар», – кебек юлларны, Русиядә милли телләргә, мәгърифәткә нисбәтән эшләнгән гаделсезлекләр көчәйгән бүгенге көннәрдә, автор ошбу чакыруын мондый катгыйлык, шагыйрәкайнарлыгы белән әйтмәс иде кебек. Ничек кенә булмасын, чит мәмләкәтләрдә гомер сөрүче кан кардәшләребез язмышы хәзерге татар шигъриятендә моң, үкенеч, үтәлмәгән ниятләр, тарихи хәтеребезне яңартучы тармак буларак яши, бер әсәрдән икенчесенә юл алып үстерелә.

Ахыры киләсе санда ■

Истә, һаман да истә!

Язучы Равил Вәлиевнең тууына 80 ел

Язучы, публицист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (2000), Ф.Хөсни (2010) һәм Э.Касыймов исемендәге әдәби премияләр иясе, 1978 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Равил Вәлиев 1942 елның 20 августында ТАССРның Арча районындагы Яңа Кенәр авылында туган.

1970-1972 нче елларда ул Чаллыдагы «Кама таңнары» исемле күп тиражлы газетаның редактор урынбасары булып эшли. Шул ук вакытта җитди рәвештә әдәби иҗат белән дә шөгыльләнә башлый. Тиздән авторның «Каурыйлар чыныкканда» дигән очерклар циклы «Казан утлары» журналында (1972 ел, №2, 3, 4) басылып чыга һәм журналның еллык премиясе белән бүләкләнә. Яшь язучы тарафыннан тагы да киңәйтелебрәк эшләнгән бу әсәр 1973 елны Татарстан китап нәшриятында «Шәһәр булсын бүләгем» исемле документаль повесть рәвешендә аерым китап булып басыла.

Равил Вәлиев татар әдәбиятында тарихи әсәрләр авторы буларак танылу алды.

Ул 2020 елның 31 мартында Казанда вафат булды.

Язучы Газиз Кашаповның тууына 80 ел

Язучы, 1983 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Газиз (Газизҗан) Салих улы Кашапов (Кашшаф Үзиле) 1942 елның 21 августында ТАССРның Аксубай районындагы Яңа Үзи авылында туган.

Кечкенәдән әти-әнисез калган Газиз әбисе тәрбиясендә үсә. 1957 елда – туган авылының җидееллык мәктәбен, ә 1960 елда Иске Ибрай авылы урта мәктәбен тәмамлагач, ул ике ел колхозда бухгалтер ярдәмчесе, аннары тракторчы һәм клуб мөдире булып эшли. 1962 елның көзендә Совет Армиясенә алынып, башта курсант, соңыннан гаскәри частьта механик булып хезмәт итә, хәрби училище тәмамлый.

1973 елда Газиз Кашапов Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә читтән торып укырга керә, бер үк вакытта, 1974-1982 нче еллар арасында, Татарстан китап нәшриятында кадрлар бүлеге инспекторы, Әлмәт шәһәрендә чыга торган «Хезмәт байрагы» газетасы һәм КамАЗ радиотапшырулар редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, «Социалистик Татарстан» газетасының Түбән Кама, Алабуга, Мамадыш һәм Тукай районнарындагы үз хәбәрчесе һәм язучыларның Чаллы оешмасында пропаганда бүлеге хезмәткәре булып эшли.

Ләкин Газиз Кашаповны өметле яшь прозаик итеп таныткан беренче әсәр – «Сәмум җиле» повесте. Авторның «Солдат иртә ир була», «Җир җылысы» исемле повестьлары һәм «Язмышыңа ышан» дигән романы да игътибарга лаеклы.

Г.Кашапов 1991 елның 30 августында вафат булды.

Рәссам Шамил Шәйдуллинның тууына 75 ел



ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1991), ТРның халык рәссамы (1997), Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (2000) Шамил Мортаза улы Шәйдуллин 1947 елның 1 августында ТАССРның Тәтеш районындагы Берлек авылында туган.

Ш.Шәйдуллин – портрет, натюрморт, пейзаж һәм темалы картиналар ясау остасы. Рәссамның кайбер әсәрләре: «Сабантуй», «Нефть ягы. Лениногорск промыслы», «Карт алмагач төбендә», «Күкидә көз», «Авылымда бәйрәм», Г.Тукайга багышланган «Халык шагыйре» триптихы, «Чаптар атлар», «Сөембикә патшабикә» һ.б.

Ш.Шәйдуллин 2021 елның 4 августында Казанда вафат булды.

Шагыйрь Наис Гамбәрнең тууына 75 ел

Шагыйрь, әдәбият тәнкыйтьчесе, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре (2000), 1992 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Наис Гыймран улы Гамбәров 1947 елның 25 августында ТАССРның Мөслим районындагы Бүләк авылында туган.

Туган авылында башлангыч, Үрәзмәттә урта белем ала. 1966 елда ул Мөслим районында чыгучы «Авыл утлары» газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли. Шагыйрь Рәдиф Гаташның Үрәзмәт мәктәбенә практика үтәргә килүе аны шигърият белән мәктәп елларында ук кызыксына башлауга этәрә. Наис Гамбәров 1969 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә һәм аны 1974 елда уңышлы тәмамлый. 1974-1978 нче елларда ул Татарстан китап нәшриятының Матур әдәбият бүлегендә мөхәррир булып эшли. Аның мөхәррирлегендә «Татар халык иҗаты» күптомлыгының беренче дүрт китабы, Тажи Гыйззәт әсәрләренең 3 томлыгы, Мөхәммәт Гайнуллинның XIX гасыр татар язучылары иҗатына багышланган китабы дөнья күрә. Наис Гамбәров 1993 елның апреленнән вафатына тиклем «Казан утлары» журналында башта җаваплы сәркатип, аннары фән һәм сәнгать бүлеге мөдире булып эшли.

Ул 2005 елның 4 маенда вафат булды һәм туган авылы зиратында җирләнде.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Имән

Татар халкы мәдәниятендә имән агачы үзәк урыннарның берсен алып тора. Һуннар күзаллавынча, куе ябалдашлы биек имән агачы – кешене, ыруны, җирне күктәге Тәңре белән бәйләүче агачтыр.

Имән 400-500 ел, кайберләре хәтта 1000 елга кадәр яши. Шуңадыр да, имән агачы образы ыруның озын гомерлелек, тормыш куәте, муллык билгесе санала. Аның сурәте, саклагыч символ буларак, болгар хатын-кызларының күкрәкчәләренә, хәситәләренә дә төшерелгән.

Татарларда имәнлекләр хәзергәчә изге урыннар саналып, анда кылган догалар ата-бабалар рухына, һичшиксез, барып ирешә дип исәпләгәннәр. Имән шулай ук нәсел агачы функциясен дә үти: тамыры борынгы бабалар булса, яфраклары, ботаклары яшь буынны гәүдәләндерә.

Имән гаилә ныклыгы символы да. Татарларның гаилә йолалары буенча, гаилә нык, котлы булсын, дигән теләк белән, яшь гаилә өй каршына имән агачы утырткан. Гаиләдә бала туса да, тазалык, сәламәт булсын, дип, имән агачы утыртканнар.

Имән ул татар аңында яшәү көче бирүче дә. Татарстанның Чүпрәле районында май аенда үтә торган Каталау бәйрәме бүгенгәчә сакланган. Йола буенча, авыл халкы ел саен бу көнне дәррәү урманга барып, «имән агачын коча һәм үләндә тәгәрәп ауный». Аннары, Аллаһ ризалыгы өчен булсын, дип, имән белән серләшеп, алдагы ел өчен көч-куәт, сәламәтлек сорый.

Казан арты татарларында көтүнең беренче көнендә «иске ут»ны сүндереп «яңасын» табу йоласы саклана. Әлеге йола вакытында бөтен йортларда утны сүндереп, аннары бер урынга җыелып, имән агачын борынгыча бер-берсенә ышкып «яңа ут» тапканнар. Бу утны бөтен кеше дә әз-әзләп үзе белән өенә алып китә һәм өендә яңа учак кабыза. Әлеге йола һәртөрле йогышлы чирләрдән, афәтләрдән ышанычлы саклану чарасы саналган.

Билгеле булганча, имән кораб төзелешендә, күперләр, тегермән салганда, шпаллар, паркет ясаганда кулланыла.

XII гасырның күренекле сәяхәтчесе Әбү Хәмид Мөхәммәт әл-Гарнати үзенең язмаларында Болгар дәүләтенең диварлары һәм капкалары имәннән булуы турында яза.

Сәхифә «Татар халкы традицияләрен саклау һәм үстерү «Татар ядкярләре» шәхси учреждениесе (җитәкчесе – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе ***Фәнзилә Җәүһәрова****) белән берлектә әзерләнде.* ■

Имән турындагы видеоязманы шушы QR-код ярдәмендә кереп карарга мөмкин.

безнең мирас №8 август 2022

Имән дәвалый

Мәшһүребез Каюм Насыйриның «Хәвасе нәбатат» («Шифалы үләннәр») китабында имәнгә нисбәтле мондый юллар бар:

«Имән агачы (дуб обыкновенный) – күренекле агач. Гарәпчә шәҗәре танин диләр. Имән – һәркайда бар агач, ләкин бик салкын җирләрдә һәм төньяк тарафларда үсми. Тәме әчкелт һәм бөрештергеч. Үзлеге: куәт, әчкә ныклык бирүче һәм эчтәге суалчаннарны чыгаручы. Имәннең кайрысын уып, порошок көенчә дә, кайнатып, суын да кулланалар. Бизгәктән бик файдалы. Имән кайрысын кайнар суда төнәтеп, теш һәм авыз чайкасаң, бик яхшы була. Теш уртларын тазартыр һәм теш зәңгеләсен бетерер. Үт кутыры өчен әкәләсен (чикләвеген) көйдереп, кофе урынына пешереп эчәләр. Имән кабыгын һәм яфрагын суда кайнатып су ясап, суына кереп ятсаң, ныклык бирер һәм яман каннарны суырыр. Тагы, яфрагын пешереп, зәңгелә кутырына ябалар. Кече тел зәгыйфьләнсә яки кече тел төшсә, имән яфрагын кайнатып су ясап, азрак бал һәм аракы кушып тамакны, авызны чайкасаң, гаять шифасы бар. Арты (күтәне) чыккан кешегә һәм җенси органыннан эрен килгән кешегә шулай ук файдасы күп».

Имән чикләвеге, кайрысы һәм яфрагы

Имән төнәтмәсе

Имән флавоноидларга, пектин, танин, һәм крахмалга бик бай.

Медицинада аеруча яшь имән кайрысы (төнәтмә яисә чәй рәвешендә) кулланыла. Ашказаны авыруы белән интеккәндә, гастрит булганда, бавыр чиреннән дәваланганда имән төнәтмәсенең файдасы зур.

Аяклар тирләгәндә имән кайрысыннан мондый төнәтмә әзерлиләр: бер стакан суга ике кашык вакланган кайры салып 1-2 минут кайнаталар да төнәтәләр яки вакланган кайрыны оек (носки) эченә салып кияләр.

Имән кайрысы төнәтмәсен тел ялкынсынганда да, сидек тотмаганнан һәм экземадан интеккәндә дә кулланалар.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №8 август 2022

Кияү коймагы – табын байлыгы

Гаилә татар халкында элек-электән тормышның иң мөһим һәм иң югары кыйммәте булып саналган. Шуңа күрә гаилә кору, гаилә эчендә булган мөнәсәбәтләрне саклап калу һәм ныгыту серләре буыннан-буынга күчкән, кагыйдәләре тарих битләреннән әле дә югалып бетмәгән, үзгәрешсез калган.

Татар туйларын электән үк йоласыз күз алдына китереп булмаган. Мендәргә бастырып кәләшне каршы алу дисеңме, ипи тешләтеп йортның хуҗасын билгеләү, киленнең чишмәдән су алып кайтуы, иртән яшьләргә мунча ягу һәм кияү коймагы пешереп ашату – болар барысы да төгәл итеп башкарылып килгән. Иң кызыгы – атап үткән соңгы икесенең бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә булуы.

Никах һәм туйдан соң иртән яшьләр өчен мунча ягылган. Яшь кияү аннан килен текәкән яңа киемнәрне киеп кайткан, ә ул, үз чиратында, хатынына кыйммәтле бүләк – алтын йөзек, балдак яки шәльяулык биргән. Бу йола кыз куенына салу дип аталган. Яшьләр мунчадан кайтуга, аларны гадәти коймактан кечерәк булган кияү коймагы көткән. Без дә әлеге сыйны Юныс Әхмәтҗанов авторлыгындагы «Татар халык ашлары» китабындагы рецепт буенча пешереп, тәмен татып карау бәхетенә ирештек. Сез дә безгә кушылыгыз!

Кирәкле ингредиентлар:

- 1 кг бодай оны (безнең очракта – гади белен оны);
- 1,6-1,7 л сөт;
- 60-70 г шикәр комы;
- 5-6 йомырка;
- тоз;
- сары май.

Эш барышы:

1. Сөткә йомырка, тоз, сары май (безнең очракта – сыек май), шикәр комы салып, күперткәнче яхшылап туглыйбыз. (Камырның күперүе мөһим, чөнки бу коймакка чүпрә салынмый.)
2. Иләгән он салып, төерләре калмаслык итеп сары каймак сыман хәлгә килгәнче тагын яхшылап болгатабыз.
3. Кызган майлы табага аш кашыгы белән бераз камыр салып, диаметры 4-5 см чамасындагы кечкенә генә күпереп торган коймак пешерәбез.
4. Әзер коймакны тәлинкәгә өеп, каймак яисә катык белән табынга чыгарабыз.

Нәтиҗәбез куандырырлык булды. Мондый ысул белән пешерелгән кияү коймагының тәмле, кояш кебек алтынсу-саргылт, әкиятләрдәге сыман ымсындыргыч икәне ачыкланды. Әлбәттә, кияү коймагын күп итеп пешергәннәр. Беренчедән, татарлар тулы табын артында утырырга күнеккән, икенчедән, бу күренеш кыз әнисенең кияүгә карата ачык йөзен күрсәткән. Шуңа рецепт буенча бирелгән ингредиентларның күләмен үзегезгә яраклаштырырга киңәш итәбез. Ләкин кияү коймагына йомырка күп итеп салынырга тиеш, шуны онытмаска кирәк!

Кияү коймагы кияүне тәмле камыр ризыгы белән сыйлар өчен генә пешерелмәгән, ә кайбер очракларда яшерен сүзләрне җиткерү ысулы буларак та кабул ителгән.

Бу йола турында безгә Татарстанның халык язучысы, җәмәгать эшлеклесе Рабит Батулла сөйләде: «Кияү белән кәләш махсус әзерләнгән «ак келәт»кә кереп китә, анда бит инде интим нәрсәләр дә була. Мәсәлән, кәләшнең кыз булмавы ачыклана. Ир-егет берни дә эндәшми, хатынны ярата, гауга куптармый. Икенче көнне мунчадан чыгуларына кияү коймагы әзер була. Әйтергә теләгән фикерен белдерер өчен, кияү коймакны бөкләп төрә дә уртасын тешләп каба, нәтиҗәдә, уртасы тишек коймак барлыкка килә. Шуннан соң әлеге тишек коймакны самавыр янына төпсәгә кыстырып куя. Бу: «Кызыгыз сафлыгын җуйган иде инде, әмма мин аның белән яшәргә риза», – дигәнне аңлата. Ул бер сүз дә әйтми, ләкин аны шуннан аңлыйлар. Менә шул тишек коймак кияү коймагы була инде».

Әнә шундый нечкә темаларны татар халкы, үзенең тыйнаклыгы аркасында, төрле символ-билгеләр ярдәмендә белгертергә мәҗбүр булган. Асылы югалса да, ул йола гади коймак ашау буларак сакланып калган.

*Сәхифәне **Айзилә Сабирова** әзерләде.* ■

Кияү коймагы әзерләү турындагы видеоязманы шушы QR-код ярдәмендә кереп карарга мөмкин.

Көлке куа килә...

Шәүкәт Галиев (1928-2011)

Иске чир

Оешмалар өстенә – оешма,
Әйләнергә урын тар кала.
Бу ни хикмәт икән, безнең эш
Оештырган саен таркала?

2002

Гамил Афзал (1921-2003)

Экспромт

Ишәк – ише белән, шайтан – шәе белән,
Безнең өстәл ямьле чәе-мәе белән,
Заман – заты белән, дөнья – арты белән,
Вөҗдан – шарты белән, дуслык – ярты белән,
И-һи-һи...

Туфан Миңнуллин (1935-2012)

Ике робагый

Малай чакта гашыйк идем әбиеңә,
Егет булгач, гыйшкым төште әниеңә.
Инде син дә унҗидедә... Йа Ходаем!
Өченче кат... Бу яшемдә... Йә, ниемә?

***

Әгәр, мәйтәм, шундый план, ният кылсак,
Таһир белән Зөһрә кебек парлар булсак...
Шулай дим дә ниятемнән кире кайтам –
Комачаулый картлык белән симез корсак.

Т.Миңнуллин.
Нияз Хаҗиәхмәтов шаржы

Фаил Шәфигуллин (1939-1982)

Зөлфәткә

– Дан юк, Зөлфәт.
– Шигырьләр яз.
– Сан юк, Зөлфәт.
– Шәп җырлар яз.
– Ял юк, Зөлфәт.
– Курротта яз.
– Мал юк, Зөлфәт.
– Либретто яз.

(Язучыларның «Тынгысыз каләм» дигән дивар газетасыннан, 1974)



Фаил Шәфигуллин.
Нияз Хаҗиәхмәтов шаржы

Гомәр Саттар Мулилле (1932-2020)

Үзгәрмәде

Рабит Батуллага

Роберт иде – Рабит булды,
Үзгәрмәде Батулла:
Татарларга – әкиятче,
Керәшеннәргә – мулла.

Гәрәй Рәхим (1941-2021)

Кем нәрсә булдыра бит

Безнең кайбер әдипләребез –
Коеп куйган шәп бакчачылар.
Кайберләре әдәбиятта
Коеп куйган шәп акчачылар.

Тәлгат Нәҗмиев (1950-2014)

Ычкыну

(Саба мәзәге)

Иҗат кешеләре турында «хискә бай, акылга сай» дип әйтү гадәте бар. Кайбер вакытта «бераз авышкан», «ычкынган» дигән чагыштырулар да кулланалар. Бу сүзләрдә күпмедер хаклык бар сыман. Гомер буе үзе шигырь язып, поэзия сөючеләрнең иҗат җимешләрен «калыплап» гәҗиткә чыгарып утырган Газиз ага Нәбиуллинга Шәмәрдәндәге кичке мәктәп директоры Зөфәр Минһаҗев шигырьләрен кертеп бирә. Газиз абый кулъязмаларны әдәпле генә итеп ала һәм, автор чыгып киткәч, әйтеп куя:

– Да, бу да ычкынган икән...

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №8 август 2022



БЕЗ БАРЫБЫЗ ДА – БАЛАЧАКТАН

«Балачак мирасы» сәхифәсе – иң әүвәл сезнең өчен, өлкәннәр. Халкыбызның күңел җәүһәрләрен – такмак-такмазаларны, табышмак-башваткычларны, әкиятләрне, әдипләребезнең хикмәтле һәм гыйбрәтле, мәгънәви һәм тәрбияви әсәрләрен хәтерегезгә сеңдерегез, аларны, озын-озакка сузмыйча, балаларыгызга һәм оныкларыгызга җиткерегез, нәниләргә бишек җырларын көйләргә дә онытмагыз. Кыскасы, укыгыз, уйланыгыз һәм бер нәтиҗә ясагыз да... һәрвакыт безнең «Балачак мирасы» белән бергә булыгыз!

Көйсез бала

(Гыйбрәтле мәзәк)

Берәүнең бик көйсез баласы булган, ди. Менә беркөнне бу бала әнисеннән су сорап елый башлаган, ди. Әнисе аңа су биргән, ди. Су биргәч, сөт сорап елый башлаган, ди. Әнисе аңа сөт биргән, ди. Су да, сөт тә биргәч, көйсез бала: «Су белән сөтне бергә кушып бир», – дип еларга керешкән, ди. Әнисе аңа су белән сөтне бергә кушып биргән, ди. Шуннан соң көйсез бала: «Хәзер судан сөтне аерып бир!» – дип, тагын да ныграк еларга тотынган, ди.

Борын-борын заманда...

(Такмаза)

Борын-борын заманда,
Кәҗә команда,
Саескан сотник,
Үрдәк урәтник,
Бака дисәтник булганда,
Бар иде, ди, бер кеше,
Авызында булган, ди, бары бер теше.
Ашый алмый тончыккан,
Аптыраган, төн чыккан.
Шуннан торган, ди, бу иртән,
Тапкан, ди, бер тишек чабата.
Җиккән, ди, аңа сукыр тычкан.
Их, китте, ди, бу, каһәр суккан!
Барадыр иде, ди, чабып,
Кешесе калды, ди, авып.

Нәҗип Думави (1883-1933)

Авыл балаларының яңгыр теләве

Яңгыр, яу, яу, яу!
Сыерлар да сөт бирсен,
Игеннәр дә бик уңсын.
Игеннәрнең башлары
Ач булмасын, тук булсын.

Яңгыр, яу, яу, яу!
Бакчадагы алмагач
Корый, яңгыр яумагач;
Бакчалардан ни файда,
Алма пешеп тормагач!

Яңгыр, яу, яу, яу!
Елга аксын юллардан,
Ташып чыксын ярлардан;
Матур яңгыр соңында
Хуш ис чыксын кырлардан!

Тизәйткеч

Сезнең кызлар безнең кызларга кер тукмаклаштыргаламакчылар иде, тукмаклаштыргаласалар, тукмакларын алып килсеннәр, тукмаклаштыргаламасалар, тукмакларын биреп җибәрсеннәр.

Әйдәгез, уйныйбыз!

Әбәк

Балалар бер төркем булып басалар. Шунда бер бала: «Әбәк-чәбәк, тити-суат, килеп юат», – дип, иптәшләренең берсенә сугып китә. Шулай дигәч, һәммәсе «әбәк» бирелгән бала яныннан читкә йөгерә. Куучы аларның кайсын да булса куып тотып, «әбәк»не бирергә тырыша. «Әбәк» бирелгән бала тагын үз чиратында балаларны куа башлый.

Уен шул рәвешчә дәвам итә.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

ИЮЛЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● Июльдә тарихчы-галимнәр Сергей Белов һәм Булат Хәмидуллинның Идел буе халыкларының Исламны рәсми кабул итүенә 1100 ел тулуга багышланган «Волжские булгары. Путь к исламу» китабы (фәнни редакторы – Рәфыйк Мөхәммәтшин, рецензентлары – Питер Бенджамин Голден, Радик Салихов, Айрат Ситдыйков) дөнья күрде.

● Июль башында Төмән өлкәсенең Индрәй авылында зур бәйрәм булып үтте. Авыл мөселманнары оешмасы рәисенең урынбасары Кормангали Шәмсетдинов ачып җибәргән әлеге бәйрәмдә авылның иң яшь һәм иң өлкән кешеләре билгеләнде: алар – 2 июньдә туган Фаяз Вәлиев һәм 98 яшьлек Гөлмайрә апа Арипова иде. Бәйрәмдә 50 ел гомер иткән Нурания һәм Зәбирҗан Фәтхулиннарны алтын туйлары белән котладылар. Тантана кунакларына бүләкләр тапшырылды.

● 5 июльдә Изге Болгар җирендә ТР Дәүләт Киңәшчесе, «Яңарыш» Республика фондының Попечительләр Советы рәисе, ЮНЕСКОның мәдәниятара диалог буенча Махсус илчесе Минтимер Шәймиев рәислегендә борынгы шәһәр биләмәсендә «Кара пулат» спектаклен кую мәсьәләсе буенча күчмә киңәшмә узды.

ТР Дәүләт Киңәшчесе Болгар музей-тыюлыгында берничә локация карады, шул исәптән, «Хан сарае» һәм «Кара пулат»

территорияләрен дә. Проектны гамәлгә ашыруга бәйле оештыру мәсьәләләре буенча фикер алышуда Татарстан мәдәният министры Ирада Әюпова, театр эшлеклеләре, Болгар музей-тыюлыгы вәкилләре, Спас районы җитәкчелеге катнашты.

● 7 июльдә Питрәч районының Көек авылында салына торган «Фаруаз» мәчетенә тантаналы рәвештә ай куелды. Чарага Питрәч районы имамнары, якын-тирә бистәләрнең хәзрәтләре, иганәчеләр, төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр, мәхәллә халкы җыелды. Яңа мәчет Көек авылының халык телендә Яңа Салмачы дип йөртелгән өлешендә салына. Хәзерге вакытта мәчетнең эчке төзелеш һәм матурлау-бизәү эшләре дәвам итә.

● 15 июльдә Байлар Сабасында «Татмедиа»ның 15 еллыгына багышланган Са-

бантуенда «Шәһри Казан» журналисты Фәрит Салихов көрәш буенча абсолют батыр калды.

● 17 июльдә Балтач районының Бөрбаш авылында XV Россиякүләм мөселман балалар Сабан туе булып узды. Әлеге күркәм бәйрәм-тамашаның төп оештыручысы – Балтач районының имам-мөхтәсибе, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев.

● 17 июльдә Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының танылган актрисасы, Татарстанның халык артисты, Татарстанның Питрәч районындагы Күн авылы тумасы Раушания Хөснетдин кызы Юкачева вафат булды. Мәрхүмәнең җәсәде туган авылы зиратында җирләнде.

● 1-18 июль көннәрендә «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, бер

төркем татарстанлылар белән бергә, Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) туган һәм вафат булган Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләрендә, шулай ук анабыз Хәва җирләнгән Җиддә каласында булып, хаҗ сәфәре кылып кайтты.

● 19 июльдә Казанда Вәлиулла хәзрәт Якуповны искә алдылар. Күренекле дин әһелләре аның Самосырово зиратындагы кабере янында Коръән укыды. Дин эшлеклесе, мәгърифәтче, «Иман» нәшриятына нигез салучы, педагог, тарихчы һәм «Апанай» мәчетенең имам-хатыйбы булган Вәлиулла хәзрәт Якупов нәкъ ун ел элек 48 яшендә фаҗигале рәвештә һәлак булган иде.

● Июльдә «Минбар» ислам журналында Татарстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның «Җәһәннәмнең мәңгелеге мәсьәләсенә сөнни дин галимнәренең карашы» дигән яңа фәнни мәкаләсе дөнья күрде. Анда дин галимнәренең, шул исәптән, Россиядә эшчәнлек алып баручыларының да бу темага багышланган аерым чыганакларына күзәтү тәкъдим ителгән һәм аңлатмалар бирелгән. ■

МИРАСВОРД

Эрләр өчен тетелгән, таралган сүс

Гөмбәзле, колонналы түгәрәк бина

Туку станогы детале

1913-1914 елларда Казанда чыккан педагогик журнал

Иң борынгы язма

Сара Садыйкова музее урнашкан авыл

Комиссар эт

Керәшеннәрдә мәрхүмнәрне искә алып аш уздыру йоласы

Бала чыгармаган, ялгыз кош (диал.)

Гаяз Исхакый комедиясе

«Энесенә ул ...» китабы (Мөнир Мазунов)

Авыл (иск.)

Алтын (иск.)

Жырларга кергән елга

Төрле ырымнар, өшкерүләр, үләннәр белән дәвалаучы

Телсез-чукрак кеше (диал.)

Бөтендөнья татар конгрессы гамәлгә куйган газета

Төркем, өер (иск.)

... – беләк, хатын – терәк

Җан, рух

... Эвер (эстон актрисасы)

Бүлмә гөле

Ислам, христиан

Гаскәр (иск.)

Һөҗүмгә күтәрелергә өндәү авазы

Рус революционеры

Җырлы-биюле уен

«...-иш кирәк дөнья күтәргә» (җырдан)

Ярышта җиңү

Борынгы грек архитекторы

Җәлилче Гайнан ...

Алтын Урда һәм татар ханлыклары хөкүмәтендә диван әгъзасы

... де Бальзак

Җәядән атыла

Хәл бету, талчыгу

... Такташ

Дедал улы

Туган-...

Милли ... (Бөтендөнья татар конгрессы органы)

7 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: Агиев, ылак, сөлес, лимб, мәхәллә, Кох, чумар, Нерва, аем, саам, Мәккә, атом, пул, корыч, «Аһәң», Хосе, Игәнәй, Аав, Павлик, оешу, Эко.
Өстән аска: аксым, Сап, тунг, ислах, Ломе, Әкрам, Анапа, Василова, әһә, Лхаса, Әй, вок, Лео, чөмәк, Агиш, Тырлау, Оха, куш, Макаров, Каюм, аек, ыс, «Бәрмәнчек».

Рәис Габдулла тәзеде.

«Безнең мирас»

елъязмасы / август

Фәтхи Бурнаш урамы. Кыр Бикшиге авылы, Чуашстан.
Нәкыйп Каштан фотосы

760 ел элек (1262)

Борынгы Үкәк каласына (хәзерге Саратов – Сарытау шәһәре тирәсе) нигез салына. Бу чорда Алтын Урда дәүләте белән Бату (Батый) хан идарә итә.

410 ел элек (1612)

Лейпциг шәһәрендә беренче татар басма китабы дөнья күрә.

115 ел элек (1907)

Август аеннан Баку шәһәрендә социал-демократларның «Юлдаш» исемле атналык газетасы чыга башлый.

95 ел элек (1927)

3 августта Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы «Татар язуында латин (яңа төрек) шрифты (хәрефе) куллануны кертү турында» карар кабул итә.

80 ел элек (1942)

1 августта күренекле драматург Фәтхи Бурнаш (1898-1942) Куйбышев (хәзерге Самара) шәһәрендә НКВД хезмәткәрләре тарафыннан атып үтерелә. Кабере бүгенге көнгә кадәр билгесез.

30 августта «Кызыл Татарстан» газетасында Фатих Кәримнең «Пионерка Гөлчәчәккә хат» әсәре дөнья күрә.

60 ел элек (1962)

«Совет әдәбияты» журналының август саныннан Гариф Ахуновның «Хәзинә» романы басыла башлый.

55 ел элек (1967)

Хельсинки университеты профессоры Гомәр Таһир чакыруы буенча, галимнәр Мөхәммәт Гайнуллин, Хатип Госман һәм Резеда Ганиева Финляндиядә булып кайта. Алар Хельсинки университетында, яңа оештырылган Г.Тукай җәмгыятендә хәзерге татар әдәбияты һәм мәдәнияте турында чыгышлар ясый.

50 ел элек (1972)

14-20 август көннәрендә Татарстанда Украин әдәбияты атналыгы уздырыла.

*Журналга **Айдар Закиров** әзерләде.* ■

Журнал регулярно освещает все
значимые события в жизни нашей нации.

Содержание. Август 2022

И останется в мире слово моё...: Наис Гамбар.

Историческое наследие: «Малмыжские татары и марийцы». И.Газизуллин; «Татарский мир 100 лет назад». Р.Шарафиева и Л.Губайдуллин; «Касим хан (конец 1440-х-1469)». Л.Губайдуллин.

Татарский мир: «Мы изменили мнение о татарской нации». М.Шаймиев; «Василь Шайхразиев: «Для каждого татарина Татарстан – это родина»; «Татарский конгресс: первые шаги». И.Тагиров; «Данис Шакиров: «Великое счастье татар – иметь везде своих местных лидеров»; «Пройденная часть великого пути». Р.Закиров; «Фарит Уразаев: «Рождаются наши «белые баи»!»

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Обзор деятельности Мурада Рамзи». Х.Миннегулов; «Ислам. Религиозный словарь»; «Хадисы пророка Мухаммеда (с.г.в.)». А.Рахими; «Уроки религии». С.Бикбулат.

Литературное наследие: «Стихи Рахима Саттара»; «Отражение эмиграционного движения в татарской поэзии и Исхаки». Т.Галиуллин.

В глубинах памяти: «В памяти, до сих пор в памяти!»

Художественное наследие: «Выдающийся художник Урманче». З.Мухамметшин.

Природное наследие: «Дуб».

Рәссам әдипләр

Басмабызның алдагы санындагы «Безнең мирас» галереясы»н Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров ясаган Рабит Батулла портреты белән ачып җибәргән идек. Ошбу сандагы галереяда каһарман шагыйребез Муса Җәлилнең (1906-1944) уналты яшендә чагында – 1922 елда абыйсы Ибраһимның һәм булачак җиңгәсе Зөбәйдәнең туена атап махсус альбомга ясаган рәсемнәренең берсен тәкъдим итәбез.

«Безнең мирас» галереясы



«Күгәрчен сөйгән ярын коткара». 1922 ел. ***Муса Җәлил эше***

КАСЫЙМ ШӘҺӘРЕНДӘГЕ «ЯҢА МӘЧЕТ»

Мәчетнең XX гасыр башындагы күренеше

Мәчетнең хәзерге көндәге күренеше. *Ленар Гобәйдуллин фотосы*

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

4 612750 670172

***«БЕЗНЕҢ МИРАС»* журналына башкача язылу:**
- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 51), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.